# Казан утлары



9
сентябрь
1967

# КАЗАН утлары

АЙЛЫК ӘДӘБИ ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-ПОЛИТИК ЖУРНАЛ
ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАРЫ СОЮЗЫ ОРГАНЫ
КЫРЫК АЛТЫНЧЫ ЕЛ ЧЫГА

9
СЕНТЯБРЬ
1967

## Бу санда:

### РОМАН, ХИКӘЯЛӘР, ШИГЫРЬЛӘР

А. Расих. **Ямашев.** Роман . . . . . . . . 3
Ш. Галиев. **Җир баласы идем. Яшьләр, яшьләр. Тормышымда азмы күрелгән. Ашыкма, каләм. Яшьрәк чакта. Сабыр диеп. Унөченче елга чагыштырып. Исемеңне алып җырга куштым. Хәтерлим. Сөйгән ярым минем тылсымчы. Белеп булмый.** Шигырьләр . . . . . . . 38
Р. Фәйзуллин. **Туган якка. Читтә. Яшь беткәнче елыйлармыни. Көн шыксыз дип карадым. Ярлар күчәр. Куеп тереклек итүнең. Шатлыгы киләме. Мескен. Кайгы чәчеп. Минем турыда. Көз. Катлаулы икән. Тышка чыксам. Башны салларга салып.** Шигырьләр . . . . . 42
Р. Гатауллин. **Барысы да әле ярты юлда. Әллә нигә уйландыра.** Шигырьләр . . . . . 45
Г. Әпсәләмов. **Яфраклар коела. Язучының күңел дәфтәреннән** . . . . . . . . . . 46
Ф. Хөсни. **Яз галәмәте.** Хикәя . . . . . . . 54
А. Хәлим. **Колмак җыя кызлар. Тальян моңы.** Шигырьләр . . . . . . . . . . . . 60
Гамил Афзал. **Кызыл йолдыз. Поэзия. Бер елмаю. Мине картайткан. Борылам да карыйм. Берәү.** Шигырьләр . . . . . . . . . . . . 62

### ЗАМАНДАШЛАРЫБЫЗ

Д. Вәгыйзов. **Балыкчылар.** Очерк . . . . . 64

### СОВЕТ ВЛАСТЕНЫҢ ИЛЛЕ ЕЛЛЫГЫНА

Ә. Таҗетдинов. **Бөек Октябрь һәм Татарстанда культура революциясе** . . . . . . . . 75
М. Гыйбадуллин. **Революционер, хәрби җитәкче** . . . . . . . . . . . . . . 87
А. Әхмәдуллин. **Татар мәдәниятының көндәлек дәфтәреннән** . . . . . . . . . . . 96

### ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ

Р. Башкуров. **Үткән елның шигъри тавышы** . 103

КПССның
ТАТАРСТАН ӨЛКӘ
КОМИТЕТЫНЫҢ
ГАЗЕТА ҺӘМ
ЖУРНАЛЛАР
НӘШРИЯТЫ
КАЗАН

К. ТИНЧУРИННЫҢ ТУУЫНА 80 ЕЛ

Х. Кумысников. «Җилкәнсезләр» һәм аның сәхнә тарихы . . . . . . . . . . . . 109

ДУСЛАР ҖЫРЫ

М. Госманов. Уйгур әдәбияты сәхифәләре . . 112
С. Моллаудов, Г. Сәгъдеваккасов. Татар һәм уйгурлар арасында культура мөнәсәбәтләре тарихыннан . . . . . . . . . . . 114
Һ. Искәндәров. Ак каеннар. Китмәнем. Шигырьләр . . . . . . . . . . . . . 117
И. Бәхтия. Бакчачы. Бәлки, бәхетле итү кулымнан килмәс. Шигырьләр . . . . . . 117
Х. Һәмраев. Кетүче кыз. Мәхәббәт һәм җырларым. Шигырьләр . . . . . . . . . . 118
Н. Хәсән. Үз анамсың. Шигырь . . . . . . 118
Мәзәкләр . . . . . . . . . . . . . . . 119
Уйгур халык мәкальләре . . . . . . . . . 120

КОНКУРСКА КИЛГӘН ӘСӘРЛӘР

И. Катиев. Ялкын. Драма . . . . . . . . 121

ӘДӘБИЯТ ҺӘМ СӘНГАТЬ

Н. Юзиев. Музалар туганлыгы . . . . . . . 130

ХАЛЫК АВЫЗ ИҖАТЫ

Курган татарларының авыз иҗаты . . . . . . 138

КИТАП КҮЗӘТҮ

Н. Фәттах. Беренче китап һәм балалар әдәбияты. 148

БӘХӘСЛӘШӘБЕЗ, ФИКЕР АЛЫШАБЫЗ

Л. Әхмәдиева. Әсәр хакында берничә сүз . . 151
Г. Нәҗметдинов. Мин үкенмим . . . . . . 152

ТҮГӘРӘК ӨСТӘЛ ТИРӘСЕНДӘ


С. Таҗетдинов. Укучыларга җавап . . . . . 154

САТИРА ҺӘМ ЮМОР

Э. Гайнанов. Майсыз тәгәрмәч. Палас язмышы. Термометр. Шигырьләр . . . . . . . . 156
Ш. Шәрәпов. Чебен. Шигырь . . . . . . . 156
Әдәбият һәм сәнгать яңалыклары . . . . . . . 157

*Редакциягә килгән кулъязмалар кире кайтарылмый*

Редакциянен адресы: *Казань, ул. Баумана, 19. Дом печати, 2 этаж.*
Телефоннар: җаваплы редактор — 2-68-21, җаваплы секретарь — 2-68-21, бүлекләр — 2-39-52.
Хатлар өчен: *Казань, почтамт, почтовый ящик 63. Редакция «Казан утлары».*




*Атилла Расих*

Роман

Бөек Октябрь революциясенең илле еллыгына багышлыйм.

*Автор.*

## Көзге яңгыр

Стенадагы зур сәгать, өй эчен яңгыратып, унны сукты. Хөсәен китабыннан аерылды да башын күтәрде. Шундый шомлы минутларда сискәндереп, тынычлыкны бозган сәгатьнең әкрен генә зыңлап торуын кашларын җыерган хәлдә тыңлый башлады.

Кечкенә генә бүлмәдә ялгызы китап укый иде ул. Дөресрәге, китапка текәлгән генә, ә уйлары әллә кайларда, чөнки әледән-әле, күңелен китабыннан аерып, дикъкатен күрше бүлмәгә юнәлтә. Ул бүлмәдә аның әтисе ята. Каты авырый. Хөсәен түшәккә яткан кадерле кешесенең һәрбер кыштырдаган тавышына колак сала. Ул аның исән булуын, элеккечә көр тавыш белән: «Улым, сиңа йомыш бар», — дип әйтүен тели. Тик берни дә ишетелми, бары күңелгә шом сала торган авыр тынлык кына. Менә ни гомер инде шулай...

Саргылт яктылык сирпеп янган җиз шәмдәлдәге шәмне Хөсәен читкәрәк этеп куйды да көрсенеп аягына басты. Тәрәзә янына килде, салкын пыялага маңгае белән капланып урамны күзәтергә кереште. Кап-кара елтыр пыялага тып-тып итеп яңгыр тамчылары бәреләләр, алар бергә кушылып зураялар, авыраялар, аннары якты юллар калдырып, ашыга-ашыга аска шуышалар.

Әгәр әтисе таза-сау булса, Хөсәен хәзер бирелеп имтиханга әзерләнер иде. Тәгаен шулай. Аңа бик нык утырырга кирәк. Университет-

ка эләгү жиңел эш түгел. Ләкин хәзергә, мондый чакны, аның башына берни дә керми. Ул бары этисе турында гына уйлана.

Искиткеч бер хәл! Хөсәен моңарчы әле этисен шул дәрәҗәдә якын итүен, шулкадәр яратуын белмәгән икән. Үлем куркынычы күзгә күренә башлагач, Газраил үзенең килү хәбәрен җиткергәч, барысы да ачыкланды. Үпкәләшүләр дә, хәтер калулар да — барысы да, барысы да җилгә очты. Ә бит җентекләбрәк тикшерсәң, этисенең Хөсәенгә бик каты ачуланып йөргән чаклары булды. Улын Мөхәммәдия мәдрәсәсендә калдыру өчен никадәр көрәште ул. Инде сүзе үтмәгәч, Хөсәенне ничек кенә итеп каргамады, орышмады! Соңыннан барыбер улын учительскаяга бирергә риза булды тагы үзе. Чөнки, ни әйтсәң дә, акыллы кеше шул ул...

Хөсәен тәрәзәгә капланган килеш шулай уйланды. Ә урамда берниндн дә хәрәкәт юк. Конкалар[1] да йөрми, күрәсең, извозчиклар да көзге янгырдан шүрләп калганнар. Колакка бары кайсыдыр капка сакчысының шакылдавыгы гына ишетелә. Анысы да әкрен генә, зәгыйфь кенә булып. Ахры, ул кайдадыр яшеренеп кенә шакылдата... Хөсәен, җанын телгәли башлаган авырлыктан котылырга теләп, ашыгып яңадан китабына тотынды, шәмне үзенә табарак тартты.

Бераздан чыелдап ишек ачылды, этисе яткан бүлмәдән Хөсәеннең әнисе Бибифатыйма чыкты. Аның матур ак йөзе сагышлы, күзләренә йокысызлыктан талчыгу билгеләре кунган. Хөсәен, сагаеп, тәшвишләнеп әнисенә текәлде.

— Улым, — диде әнисе, — этиең янына керче.

Шомлы иде аның тавышы. Хөсәен, агара төшеп, урыныннан торды, тагын әнисенә карап алды.

— Этиең синең белән сөйләшергә тели, — диде Бибифатыйма апа.

— Кәефе ничегрәк соң? — диде Хөсәен. Әнисе туры җавап бирмәде, ләкин барысын да аңлатып аскы иренен тешләп куйды.

— Бар, улым.

Минһаҗ абзый ишеккә каршы як стена буендагы караватта, ап-ак урын-җирдә, җәймә, мендәрләргә күмелеп ята иде. Аның ябыклыгы, бөтенләй кеп-кечкенә булып калганлыгы Хөсәеннең күзләренә бүген аерата ачык чагылды. Авыруның йөзен чаларган куе төк баскан, күзләре нурсызланып эчкә баткан. Асылмалы лампа яктысында аның һәрбер сызык-чалымы ап-ачык булып күренә иде.

Хөсәеннең апасы Рокыя, энесе килеп керү белән, шыпырт кына урыныннан торып, ишеккә таба китте. Бу — нәкъ әнисенә охшаган, ак чырайлы чибәр хатын, иренең рөхсәте белән, Уфадан әле өченчекөн генә кайткан иде. Аның да елаудан күзләре кызарынган. Хөсәен бары шулкадәресен генә абайлады. Аның башында: «Соңгы тапкыр күрәм бит, апа да шуны тоеп үксегәндер», дигән уй көйри иде.

Минһаҗ абзый, күз караларын йөртеп, олы кызын ишеккә кадәр озаткач, күгелҗем кан тамырлары белән челтәрләнгән ябык, хәлсез сул кулын күтәрә төште. Бермәл Хөсәенгә карап торды, имән бармагын ике тапкыр бөгеп улын үз янына чакырды.

Хөсәен урталыкта нишләргә белмичә югалып тора иде, ул өнен җыйды һәм, аяк астындагы келәм җыерчыгына җиңелчә сөртенеп, этисенә таба атлады.

— Утыр әле, улым, — диде Минһаҗ абзый, — әнә утыргычны якынрак куй.

Хөсәенгә җиңелрәк булып китте, чөнки этисе нәкъ исән чагындагы кебек сөйләшә иде. Һәрхәлдә, Хөсәенгә шулай тоелды.

— Улым Хөсәен, — диде этисе. Бермәл тынып торды. — Аллаһытәгаләнең язганы шулдыр инде. — Ул тагы туктады. — Әле акылым саф, телем ачык чагында синең белән сөйләшәсем килә.

[1] Ат җигеп йөртелә торган трамвай.

— Эти, — диде Хөсәен, иңри төшеп, — алай дип әйтмә, зинһар!

Минһаҗ абзый тагы бер мизгел тынып ятты. Хөсәен исә, авыр тойгылар кичереп, этисенең йөзеннән күзләрен ала алмый иде. Тагы авыруның өзек-өзек әйткән сүзләре ишетелде.

— Улым, бөтен өметем синдә. Бердәнбер улым син, варис булып син каласың. Бөтен өметем синдә... — Ул, еш-еш сулап, тагы сүз әйтә алмый ятты. — Тормыш итүләре күп дәрт-дәрман сорый, күп тырышлыклар кирәк гомер сөрү өчен ир-егеткә, — диде ул, ниһаять, ашыга-ашыга. — Син инде хәзер, аллага шөкер, егерменче яшь белән барасың. Укыйм, дидең, укыттым, урысчасын укыйм, учитель булам дидең, анысына да күндем. Кулыңда, аллага шөкер, һөнәрең бар. Кая да хур-рисвай булмаслык һөнәр иясе булдың. Инде әйтергә теләгәнем, нанәм, шул: акыллы, инсафлы бул. Олыларның сүзеннән чыкма, денебезне онытма, ата-баба гореф-гадәтен ташлама. Менә шул...

Минһаҗ абзый соңгы сүзләрен улына карамыйча гына әйтте. Хөсәен төшенеп торды: әйтeләсе сүзләр бар иде әле.

Чыннан да, бераздан этисе янә телгә килде:

— Улым, сиңа фатихамны бирәм, тик берүк минем васыятемне аяк астына салып таптама...

— Ярар, эти. Тик син ни өчен болай... — Хөсәен сүзен әйтеп бетермәде. Ул: «...үләргә җыендың әле, син үлмисең, эти», — димәкче иде.

— Улым... тыңлале, — диде Минһаҗ абзый, ничектер ачулана төшкәндәй, — күптән сизеп йөрим, син соңгы вакытларда әллә нинди яшерен эшләр белән шөгыльләнәсең, хәтәр кешеләр белән чуаласың. Күреп торасың ич, авыр заманда яшибез. Денебезне, шәригатебезне аяк астына салып таптыйлар. Олыга хөрмәт бетте...

Хөсәен, тынычсызланып, еш-еш сулыш ала башлады. Тик карт, аны кисәтеп, имән бармагын күтәрде:

— Аллага шөкер, авырлыклар күреп үссәк тә, тырыш вә итагатьле булу аркасында хур-рисвай булмадык,—диде.—Менә шул, улым. Әниеңә, туганнарыңа миһербанлы бул, эшеңне иҗтиһат кылып, тырышлык белән башкар. Ә теге фетнәче студиннар, яһүдиләр белән аралашма. Аңа минем риза-бәхиллегем юк.

Әтисенең сүзе беткәч үк, Хөсәеннең күңелендә бәхәскә керү теләге туган иде. Ләкин моның акылсызлыктан да болайрак нәрсә икәнен ул тиз төшенде. Хөсәен үзен көчләп диярлек дәшми калды. Аның әтисе соңгы васыятен, соңгы теләкләрен әйтә иде. Ул, әлбәттә, иң яхшы нияте белән сөйли. Алтмыш елдан арткан гомере эчендә ул аз күрмәгәндер, менә хәзер инде ул шул тәҗрибәсенең, үз фикеренчә, иң файдалы дип тапкан җимешләрен улына тапшыра.

Хөсәен, кулларын тез капкачларына куйган хәлдә, башын иебрәк, тыңлап утырды.

— Мәсҗетне онытма, — диде Минһаҗ абзый, — муллаларга һәрдаим тиешле сәдакасын биреп тор, мулла — мәсҗет хуҗасы ул, ә мәсҗет — дин тирәге, ә дин — халык терәге. Инде, улым, фәкыйрьләргә, кимсетелгәннәргә дә сәдакаңны кызганма. Сәдака ул ике өлеш булып кайта. Сиңа сәүдә эшләренә керешергә киңәш бирер идем тагы. Әлифне таяк дип белмәсәм дә, мин, улым, аллага шөкер, яман аты чыккан сәүдәгәр булмадым. Үзең беләсең, сәүдә эшләре дә — адәмнән зур маһирлек, зиһен сорый торган һөнәр. Артык югары күтәрелмәсәм дә, бик күпләр белеп адәм хурлыгына калганда, эшемне көйле генә алып бара алдым. Туганнар каршында, гаиләм алдында... әйе, ким-хур булмадым.

Минһаҗ, хәл җыеп, тагы түшәмгә караган килеш, бөтен күкрәге белән сулый башлады. Ул ябык озын бармаклары белән чуалган сакалын тотты — тагы авызын ачты.

— Васыятьнамәмне эле җаен үк яздырган идем. Эш кәгазьләрем янында, күн букчада, шкафта.

Юк, юк, кирәкми, йөрәкне авырттыра торган газаплы сүзләрне сөйләмәсен ул! Әти үләргә тиеш түгел! Бу һич мөмкин түгел! Хөсәен шундый тойгылар тәэсирендә этисенең салкын ябык кулын тотты.

— Әти, кирәкми. Әти дим! Андый сүзләрне сөйләмә, зинһар, әти!

— Сабыр, улым. — Минһаҗ тагы тынып зиһенен җыеп ятты. — Абый җибәргән соңгы партия малны урнаштырып өлгерә алмадым, ул бүген булмаса иртәгә үзе килеп җитәргә тиеш. Инде килеп өлгерми икән, син аңлатып бир, моның тире-ярыга бу арада бәя очсызлану аркасында килеп чыкканлыгын әйт. Приказчик Исмәгыйль абыең белән барысын да бергәләп тикшерегез.

Минһаҗ күзләрен йомып өнсез калды. Аның күптән кайчы күрмәгән мыек чылгыйлары авызына керәләр. Ул әйтер сүзен шуның белән тәгәлләгән идеме, әллә юкмы — Хөсәен белеп бетермәде. Бары авыру: ·

— Бар, улым, аллага тапшырдык, — дигәч кенә, имәнеп китте. Әтисе ак җаймәгә сөяк белән тиредән торган кулын төшерде, бераздан ишеккә таба ишарә ясады. Хөсәен яшьле күзләре аша аны бик тонык күрә иде хәзер. Чыгып китәр алдыннан гына этисенең үзенә текәлгән кара күзләрен абайлады.

— Ял ит, улым, йоклар вакыттыр инде хәзер, — диде Минһаҗ.

Хөсәен үз бүлмәсенә кереп, тонык моңсу яктылык сипкән шәмгә таба атлады. Кемдер тагы күрше бүлмәгә керде, кемдер чыкты, әмма Хөсәен боларны тонык акыл аша гына кичерә иде. Ул өстәл янына утырып, чигәләрен тоткан хәлдә, төпсез уйга чумды. Юк, бу уйлану да түгел, бу, дөреслектә, тетрәнүдән хәрәкәтләнә алмыйча хәлсезләнеп калу иде. Ниһаять, күңел яктылыгын томалап торган караңгы пәрдә күтәрелде. Хөсәен, айнып китеп, тиз генә пиджагын салды һәм хатыны йоклап яткан кече бүлмәгә керде. Ул караватка утырып ботинка бавын чишә башлагач, тагы имәнеп китте. Чөнки ачык ишектән күренгән сеңелесе Хәдичәбикәнең күзләрендә моңарчы булмаган дәһшәтләнү күрде ул.

— Син ятмыйсыңмыни? Вакыт соң бит, — диде ниндидер басынкы тавыш белән.

— Юк, — диде Хәдичә. Аптырагандай зур кара күзләрен тутырып, абыйсына текәлде.

— Әтинең кәефе начарланса, мине уятырсың, — диде Хөсәен.

Хәдичә ризалык белдереп баш иде, өстәлдә яткан корьәнне алып шыпырт кына бүлмәдән чыгып китте.

Хөсәеннең хатыны түрдәге караватта тыныч кына йоклап ята иде. Узгач төнне ул да авыру мәшәкате белән йокысыз уздырды.

Хөсәен көзге яңгыр тамчыларының баш очындагы тәрәзәне шакуын тыңлап ятты. Йокы баса башлады. Инде йоклап китәм дигәндә генә, кинәт этисе яткан бүлмә ягыннан ниндидер кыштырдау ишетелде. Хөсәен сискәнеп күзләрен ачты һәм бөтен дикъкатен җигеп тыңларга керешге. Тагы тынлык урнашты. Ләкин Хөсәеннең йокысы да тәмам качкан иде инде. Ул этисенең үзенә әйткәннәре турында уйлана башлады. Әйе, ул Хөсәенгә итагатьле, олыларга карата химаяле булырга куша. Ул көчлеләргә, хуҗаларга сүзсез рәвештә буйсынырга өнди. Я хода, бу эш мөмкинме соң?! Хөсәен нәкъ шул золмәткә, көчләүләргә каршы көрәшү өчен социал-демократлар партиясенә кермәдемени?!

Хөсәен чытырдатып йомган күзләрен беләге белән каплады. Һич көтелмәгән күренешләр күз алдына килеп басалар иде. Ничек инде ул алай, ничек? дип пышылдап куйды.

Кинәт күңеле бик каты чәбәләнеп сыкрана башлады. Аның кадерле этисе, акыллы, кешелекле этисе үләргә ятканда, ул, Хөсәен, шулай тормыш, гаделсезлек турында гомуми фикер йөртеп ята!

Хөсәен, үзен кая куярга белмичә, икенче ягына әйләнеп ятты. Аның авыр сулавын йомышы төшеп күрше бүлмәгә чыккан әнисе дә ишетте, ул Хөсәен янына керде.

— Тыныч кына йокла, улым. Әтиеңнең кәефе яхшыра төшкәндәй.

— Йоклап булмый, әни. Һич йокы алмый, — диде Хөсәен, кинәт үзенең әллә кайчандагы иркә малайга әверелгәнен тоеп.

— Булмаса, бар, чыгып бераз һава сулап кер, — диде Бибифатыйма, — син дә бик алҗыдың шул. Ул кадәр борчылма. Әйтәм ич, әтиеңнең хәле яхшыргандай. Алла теләсә, иртәгә тамагына да каба башлар.

— И әни, — диде Хөсәен һәм әрнү катыш елмаеп куйды. Ул әнисе әйткән сүзләрнең асылда үзен юату өчен генә әйтелгәнлеген ачык тоя иде. Җәһәт кенә урыныннан торды да, күрше бүлмәгә чыгып, яктыда ботинкаларын кия башлады. Чыннан да, бер әйләнеп керергә кирәк дигән фикергә килде ул. Яңгырлыгын киеп, зонтик алып: «Мин шушы тирәдә генә булырмын», — диде.

Баскычтан төшкәндә, аның күңелендә өмет йолдызы тугандай булды. Бәлки, чыннан да этинең кәефе яхшыра башлагандыр, бәлки, чыннан да ул иртәгә тамагына каба башлар?

Тик бу өметләр озакка бармады, Хөсәен әтисенең кипкән ябык йөзен, нурсыз күзләрен хәтерләде, аның әйткән сүзләрен, сөйләгәндә газаплануларын тагы башыннан кичерде. Һәм өмет йолдызы кинәт сүнде.

Ул яңгырда бүрткән бастырыкны көчкә этеп, шулай ук бүртеп тыгызланган кече капканы авырлык белән ачты. Урамда шыксыз караңгылык һәм күшектергеч вак яңгыр гына иде. Күрәсең, җил искәнгәдер, яңгыр биредә аерата көчле тоела. Хөсәен йөзе чыланудан уянып киткәндәй булды. Хәтерләп, тиз генә зонтигын ачып күтәрде. Шулай да монда сулыш алуы җиңел иде. Зиһене яктырып китте. Ул, өзелгән җепнең очын тапкандай, югалган фикер-уйлар йомгагын яңадан сүтә башлады. Әйе, әтисе бит улына яхшылык теләп, үзе бик күп тапкырлар һәр ягын үлчәгән, бизмәнгә салган, яшәү өчен көрәш нәтиҗәсендә туган кагыйдәләрне аңлатты. Юк, алай гына да түгел. Аңлатты гына да түгел, ул аны васыять итеп әйтте. Ә бәлки, ул хаклыдыр? Бәлки, школадагы алдынгы яшьләрнең янып, дәртләнеп йөрүләре узгынчы гына нәрсәдер? Бәлки, теге укучылар янына килеп йөрүче революционерлар кирәкмәс һәм гомердә дә тормышка ашуы мөмкин булмаган әйберләр турында сөйлиләрдер?

Хөсәен, барысын да бер җепкә тезәргә тырышып, үзе укып чыккан мәктәпкә килүче татар революционерларын да, рус революционерларын да күз алдыннан кичерде. Алар бик ачык дәлилләп революцион хәрәкәтнең булачак җимешләре турында сөйлиләр иде. Кайчандыр, яшүсмер чагында, тирә-юньдәге йөрәк әрнеткеч гаделсезлеккә күңеленнән җан ачулары килеп ризасызлык белдергән иде Хөсәен. Шул көннән алып революционерлар белән очрашканга кадәр ул ялгыз башына барыр юллар эзләп азапланды. Ләкин Хөсәен артык беркатлы һәм тәҗрибәсез иде шул ул чак. Аның революционерлар аңлаткан рәвештә тормышка карау турында уйлаганы да булмады. Ул моңарчы бары хыял дингезләрендә генә йөзгән икән.

Хөсәен, белемле һәм кыю кешеләр белән очрашып, күзләре ачылганнан бирле, комсызлык белән, ару-талуны белмичә, менә ничә ел инде яшерен әдәбият укып үзенә җан азыгы таба. Әйе, күп белгән саен, күбрәк укыган саен мәсьәләнең бик катлаулы булуы ачыла бара. Әйтерсең лә, Хөсәен тау башына таба үрмәли һәм тукталып тирәюненә күз ташлый, ул җиһанның киңәйгәннән-киңәя баруын күрә, аның тагы да киңрәк булырга тиешлеген аңлый. Ләкин шулай да хакыйкать аның өчен ачык, көрәш юлы мәгълүм, һәм менә нәкъ шундый бервакытта ана туктарга кушалар, син бит бөтенләй кирәксезгә биек-

леккә үрмәлисең, диләр. Ә бәлки, чыннан да, шулайдыр? Бәлки, чыннан да, Хөсәен кирәкмәс эшкә керешкәндер? Алда ике юл ярылып ята. Берсе аның тыныч, хәвефсез юл. Моның өчен Хөсәенгә бары әтисенең хәер-фатихасын алып, ул кинәш иткәнчә генә гамәл кыларга кала.

Ә икенчесе куркынычлы, авыр юл. Монда сине мең төрле газаплар көтә. Син монда бернинди дә дөньяви рәхәтләр күрмәячәксең, аны бел. Синең артыңнан өзлексез шымчылар сагалап йөриячәк. Тотылсаң, сине һич аямастан караңгы зинданга ташлаячаклар. Менә сайла инде син шул ике юлның берсен, Хөсәен!

Крестовников заводы ягыннан бөтен урамны яңгыратып дөбер-шатыр атлы трамвай килә. Тәгаен, бу соңгы конка иде. Өстә беркем дә күренми, әчтә дә кеше аз. Чыбыркысын тоткан кучер бөтенләй бөрешкән; яңгыр зонт астына да үтә, күрәсең, мескен күшегеп беткән. Хөсәен трамвайны озатып, аның тоныкк фонарьлары ераклашканын тукталып карап калды. Ул ераклашкач, күлләвек аша сикерде, юлын дәвам иттерде.

Әйе, әтисе белән ул ничек тә аңлашыр иде. Ул аның акыллы һәм зирәк кеше икәнлегенә ышана. Ләкин хәзер вакыты андыймыни?

Хөсәен, уйларына бирелеп бара торгач, якында гына ишетелгән гөрелтегә игътибар итте. Карасана, сизми дә калган бит: Крестовниковлар заводына килеп тә җиткән икән! Урамның каршы ягында зур карачкы булып күккә ашкан кызыл кирпеч бина тора. Аның тимер рәшәткәле тәрәзәләреннән тоныкк яктылык сирпелә. Хөсәен белә: аның эчендә әле дә, тирләп-пешеп, ярым ялангач эшчеләр сабын кайнаталар. Анда бөркү, эссе, сасы. Шунда көн саен ундүрт сәгать эшлиләр алар. Татар егетләре, татар кызлары аерата авыр хезмәт башкаралар. Аларны төрлечә мыскыл итү, рәнҗетү, кагу, төрле хәйләләр белән соңгы тиеннәрен басып калу, штрафлар...

Хөсәен, тукталып, завод эченнән килгән гөрелтене тыңлап торды. Мондый көзге караңгы төндә аерата дәһшәтле булып ишетелә иде ул аваз.

«Ә син, әти, ташла бу эшләреңне, дисең», — дип уйланды Хөсәен. Тирә-ягына каранып алды да: «Хәер, — дип куйды, — аның үз юлы бар, ул үз юлым дөрес дип яшәгән». Тыкрыктан ниндидер исерек урыс килеп чыкты. Аңа диңгез тубыктан иде. Ул, тирә-юньдәге этләрне уятып, акырып җырлый-җырлый, урам аша узды һәм каршы тыкрыкта күздән югалды. Һау-һаулап күтәрелгән көчекләр озак тынычлана алмадылар. Капка саклап төн уздыручы каравылчылар калгып киткән җирләреннән сискәнеп уяндылар булса кирәк, алар да бер-бер артлы шакылдавыкларын селкергә керештеләр.

Бераздан урамда тагы үле тынлык урнашты. Ямьсез, авыр көзге җилле, яңгырлы елак тынлык иде бу.

«Кайтам да әти белән аңлашам, — диде Хөсәен, — кадерле әтием, дим, син күрмисеңмени халыкның михнәт чигеп интегүен, җәфалануын? Син үзең дә бит миңа яшь чагыңда күргән кимсетелүләрең, рәнҗетелүләрең турында сөйли идең. Тик син тапкан юл әле ул я бик шома, я бик оятсыз кешеләрне генә кояш яктысына алып чыккан. Ә мин барлык кешеләрне бәхетле итү өчен көрәшәчәкмен!

Мин иплап кенә, әтиемнең хәтерен калдырмаслык итеп кенә аңлатачакмын, аны ялыктырмыйча гына», — дип юатты ул үз-үзен.

Кинәт шул җирдә Хөсәен боларның ахмак бер нәрсә икәнлеген тоеп тукталып калды. Әйе, аннан да юләррәк кеше була алырмы соң дөньяда! Әтисе үлем түшәгендә ята, ә ул аңа үзенең тормышка карашын сөйләргә тиеш. Юк, юк! Ул хәзер бернинди дә карар кабул итә алмый әле. Нишләргә соң? Әтигә берни әйтмичә тору да алдау түгелме соң? Соңгы көннәре, бәлки, соңгы сәгатьләредер аның? Хөсәен адымнарын әкренәйтә төште. Нинди дә булса карарга килергә кирәк иде.

Ә яңгыр көчәйгәннән-көчәя, су инде юка зонтның эченә дә үткән, таяк буйлап агып кулларны чылата. Хөсәен онытылып ялгыш кулләвеккә кереп китте, ботинкаларының эче лач булганын да абайламады.

Ул, тукталып, чатлыктагы таш өстенә менеп басты. Чарасызлыктан да газаплырак нәрсә бармы дөньяда?

«Юк, болай, — дип план корды ул. — эти, син, зинһар өчен, башта терел, савык әле, дим, аннан соң мин сиңа барысын да, барысын да сөйләрмен. Мин бит синнән моңарчы берни дә яшермәдем, хәтта син теләмәгән, синеңчә ялгыш исәпләнгән эшләр турында да мин синең күзеңә карап туп-туры әйттем. Минем барыр юлым турында да, киләчәгем, бәхетем турында да мин сиңа, эти, барысын да әйтермен. Тик син терел генә, син аңламый калмассың.»

Хөсәенгә беразжиңелрәк булгандай тоелды. Ул, үлем түшәгендә яткан кадерле әтисенә әйтеләсе сүзләрен күңеленнән тагы бер тапкыр кабатлап, юеш, авыр капканы ачты, ишек тоткасына үрелде. Бу минутта ул баскычтан менү белән дәһшәтле хәбәр ишетәчәген, әнисенең, сабыр һәм кадерле әнисенең, елап улының муенына сарылачагын, кыз туганнарының сулыгып-сулыгып елаячагын, әтисенең моннан биш кенә минут элек җан биргәнлеген белми иде әле.

## Ак кар өстендә ай нурлары

Төн иде. Хөсәеннәр өендә барлык кеше йоклап беткән, ишекләр бикле. Бары тик Хөсәен бүлмәсендә генә, ике тәрәзәгә дә юрган каплап, тәбәнәк өстәл янында өч егет нәрсәдер эшли. Алар бик җитди һәм эшчән кыяфәттә. Идән кәгазь кисәкләре белән тулган. Хөсәен өстәл уртасындагы җилемле калай табага иелгән. Каршысында — Гыйльфан. Түгәрәк йөзле бу таза егет идәнгә тезләнеп утырган. Гади киемнәренә игътибар итсәң, аның эшче икәнлеген аңларга була. Ләкин конспираторларның өченчесе — тәбәнәк өстәлнең читенә утырганы — ак йөзлесе — бөтенләй башка катлау кешесе. Анысының исеме — Җәгъфәр. Ул йомшак җиңел читек, әйбәт постау казаки, хәтфә кәләпүш кигән.

Хөсәен җилем салынган бәләкәй табасына беренче битне китереп каплады. Өстеннән резин уклау тәгәрәтеп уздырды. Җәгъфәр, кулындагы язулы кәгазьне өскәрәк күтәрә төшеп, тынын кысты. Гыйльфан да, чиста кәгазь битләрен санаудан туктап, зәп-зәңгәр күзләрен зур итеп ачты. Хөсәен прокламацияне тиз генә җилемнән куптарып алды һәм, язуга күз ташлау белән, йөзен чытты.

— Карасы җәелә, — диде ул, аптырый төшеп.

— Зарар юк, беренчесе шулай була инде аның, — диде Җәгъфәр.

— Бир әле бер бит, тагы сынап карыйк, — диде Хөсәен Гыйльфанга.

Ул җитез хәрәкәтләр белән кәгазьне җилемгә китереп каплады да, уклавын тәгәрәткәч, кәгазьне тагы куптарып алды.

— Егетләр, — диде Хөсәен, яктырып, — прокламация менә дигән булып чыкты!

Кулындагы язуны, горур елмайган хәлдә, Җәгъфәргә тоттырды. Җәгъфәрнең нервлы, хәрәкәтчән йөзе, кара күзләре шатлык нурлары балкытып кабындылар.

— Расиески сатсиал димакратический эшчеләр партиясе. — дип укыды ул. Гыйльфан да муенын сузып язуны күрергә теләп иде. Ул тотлыга-тотлыга өстәде:

— Тоташыгыз бергә, бөтен дөньяның эшчеләре!

Хөсәен һич тыела алмыйча көлеп җибәрде.

— Булды бит! — диде ул. — Булды бит, егетләр!

— Булган, барып чыккан, — диде Гыйльфан. Җәгъфәр исә куанычыннан бөтенләй телдән язган. Ул дулкынланудан кызарынган, үзе елмая иде.

— Димәк, шулай эшләгәндә була икән, — дип нәтиҗә ясады Хөсәен, — җиң сызганып эшкә керештек алайса, егетләр. — Шул ук минутта ул курткасын салып ташлады һәм чынлап торып җиңнәрен сызгана башлады.

Егетләр, баш күтәрмәстән, прокламация басарга тотындылар. Алар хәзер ара-тирә генә, анда да артык тавышланмыйча, сүз алышалар иде. Бүлмә эчендә күбрәк көрсенеп кую, яки кәгазь кыштырдаганы гына ишетелеп торды.

Караңгы төшкәнче үк эшкә керешкәннәр иде бит алар. Башта сакчы куеп эшләделәр. Хөсәеннең сеңелесе Хәдичә ишек алдында торды. Ниһаять, төн җитеп, барлык кеше йокыга талгач, капка-ишекләрне йозаклап, Хәдичәгә йокларга рөхсәт иттеләр, үзләре кечкенә бүлмәгә кереп бикләнделәр.

Башта эш һич кенә дә көйләнмәде. Күпме казан аслык утын гына бетермәделәр алар! Күпме кәгазь әрәм итмәделәр! Инде өмет өзеләдигәндә генә, эш, ниһаять, уңайга китте. Барып чыкмаса, әлбәттә, бик авыр булачак иде. Аерата Хөсәен өчен. Чөнки татар телендә прокламация чыгарырга алынган кеше ул бит, Кулешага булдырабыз дип ул сүз бирде ич.

Русча язылган текстны алу белән, Хөсәен эшкә кереште. Прокламацияне тырышып татар теленә күчерде. Анда сүз сыйнфый көрәш турында бара иде. Ул эшчеләрне берләшергә, социал-демократия әләме астында политик көрәшкә өнди иде. Хөсәен бик нык тырышты, мәгәр үзе теләгәнчә дөрес һәм аңлаешлы итеп яза алмады. Яңа төшенчәләрне билгеләү өчен нинди-дер яңа сүзләр кирәк иде. Шул ук вакытта алар гади халык аңларлык та булсын.

Хөсәен, ярдәм эстәп, әдәби сәләте белән барлык Мөхәммәдия шәкертләре арасында танылган күптәнге ышанычлы дусты Җәгъфәргә мөрәҗәгать итте. Шуның белән төзәтеп утырдылар. Хәзер прокламация, әлбәттә, бик шома кебек иде, ләкин эшчеләр аңларлыкмы соң ул? Хөсәен ярдәмгә бу юлы Гыйльфанны чакырырга карар кылды. Крестовниковның сабын заводында эшләүче бу егет тә ышанычлы, үз кеше иде хәзер. Өчәүләшеп язуны төзәттеләр. Һәм менә, ниһаять, соңгы бит кәгазь дә җилемгә ябыштырылды...

— Ничә булды? — дип сорады Хөсәен.

— Нәкъ илле алты, — диде Гыйльфан, кулындагы прокламацияләрне күздән кичереп.

— Күбесе бозылды шул, — диде Хөсәен, үкенечле бер төс белән, — артык чыкмый, буявы бетте.


— Болай чыккач та шөкер, — диде Җәгъфәр, — мин бөтенләй барып чыкмас дип шомланган идем әле.

Өчесе дә өстәлдәге җилемле табага карап тынып калдылар. Сүз белән аңлашмасалар да, өчесе дә бер үк тойгы кичерәләр иде. Әлбәттә, эш хәтәр булмаса, зур саклык сорамаса, бәлки ул кадәр авырга да килмәгән булыр иде. Ләкин һәр адымыңны үлчәргә, артыңа-алдыңа берьюлы күз салырга, конспирация кагыйдәләрен җиренә җиткереп үтәргә кирәк иде. Әмма, ничек кенә булмасын, болар барысы да хәзер артта калган борчулар булды. Егетләр шуңа шат иде.

Җәгъфәр кинәт үзен туңып киткәндәй тойды. Шушы бүлмәгә чыккан мич йөзенә бер ягы белән тиз генә барып сөялде.

— Чиллә кирәкне бирә, — диде Гыйльфан, Җәгъфәр янына урнашып, — миңа да суык булып китте.

— Гыйнвар быел башыннан ук зәмһәрир суыклары белән килде, — диде Җәгъфәр. — Их, хәзер авылда атай өендә булсам иде, — диде



*Л. Анисимов рәсемнәре*

ул, түбәтәен кырын җибәрә төшеп, — рәхәтләнеп мич башында ятар идем.

Хөсәен дә, иптәшләре арасына тыгызланып кереп, мичкә аркасын сөяде.

— Ә син бит, атай карттан гомергә киттем, дигән идең. Сагына да башладыңмыни? — диде ул, көлемсерәп.

Җәгъфәрнең ябык ак йөзенә ачы елмаю чыкты.

— Юк, мин аны сагынмыйм. Әни минем үги, мин бары... мич башын гына сагындым.

Өчесе дә бердән тын өй эчен җанландырып көлеп җибәрделәр.

— Я, җитте, егетләр, — диде кинәт Гыйльфан. — Миңа китәргә вакыт. Миңа иртәгә таңнан эшкә чыгасы.

— Иртәгә димә, бүген диген, — диде Хөсәен. Комод өстендә торган кечкенә сыерчык оясыдай сәгатьнең теле икене күрсәтә иде.

— У, мин дә кайтам болай булгач, — диде Җәгъфәр, кабаланып, — пишкадәмнәр тәһарәт алырга таң тишегеннән уяна.

Хөсәен басылган прокламацияләрне бүлә башлады, яртысын Гыйльфанга бирде, берничәсен Җәгъфәргә сузды, калганын карават матрацы астына кыстырды.

— Сине тоткарламыйм алайса, — диде ул Гыйльфанга, — боларны нишләтергә кирәклеген беләсең инде... Ә син, Җәгъфәр, чак кына сабыр ит. Утырып тор!

Җәгъфәр урындыгын мич янынарак җайлап куйды. Хөсәен белән Гыйльфан, аяк очларына басып, шыпырт кына караңгы якка чыгып киттеләр.

Баскычтан төшеп, ишек алдына чыгу белән, алар төннең яктылыгына хәйран калып бераз тукталып тордылар. Тулган ай үзенең сихри нурлары белән ак кар каплаган ишек алдын, түбәләрне зәңгәрсу якты-

лыкка манчыган иде. Хөсәен дә, Гыйльфан да, «Я, нишлибез, хәвефле булмасмы?» дигәндәй, бер-берсенә карашып алдылар.

Гыйльфан, үзе дә тоймастан, терсәген янтыгына тидереп, эчке кесәсендәге прокламацияләрне барлады. Бераз уйлангач:

— Борчылма, — диде тәвәккәлләп, — берни дә булмас.

— Урамга чыккач та, күл буена таба кит. Шуннан яхшырак, — диде Хөсәен.

Гыйльфан, елмаеп, күз кысып куйды.

— Мин гуләйттән кайтучы кызмача кеше...

— Үзең кара инде. Нинди эш башкарганыңны аңлыйсың, Гыйльфан.

Алар капкага таба юнәлделәр. Аяк астында кар шыгырдый, көйдергеч салкын бит очларын әчеттерә иде. Хөсәен ирексездән Гыйльфанның иске күн итекләренә, юка бишмәтенә күз төшерде. Мондый кышкы суыкта кия торган кием түгел шул.

Алар кече капканы ачтылар да башта урамны күзәтеп тордылар. Шылт иткән тавыш та ишетелми иде. Бары каршы яктан ниндидер әнчек кенә өреп куйды. Күрәсең, суык аңа да артык батыраерга ирек бирмәде, ул да шыңшып яңадан оясына кереп тынды.

— Бар, — диде Хөсәен, Гыйльфанның кытыршы кулын кысып. — Хәерле юл, туган!

Гыйльфан капкадан чыкты да бер секунд эчендә чаттан борылып күздән югалды. «Китте», — дип уйланды Хөсәен, ниндидер эчке дәрт һәм тантана белән. Гыйльфанның аяк тавышларын ишетү өчен ул бераз вакыт тыңлап торды, әмма тирә-юньне яңгыравык буш тынлык баскан, бөтен җиһан элеккечә ай нурларында көмешләнеп катып калган иде.

Хөсәен байтак вакыт тыңлап торды. Ниһаять, суык аның куенына, бөтен тәненә йөгерә башлады. Капканы бикләп алгач, ул тагы бер минут чамасы игътибар белән урам якка колак салып торды да йөгерәатлый өйгә кереп китте. Юравынча, Гыйльфан хәзер күл буена кадәр араны хәвефсез генә үткән иде инде.

Бераздан Җәгъфәр белән Хөсәен тагы ишек алдына чыктылар. Бу иптәшен дә Хөсәен шундый ук саклык һәм борчылу белән озатып җибәрде.

Туңып-катып, ул бүлмәсенә кергәндә, сәгать өченче киткән иде. Хөсәен, чишенгәч, туңган кулларын уа-уа, шатлыклы бер дулкынлану белән, прокламацияләрне халык арасына алып киткән дусларына күңеленнән уңыш теләп, аларның бу минутта ни эшләүләрен, кайда булуларын күз алдына китерергә тырышты.

«Хәерле сәгатьтә!» — диде ул, дәртләнеп, үзалдына елмаеп, тиз генә ботинкасын, чалбарын салды, җылы юрган астына кереп ятты. Җылына төшкәч кенә, әле эшлисе эшләренең бетмәгәнлеген, эзләрне яшерергә, җуярга, томаланган тәрәзәләрне ачарга, ниһаять, утны сүндерергә кирәклеген хәтерләде. Шулай да җылы урыннан торасы килмәде. Хөсәен түшәмгә караган килеш ята бирде. Соңыннан, йокы басып тәмам үзен изрәтә башлагач, ул сискәнеп урыныннан торды, әлеге эшләрне эшләде. Хәзер инде өй эченә дә ай нурлары төшкән, тәрәзәләр яп-якты иде. Уйлар төркеме, узгынчы болытлардай, бер-бер артлы күңел күген тутыра башлады. Ни өчендер вакытсыз үлеп киткән этисе исенә төште. Яралар бик яңа, әле төзәлмәгән иде шул. Моннан ике атна элек кенә бит әле мәрхүмнең кырыгын уздырдылар.

Хөсәен этисенең үзе бала чагыннан ук күңеленә сеңгән кыяфәтрәвешен хәтерләде. Егет кеше иде ул. Булдыклы, уңган иде. Менә алар этисе белән бергә Ташаяк ярминкәсендә йөриләр. Хөсәен әле ул чак шәкерт тә түгел. Алар икесе дә булган әйбәт киемнәрен кигәннәр. Этисендә өр-яңа сай каракүл бүрек, утырма якалы әдрәс казаки, ә Хөсәен кып-кызыл чуклы фәс һәм матур яшел хәтфә камзул кигән.

Менә алар Ташаяк ярминкәсе аша узалар. Ә тирә-юньдә күз явыныы алырлык тамаша. Ул берсеннән-берсе матур уенчыклар, кәкре муенлы алмачуар атлар, күзләре йомыла торган алсу битле таш курчаклар, колакларны тондырып ата торган гайрәтле пугачлар. Ә андагы тавыш, андагы җанлылык! Ул, мин сиңа әйтим, уенчык гармуннар чыелдый, курайлар сызгыра, үти-үтиләр кычкыра, такмак әйтә-әйтә сәүдәгәрләр үзләренең товарларын мактыйлар. Мәхшәр, дөнья гөр килә! Кинәт шул вакытны, Хөсәеннең шатлыгы ташып торган бервакытны, аларның күз алдында юан корсаклы, бөтеркә мыеклы жандармнар фәкыйрь киемле яшь кенә бер егетне тотып каядыр алып киттеләр. Хөсәенгә теге егет бик кызганыч булып тоелды. Кем ул, нинди кеше, ни өчен аны шулай, кулларын каерып, револьвер түтәсе белән аркасына суккалап алып киттеләр? Хәтерендә: әтисе дә ул чак Хөсәенгә анык кына җавап бирә алмады, карак дип әйтерлек түгел, политический булмагае ул, диде. Ә нәрсә ул «политический», Хөсәен ул кадәресен белми иде әле.

Хөсәен ни өчендер менә шул күптән булып узган вакыйганы хәтерләде. «Менә алайса, — диде ул үз-үзенә, — син инде үзең дә хәзер «политический». Шушы сүзгә бәйләнештә ул яңадан онытылып үзләренең бүгенге эшләре турында уйланды. «Ничек кайтып җиттеләр икән тегеләр? Бер-бер хәвефле хәлгә тарымаган булсалар ярый. Шулай итеп үзебезчә язылган дөреслек сүзләре халык арасына кереп китте диген, ә? Ниләр көтә ул прокламацияләрне?» Ул язулар жандармнар кулына эләксә, Хөсәен ни буласын яхшы белә. Шулай да алар заводтагы эшчеләр, авылдагы фәкыйрь агайлар, шәкертләр кулына эләксә, ни буласын анык кына белми әле. Аңларлармы? Әле бит моңарчы аларның үз телләрендәге прокламацияне күргәннәре юк. Аннары, укыйяза белүче дә бик аз бит бездә. Табып алыр берәрсе, алай боргалар, болай боргалар, бу нинди язу икән дип берәр зыялы байга барыр, я авыл мулласына илтеп бирер! Алар халыкка җиткерерләр дип уйлыйсыңмы син?! Ә инде кычкырып укыган хәлдә дә барлык сүзләр аңлашылырмы соң гади халыкка?

Моңарчы да күп тапкыр уйланса да, теләк гамәлгә ашкач, ничектер күңелгә шик-шөбһәләр туды. Хөсәен чын-чынлап хафага калды. Шундый дәрт һәм ашкыну белән бик күп киртәләрне җимереп башкарылган эш хәзер бернинди уңай нәтиҗә бирмәү куркынычы белән йөрәккә шом сала, билгесезлек газабын тудыра иде.

Прокламация язу эшенә керешкәнче ул беркайчан да туган тел турында ныклап уйланмады. Татар телендә язылачак беренче прокламация исә аңарда яңа тойгылар, яңа фикерләр тудырды. Үз телеңне белми торып, халкыңа нинди дә булса ярдәм итү, аңа хезмәт итү һич мөмкин түгел. Бу кинәт бәхәссез бернәрсәгә әверелде. Хөсәен үзләрендәге барлык татарча китапларны җыеп кат-кат укый башлады. Ләкин, үкенечкә каршы, ул китаплардагы тел прокламация өчен яраклы түгел иде. Яңа әдәби тел, гади халык — эшчеләр, авыл агайлары аңларлык тел кирәк иде. Әйе, булганыннан файдаланып, мөмкин кадәр гади иттереп, әле күптән түгел генә вафат булган Каюм Насыйрича яздылар алар. Гыйльфан соңгы хөкемне чыгаручы булды. Ләкин шулай да... барып җитәрме? Хөсәен үзенең бу соравына җавап бирә алмады. Артык арылган иде, йокы өстенлек алды, тиздән оеп, тирән йокыга талды.

Ул уянып киткәндә, январь кояшы бүлмәнең сул як тәрәзәсе турысына җиткән иде инде. Хөсәен башын күтәрде дә күрше бүлмәдән килгән ят тавышны сәерсенеп тыңлый башлады. Калын һәм чак кына карлыккы тавыш. Үзе болай бик таныш, ләкин һич хәтергә төшми. Кинәт тавышның иясе кем икәнлеген хәтерләде, куркынып урыныннан сикереп торды. Күрше бүлмәдә Хөсәеннең әнисе белән сөйләшеп утырган абзый

полицейский, халык арасында «Бутышник Гайнулла» дип йөртелә торган кеше иде. Җене сөйми иде Хөсәен шуны. Гөнаһ шомлыгына каршы, әтисе үлгәннән бирле нәләште бит шул. Узышлый, хәл белеп чыгыйм дигән булып, көн саен керми калмый. Хөсәен аны моңарчы күрмәмешкә салышты, һәрхәлдә, аның күзенә бик чалынырга теләмәде. Ә бүген менә, шундый көнне, ни пычагыма дип кергән ул? Әллә, булмаса, төнге эшнең эзенә төшкәннәрме? Шуны сизенеп кергәнме?

Хөсәен артык тавышланмыйча гына киенә башлады. Чәй эчәләр. Бутышник ух-пух килеп шапыр-шопыр эчә. Күрәсең, әле генә тәлинкәсендәге чәен чөмереп бетерде ул, чөнки тамак кырып сүз башлады:

— Мәрхүм Минһаҗ абзыйны әйтәм әле, — дигән сүзләре ишетелде. — Урыны җәннәттә булсын, бик тә юмарт, бик тә миһербанлы кеше иде. Беркөн шулай частька барам, пристав янына. Очрады бу. Карале, Гайнулла, ди, синең, ди, бар жирең дә килгән, син урыс жандармнарыннан бер ягың белән дә ким түгел, мыек шәп, итек тә сырлы, йодрыклар да һәрберсе бала башы шае, тик синең корсак кечерәк, ди. Безнең милләтнең абруе арта төшсен өчен шуны бераз үстермисеңме, ди...

Гайнулла кәефләнеп кеткелдәп көлеп җибәрде.

— Мин әйтәм... Хе-хе-хе... мин әйтәм, Минһаҗ абзый, безнең эш бик матавыклы бит, күп йөгерергә туры килә, халык тәмам бозылды, мин әйтәм, аннан килеп, мин әйтәм, Минһаҗ абзый, мин бит алай сезнең кебек бай кеше түгел. Син шуны гына әйт, корсагыңны үстерәсең киләме? — ди бу миңа.

Будочник тагы, тыела алмыйча, сыгып чыгаргандай чыелдатып, сызгыртып көлеп җибәрде.

— Мин әйтәм, как же, үзебезнең мөселман агайне өчен мин тырышыр идем кулдан килсә, дим. Мәрхүм, инде син шуны телисең икән, ди, будкаңда утырып туңа башласаң, я булмаса, тамагың кибә башласа, тот та үземә кер, мин өйдә булмасам да. Бибифатыйма абыстаң үзеңне кунак итеп чыгарыр, ди, шулай әкренләп максудка ирешербез, милләт хур-рисвай булмас, ди.

Бу юлы Хөсәен чәй эчеп утыручыларның икесенең дә көлгәнен ишетте.

— Мәрхүм, бик шаян, шук телле иде шул, — дип куйды Бибифатыйма.

— Юмарт ие, юмарт ие, — диде Гайнулла, — урыны җәннәттә булсын. Кырыгын бик әйбәт уздыргансыз икән, бөтен мәхәллә шаулашты.

— Булдыра алганча тырыштык инде.

— Ярый, ярый, бик тә изге эш эшләгәнсез.

— Әйдә, ашап-эчеп утыр әле, Гайнулла. Әнә вареньесы белән эч.

— Бер дә, бер дә галәмәт икән инде вареньесы. Үзегез кайнаттыгызмы?

— Киленнем, кызым. Үземә алай бик эшләргә бирмиләр. Аллага шөкер.

— Собханалла, собханалла, бик тә унган икән киленегез. Бик тә әйбәт инде, ходай үзләренә әйбәт тормыш бирсен.

— Рәхмәт изге теләкләрең өчен.

— Изге теләк дип, мин аны теләмәс нем дә бәлкем, тик бит, Бибифатыйма абыстай, яшьләр сәвсим бозылды. Чыгырыннан чыкты хәзер яшьләр.

— Шулайдыр инде, сезгә, ил уртасында торгач, күренә торгандыр. Тик минем үземнең балаларым, әлхәмделилла, хәзергә тәүфыйклы.

— Улың Хөсәен дә тәүфыйклы инде синең, — диде полицейский. Хөсәен шунда кашларын җыерып башын күтәрде. Аңлашылмады: Гайнулла бу сүзләрне сорау рәвешендәме, әллә расллапмы әйтә иде.

— Ходайга шөкер, — дип куйды Бибифатыйма. Бер мәл тынып сүзсез утырдылар, бары будочникның бик тәмләп лач-лоч ашаганы һәм шапыр-шопыр чәй эчкәне генә ишетелә иде.

Гайнулла тагы сүзгә кереште. Ул Хөсәеннең хатыны белән кызыксынды. Аның әле этиләре янына Чистайга китүен белгәч, сүзне бүтәнгә күчереп, серлерәк тавыш белән киңәш итте:

— Шулай да, Бибифатыйма абыстай, улыгызга бер ук күз-колак булыгыз. Яман юлга кереп китмәгәе, студиннар, рилүтсианирлар бик узына башлады. Инде алла берүк үзе сакласын, бердәнбер карап торган улыгыз шундый юлга кереп китмәсен дим.

— Нигә алай дип әйтәсең, Гайнулла, андый-мондый сүз юктыр ич? Хөсәен киенгән иде инде, ишеккә бөтенләй якынаеп, колагын ярык турысына куйды.

— Син бел дә мин бел инде, Бибифатыйма абыстай, май кап,— диде Гайнулла.

Хөсәен әнисенең куркынып сораганын ишетте:

— Нигә алай дисең, Гайнулла, барысын да әйт, әллә берәр хәл булдымы?

Йөрәк урыныннан кубардай булып авырттырып тибә иде. Шулай ук барысы да җилгә очты микәнни, капканнар микәнни?! Алай дисәң?.. Хөсәен ни уйларга да белмәде, ләкин күп төрле юраулары арасында ул үзенең әнисе турында фикер йөртергә өлгерде. Шик юк, әнисе барысын да сизенеп тә, күреп тә белә. Шик юк, ул кичә иптәшләр белән нишләп утырганны да белә. Ләкин... кара син аның тынычлыгын! Рәхмәт, әни!

Бутышник тагы сүзгә кереште:

— Мин Хөсәен турында сиңа, Бибифатыйма абыстай, кистереп кенә берни дә әйтмим. Гөнаһыга керәсем килми, алла сакласын. Тик шулай да...

— Ийе. Я, я?

— Тик шулай да... менә шушы тирәдә ниндидер фетнәчеләр әзе югала.

— И-и, дөньяда булмаганны! — дип куйды Бибифатыйма. — Монда нинди фетнәчеләр булсын, ди!

— Ә күршеләрне дә беләм дисең инде син, Бибифатыйма абыстай?

— Барысын да беләм, ходайга шөкер. Бик тә әйбәт кешеләр.

— Шулай дисең дә син, Бибифатыйма абыстай, тик әйтсәм әйтим инде, моны син бел дә мин бел, артыгын сорама, май кап...

Гайнулла икеләнгәндәй тынып торды. Хөсәен, тынын кысып, колагын ишек ярыгына якынлаштырды. Әле моңарчы мич янындагы сандыкта бит юып утырган мәче кинәт идәнгә сикереп төште. Ул Хөсәен янына килде дә, ачу китереп, ишекне ач дип кычкыра башлады. Хөсәен чак тайпылып өлгерде, кемдер теге яктан ишекне ачып җибәрде.

Бу Хөсәеннең әнисе иде. Бибифатыйма песигә сөт салып бирде, иркәләп дәште, аннары:

— Мәче аркасында сүзеңне бүлдердем, Гайнулла, — диде, — әллә нәрсә сөйли башлаган идең.

— Әйтергә җыенганым шул, Бибифатыйма абыстай, түлке май кап. Бүген иртәнге якта минем будкама мөселманча язылган прукламация ябыштырып киткәннәр. Әйләнеп кайтып керсәм, халык җыелган. Араларыннан бер шәкерт сыманы кычкырып укый, калганнары авызларын ачып тыңлап торалар. Бу ни эш бу? Бу нинди нарушение порядка, мин әйтәм! «Кил әле, Гайнулла абзый, үзең дә тыңлале, бик дөрес сүзләр язылган икән бу язуда», — ди берсе. «Көфер сүз түгелме, тәртип бозу түгелме, закон кушканчамы?» — мин әйтәм. Тыңлап баксам, Бибифатыйма абыстай, җанашым, чәчләрем үрә торды. Патшаһыгызам хәзрәтләренә тел тидергәннәр, байларны да, муллаларны да хурлаган-

нар. Теге имансыз рилутсианирлар сүзен тач үз телебездә язганнар да куйганнар. Ә халык тыңлый, халык бит ул тинтәк, авызын ачкан да ышанып тыңлый. Аллага тапшырдык, мондый биспурәдекнең әле минем кварталда булганы юк ие. Түлке, Бибифатыйма абыстай, берүк май кап, кешегә әйтәсе булма.

Хөсәеннең ирексездән күңелен куаныч рәхәте җылыта башлады. Кичәге авыр кичерешләр, шик-шөбһәләр күңелен әле дә таш кебек басып тора иде аның. Ә хәзер исә шул авыр таш будышник әйткән хәбәрдән соң мамыктай җиңеләеп китте. Гайнулланы полицейский булганы өчен һәм шул ук вакытта, бик диндар булып кыйланганы, мәхәллә халкы арасында иснәнеп йөргәне, ришвәтчелеге, гайбәтчелеге һәм байлар тәлинкәсе яларга яратканлыгы өчен җаны сөйми иде. Хөсәен аның һәрвакыт аракы исе килеп торган, кызыл борынлы, тырпайган мыеклы йөзеннән җирәнә иде. Бүген исә шул котсыз кеше, Хөсәеннәр баскан прокламация турында сөенче алып, кинәт ягымлы бер адәмгә әйләнде. Хөсәен булган һәм булырдай хәлләрне күз алдына китерде. Димәк, «товар» хәвеф-хәтәрсез тиешле кешеләренә тапшырылган, димәк, иптәшләр иртәнге сәгатьләрдә үк аларны эшкә җибәргәннәр. Нинди әйбәт нәтиҗә! Димәк, укыйлар, кызыксыналар.

Хөсәеннең күзләре нурланып китте. Ул бер мәл: «Әллә тегеләр чәй эчеп утырган якка чыгып будочникның кулын кысаргамы», — дип тә уйлады. Ләкин бу беренче тойгы гына иде. Хөсәен, шатлыклы уйлар белән булашып, Гайнулланың чыгып китүен көтте.

## Фәрхетдин

Якты, җылымса иртәләрнең берсе иде. Хөсәен тәрәзә пәрдәләрен ачып җибәрде. Өйгә сулышны җиңеләйтә торган рәхәт май һавасы керен тулды. Капка келәсе чынлап куйгандай булды. Әллә Гыйльфан килдеме? Хөсәен тәрәзәгә ташланды. Ләкин өмете акланмады, зарыгып көткән кешесе һаман күренми иде. Ул яңадан өстәл янына килеп утырды. Тагы кулына каләмен алды. Туктале, нигә килеп җитми соң ул? Сәгать тугызынчы ярты бит инде.

Хөсәен иртә белән үк килергә тиешле Гыйльфан турында тәшвишләнеп уйлана башлады. Ул чормадагы прокламацияләрне алып китәргә тиеш иде.

«Гаҗәп, гаҗәп, — дип куйды Хөсәен, язуын бүлеп, — әллә эзенә төшеләрме, әллә кулга алдылармы?» Ул капка келәсе шалтыравын ишетеп сагаеп башын күтәрде. Кара куе кашлары бердән күтәрелде. Хөсәен тиз генә торып тәрәзәдән ишек алдына үрелде. Ләкин йөзендәге өмет яктысы шундук сүнде, чөнки капкадан керүче бөтенләй ул көткән кеше түгел иде. Хөсәен, инде хәзер ни дип уйларга да белмичә, шул билгесез кешене күзәтә башлады. Авыл кешесе иде теге. Башына кигән белендәй түбәтәе ни тора да, киндер күлмәк белән буй-буй кызыл ыштаны ни тора! Ә билдә әле, җитмәсә, алъяпкыч. Ул капканы ачып, кача-поса гына ишек алдына керде һәм, тагы кемнәндер ян шерен еп, өй стенасына сыенды. Хөсәен ишек алды ягындагы тәрәзәгә килгәндә, ул бөтенләй күренми иде инде. Почмактагы зур роза гөленнән тып итеп идәнгә чәчәк төште. Хөсәен әле кичә генә шул табигать могҗизасының гүзәллегенә сокланып торган иде. Бер секунд эчендә аның башыннан шулар узды. Иелеп, идәндә яткан кып-кызыл, йомшак, салкын чәчәкне кулына алды. Шул арада әлеге кеше ишек алды уртасына узды. Анда бауга эленгән керләр җилберди иде. Нишли ул? Кеше, Хөсәенне аптырашта калдырып, шул керләргә үрелде. Хөсәен, кызыксынудан һәм аптыраудан сулышын кысып, урыныннан кузгала алмый-

ча, һаман тәрәзәдән карап торды. Тегенең максаты керләрне чәлдереп китү иде, ахры. Чыннан да, бераздан ул ашыга-ашыга керләрнең затлырагын алъяпкыч изүенә тутыра башлады. Алгы бүлмәдән хезмәтче кыз Нәкыянең чәрелдәп кычкырганы ишетелде:

— Керләрне урлыйлар бит, карасана, Хөсәен җаным!!

Ашыгып Хөсәен янына әнисе Бибифатыйма да килеп керде:

— Улым, улым, кара әле...

— Күрәм мин аны, әни, баядан бирле карап торам.

— Соң бит, ул йөзе кара чыгар да чабар.

Хөсәен мыек астыннан гына көлемсерәп куйды.

— Бик ерак китә алмас.

Шулай да ул, әнисенең сүзен тыңлап, утыргыч аркасына эленгән пиджагына үрелде.

Бибифатыйма белән Нәкыя аның ишек алдына чыкканын тәрәзә аша күзәтә башладылар. Менә Хөсәен ишектән чыкты. Сиздермәстән генә йөгерә-атлый карак каршысына барып басты. Күзәтүчеләргә угрының куркудан шашып өнсез калуы ачык күренә иде. Хөсәен аңа нидер әйтте. Тегесе дә җавапсыз калмады. Күп тә үтмәде, Хөсәен белән карак, шактый тыныч сөйләшкән хәлдә, баудагы керләрнең кипкәннәрен сайлап ала башладылар. Нәкыянең бәләкәй соры күзләрендә әйтеп бетермәслек гаҗәпләнү чагыла иде. Күрәсең, карак дип уйлаган кешеләре берәр таныш-белеш булып чыкты.

Бибифатыйма да, Нәкыя дә тынычланып кухня якка чыгып киттеләр. Баскычтан тегеләрнең менгәне ишетелде. Ишек ачылып китте һәм яңа кипкән керләрнең әйбәт исе бөтен алгы якны тутырды. Хөсәен белән кергән кеше коңгырт күзле, какча бер авыл егете иде. Керле ябык йөзе, нурсыз күзләре аның авыр тормыш сөргәнлеген әйтеп тора иде. Килеп керү белән, егет, каушый төшеп, ишек янында туктап калды.

— Әйдә, әйдә, атла. Ник шүрлисең? — диде Хөсәен, кырыс кына. — Керләрне изүеңә тутырганда бик батыр идең бит!

Хөсәеннең йөзендә хәйләкәр елмаю балкый, кара күзләрендә очкыннар уйный иде. Карак тотлыга-тотлыга аңа карап сүзгә керешге

— Бай абый, бай абый, дим. Алла хакы өчен хур-рисвай итмә инде. Зинахар дип әйтәм, кичер инде. Нужа кушканнан килеп чыккан бер гөнаһы инде бу.

Егет, тавышка чыккан Бибифатыйма каршысына ашыгып барып, кинәт тез чүкте дә еламсырап ялвара башлады:

— Олы абыстай, дим, олы абыстай!..

Хөсәен аны иңнәреннән тотып идәннән торгызды.

— И бичара, — диде Бибифатыйма, егетне әрләп, — мөселман башың белән караклык юлына бастыңмыни?! Ахмак!

Нәкыя дә сүзсез калмады, чәрелдәп егетне хурлый башлады:

— Оятсыз бәндә! Кем әйберенә кулыңны сузганыңны беләсеңме, җир бит, мужик?! Үзең ябь-яшь кеше күренәсең. Тфү!

Егет хәзер еларга ук керешгте. Пычрак куллары белән яшьле күзләрен сөртеп:

— Зинахар дип әйтәм, бер юлга кичерегез инде, апай, абыйлар! Нишлим соң инде? Нишләргә дә белгән юк бит! Ачтан үлеп тә булмый. Хәер эстәсәм — бирүче юк. Юкса, мин дә начар ата баласы түгел идем. Зинахар, денебез хакына кичерегез инде.

— А-а, дең исенә төштемени, зимагур?! — диде Нәкыя. Егет чынчынлап балавыз сыга, һаман куллары, күлмәк җиңнәре белән күзен сөртеп мышкылдый иде.

Хөсәеннең күңелен сызып кызгану хисе узды.

— Ашарыңа юкмы, ач калдыңмы?

Егет сүзсез генә баш какты.

— И-и, ышанма аның сүзенә, Хөсәен,— диде Нәкыя, сүзгә тыгылып, — андыйлар эләккәч һәнүз шулай кыйланалар.

— Туктале, Нәкыя, — диде Хөсәен, кашларын җыера төшеп, — мин үзем иплэп сөйләшим әле. Әйт әле, туган, син безнең шушы кат-кат уылган кериәрне алып мохтаҗлыктан котылырга исәпләденмени? — Хөсәен өстәлдә яткан керләргә төртеп күрсәтте. — Ал, кайсысы ошый сиңа, сайла да ал.

Егет бер агарынып, бер кызарынып мыгырданды:

— Аллам сакласын, инде үтерсәң дә алмыйм, бай абый... Мин бит ни... — Ул тагы мышкылдап елап җибәрде.

Хөсәен, аның җилкәсенә кулын куеп:

— Сал чабаталарыңны! — диде.

Егет, тәмам аптырап һәм тагы да курка төшеп, сорау белән яшьле күзләрен Хөсәенгә текәде.

— Сал, — диде Хөсәен, әмер иткәндәй, — эчкә уз!

— Безгә берәр чынаяк чәй бирегезче, — диде Хөсәен хатыннарга. Егет ашыгып мыеклы чабаталарын салырга кереште.

— Кай яктан? — дип сорады Хөсәен, егет бер чабатасын салып ишек янына куйгач.

— Әй, бай абый, кай як кешесе икәнне дә оныткан инде мин, — диде егет, җепшеп киткән борынын сөртеп. Хөсәен мыек астыннан гына елмаеп куйды. Каһәр, үзенә чәй эчерәм дип торганда да ышанмый әле, «бай»дан һаман шикләнә иде.

Егет чабаталарын салып ишек янына куйгач, Хөсәен аңа кул юарга кушып, мич артындагы комганны күрсәтте.

— Монда гына эчмисезме соң? — дип калды Нәкыя, күңелсезләнеп.

Юк, кирәкми. Хөсәеннең әле остарып җитмәгән сукбай белән аулакта гына сөйләшәсе килә иде.

— Исемең ничек? — диде Хөсәен эчкә кергәч. — Анысын да онытмадыңмы әле?

— Исемебез Фәрхетдин була, — дип мыгырданды егет. Ул күзләре белән ашардай булып зал эчен капшый иде. Зур бүлмәнең аңа искитмәле булып тоелуы ачык. Пыяла ишекле шкафлар, йомшак кәнәфиләр, шау чәчәктә утырган гөлләр аңа җәннәт җиһазларыдай күренде. Тәрәзә пәрдәләрен генә карасана! Ә сәгате соң, сәгате! Бүлмәгә килеп кермәделәр, адәм буйлык сәгать бөтен өй эчен яңгыратып суга башлады, сугудан туктал уы булды, нинди дер гүзәл авазлар чыгарып, Фәрхетдин гомерендә дә ишетмәгән көй уйнап алды әле, җитмәсә.

Егет хәйран калып, башын селкеп куйды.

— Рәхим ит, утыр, — диде Хөсәен, өстәл яныннан урын күрсәтеп.

Егет, ишек янындагы идән тактасына ялан тәпиләрен ышкып торганнан соң, батырчылык итеп хәтфә келәмгә таба аягын сузды. Өстәл янына утырырга да күнеккән кеше түгел иде ул. Монысы да аңа шактый сәер тоелды. Күп тә узмады, Нәкыя поднос белән чәй, шикәр, кош теле китерде.

— Ипи белән атланмай да китер, Нәкыя, — диде Хөсәен.

— Җитеш, — диде ул Фәрхетдингә, барлык кирәк нәрсәләр өстәлгә килгәч.

Фәрхетдин, тыела алмыйча, нидән башларга икән дигәндәй, табынга карап алды. Аннары тәвәккәлләп икмәккә үрелде. Зур бер телемне ике куллап тотты. Сындырганда валчыгы коелып әрәм булмасын дип сакланып кына эш итте. Бал калагы белән каерып маен да алды, умырып икмәкне тешләде, авыз тутырып лач-лоч чәйни башлады. Дөнья рәхәтлекләре шушы иде инде егет өчен! Хөсәен Фәрхетдиннең шундый зур бер ләззәт һәм комсызлык белән, күзләрен йома төшеп ашавын күрмәмешкә салышты. Гыйльфанның килмәве ачык инде хәзер. Чөнки

сүз куешу буенча, әгәр ул унынчы яртыга килеп җитмәсә, Хөсәен прокламацияләрне озату чарасын үзе күрергә тиеш.

Хөсәен, Фәрхетдин каршында чынаяк тотып утырган килеш, шуларны да башыннан кичерергә өлгерде, ә үзе ач егетне күңеле белән күзәтүендә булды. Кара инде син бу бичараны! Үзе ояла, үзе комсызланып ипи белән май сутә. Яңаклар ач, күзләре эчкә баткан. Моның җүнләп ашамаганына ничә көн икән?

— Әнә бавырсагыннан җитеш, — диде Хөсәен, — монысы тәмлерәк.

— Ярый миңа ипие дә, — диде Фәрхетдин, тагы икмәккә үрелеп. Хөсәен ирексездән көлеп җибәрде. Фәрхетдин кинәт ашавыннан туктады да, куркынып:

— Абый, син миннән көләсеңдер инде? — диде.

— Ашавыңны бел. Мин синең нинди хәлгә төшкәнлегеңне аңлыйм, — диде Хөсәен.

— Бәхеткәең булмаса, берни эшләр дә хәлең юк икән шул, абый. Кеше сөйләгәч, җуләрләнеп, атлык акча әтмәлләп булмасмы дип Казаныгызга килгән булган ием. Тик миңа дигән өлешне калдырмаганнар икән шул монда.

— Эш таба алмадыңмыни?

— Эшен тапкан ием дә, хуҗа үземне куып чыгарды. Атка камыт суктыргансың, дип, нахак бәла такты миңа. Атка берни булмаган, ниндидер үчен миннән шулай кайтармакчы була.

— Алай икән. Ломовой булып ялланган идеңмени?

Фәрхетдин чынаяк тәлинкәсеннән чәй чөмерде дә:

— Анысын табын алдында әйтмим инде, абый. Яман нәрсә ташыдым, — дип куйды.

— Алай икән, — диде Хөсәен, аңлап, — менә минем сүз сиңа шул, Фәрхетдин, көнлекче булып йөрсәң йөр, иллә мәгәр караклык белән кеше була алмассың.

— Аллам сакласын, — диде Фәрхетдин, куркынып, — моннан соң, башны тиле-милегә салып, Болак күпере өстендә хәер эстәсәм эстим, тик кеше малына кулымны сузмам. Ничек тә Әлмәткә кайтып җитәрлек ризык юнәтермен әле.

— Хәер эстәү инде, туган... анысы да егетлек түгел! Нәрсә дидең, Әлмәткә кайтырга дидеңме?

— Әйе, Әлмәткә, минем авыл Әлмәт волысында. Нәдер авылы. Ишеткәнең бармы?

Хөсәен үзалдына елмаеп куйды.

— Нәрсә, әллә безнең Нәдерне беләсеңме? — диде Фәрхетдин, сәерсенеп.

— Бераз беләм.

Хөсәеннең күе керфекләрен сирпеп тагы мыек астыннан елмаеп куюы шикле тоелды, ахры, Фәрхетдин ашавыннан ук туктады.

— Син үзең Нәдердән түгелдер бит?

Хөсәен аңа Нәдердән түгеллеген, ләкин анда булганлыгын, бертуган сеңелесенең Әлмәттә яшәгәнлеген әйтте.

Егеткә бу артык кызык тоелды. Белмәссең, әллә, бәлкем, Фәрхетдин бу байның сеңелесен күреп тә белә торгандыр әле. Белмәссең, мондый танышлык аркасында, әллә, бәлкем, бай абзый берәр яхшылык та эшләп куяр? — дигәндәй иде аның карашы.

— Кем була инде синең сеңелең? — дигәнен Фәрхетдин үзе дә сизми калды. — Мин бит ул Әлмәттә булмаган кеше түгел...

— Нәдер бае Якуб Ильясовларны беләсеңме?

— Ник белмәскә, бик беләм.

— Белсәң, менә шул Якуб байда кияүдә минем сеңел.

Хөсәен бу хәбәрне ничектер күңелсезләнебрәк әйтте. Ул текәп Фәрхетдингә карамады да. Хәлбуки, тегенең йөзе, Якуб бай исемен

ишеткәч, үзгәреп киткән иде. Бер секунд эчендә Фәрхетдиннең башына булып узган вакыйгалар килде. Әле күптәнме соң ул шул Якуб байда ялчылыкта торды. Алар Хафаза белән өйләнешкәч тә тормыш корып җибәрергә, өй салдырып башка чыгарга мөмкинлек булмасмы, дип, икәүләшеп шул Әлмәт баена ялчылыкка керделәр. Елына икесенә алтмыш сум акча вәгъдә итте бай. Ләкин бу акча яңа семья корып җибәргән яшьләргә насыйп булмады. Чөнки эш тавык чүпләп бетермәслек күп булып чыкты. Хафаза да, Фәрхетдин дә самовардагы шәүләдәй кибеп ябыктылар. Шул байда чакны Хафаза бер кыз бала тудырды. Ләкин бичараны имезерлек тә вакыты һәм тазалыгы булмады. Бала ачтан үлде. Иң фаҗигалесе шул: Хафаза, бердәнбер газиз баласы үлгәч, куллары бушап калуына куанган кебек булды. Фәрхетдиннең исә яман ачуы килде, ул исәпне өзмәде, көннәрдән беркөнне үзен һәм хатынын шундый көнгә калдыруы өчен байга үч итеп, карт байның үзе генә тышка йөри торган комганына кызыл борыч сипте дә Хафазасын ияртеп, Нәдергә качты. Ләкин Фәрхетдиннең байга кирәге шулкадәр генә иде, ахры, аңа ялчы табылмый дисеңмени! Соңыннан үзе алай берни дә булмады...

Алай икән! Бу — үзен чәйләр белән сыйлап юмартлык күрсәткән бай Якубның кодасы икән! Фәрхетдин хәзер Хөсәеннең серле елмаюларын да хәерлегә юрамый иде. Димәк, ул аны белә икән. Ә теге Якуб байның хатыны дигәне кем соң? Шулай, Фәрхетдин барында яшь байның хатыны үлде. Якуб бит тол иде ул чак. Хәер, соңыннан Якуб бай өйләнгән икән, үзеннән күп яшькә кече бер Казан кызын алган икән дигән хәбәр Нәдергә дә килеп җитте.

Баштагы өметләр барысы да берьюлы җимерелделәр. Фәрхетдин кинәт эчен тотты да, йөзен чытып, ыңгыраша башлады.

Хөсәен урыныннан ук сикереп торды.

— Ни булды сиңа?

— И, абый җаным, ашамый ашагач, шулай була икән шул. Гафу ит инде. Оятлы булдым. — Фәрхетдин сикереп торды. Иелә төшеп эчен тоткан хәлдә алгы бүлмәгә чыкты. Хөсәен куркып китте:

— Фәрхетдин, Фәрхетдин!

Ләкин Хөсәен кая барырга кирәклеген әйтер өчен пиджагын җилкәсенә салганда, Фәрхетдиннән җилләр искән иде инде.

## Чи печән исе

Юнусов подворьесы дип йөртелә торган мосафирханәнең коридорларыннан һәрвакыт кыздырылган суган һәм бәвел исе аңкып тора. Анда әледән-әле кыска алъяпкычлы житез половойлар йөгереп уза. Алар, ашамлык өелгән подносларын жонглер осталыгы белән тотып, җәлт иткәнче тиешле бүлмәгә илтеп тапшыралар. Номер ишекләре ачылып киткәндә, аннан бөркелеп тәмәке төтене һәм исерек авазлар чыга. Ул ара да булмый, озын ак күлмәк өстеннән жилет кигән, сәгать чылбырын салындырган юан татар баеның коридордан кикергәләп узганы күренә...

Шулай номер коридорлары иртәдән кара төнгәчә гөжләп торалар. Ишекләр ачыла да ябыла, бер бүлмәгә керәләр, икенчесеннән чыгалар, һәр бүлмәнең үзенә генә хас тормышы бар. Ләкин ул бүлмәләрнең берсендә кешеләр бүген житди һәм гадәти булмаган эш белән шөгыльләнәләр. Бу егерме беренче бүлмәдә шулай. Анда банкет. Казан сәүдәгәре мәрхүм Минһаҗ Ямашевның улы Хөсәен үзенең туган көнен уздыра. Тик аның банкеты да шул ташка үлчим инде. Унбер кешелек

мәҗлескә, ичмаса, ник бер генә шешә аракы булсачы! Белгәннәре — чәй, бер чиләкле самовар белән китерделәр...

Сәгать төнге уникс иде инде. Банкет исеме астында уздырылган түгәрәкнең нәүбәттәге әңгәмә-утырышы бетүгә якынлашты. Сүз күп төрле мәсьәләләр турында барды, ләкин әңгәмәнең үзәгендә һаман бер үк нәрсә торды. Ул да булса — большевиклар белән меньшевиклар арасындагы каршылык. Ничек инде ул бер үк партия кешеләре, бер үк максатлар өчен көрәшүчеләр, шундый җаваплы бер чорда икегә бүленеп, тукмаша башласыннар?! Беренче карашка акылга сыймаслык булып күренгән бу хәл Алафузов заводында эшләүче алдынгы татар егетләрен дә уйландыра иде. Хөсәен белгәнен ахырынача сөйләп бирде. Чәе суынып беткән чынаягын кулына тоткан килеш, меньшевикларның дөреслектә бөтенләй мәсләксез, юлсыз, вак буржуа интересларын төп мәнфәгать итеп алган кешеләр булуын, изүче сыйныфлар тегермәненә белепме-белмичәме су коючылар икәнлеген сөйләп узды. Өстәл тирәсендәге абзыйлар Хөсәеннең һәр сүзен, дөнья күргән кешеләргә хас булганча, үз тәҗрибәләре аша сизеп, игътибар белән тыңлыйлар иде.

Хөсәен аларның күңелләрендә бу авыр тормыштан котылу өметен күптән уяткан иде инде. Ләкин шундый бервакытта бүгенге әңгәмәдә сөйләнгән ызгыш күңел түрендә көйрәгән яктылыкны баса кебек. Шулай ук берни дә барып чыкмас микәнни? Җиргә иңгән алладай үзенә сәҗдә иттерә башлаган бердәнбер якты маяк та үзара талаш аркасында авып төшәр микәнни?! Хөсәен кешеләрнең борчулы йөзләренә карап, ни турыда уйланганлыкларын тоеп утырды. Дәлилләп, нигезләп, мондый көрәш-ызгышның бик табигый икәнлеген сөйләргә керешге. Ленин яклылар, беренчедән, сыйнфый көрәшләрдә чыныкса, икенчедән, алар эчке талаш-ызгышта, бәхәстә чарланачаклар. Ләкин шулай да эшче агайларга җиңел түгел иде. Алар әле үзләре генә калгач ныклап уйланырга тиешләр иде.

Мәҗлес беткәндә, вакыт төнге уникс иде инде. Хөсәен урам аша ашыгып узды да, зур карачкы булып күккә ашкан Дүрт евангелист чиркәве дип аталган гыйбадәтханә почмагыннан борылып, Кабан күленә таба юнәлде. Биткә күлнең дымсу сулышы килеп бәрелде. Кабанда йөри торган бәләкәй пароходлар хәзер причалда. Казан халкы йоклый. Бары Суконный ягындагы өйләрнең кайберсендә генә утлар җемелди.

Хөсәен әле генә номерда үзе белән утырган иптәшләре турында уйланып барды. Үзенең әңгәмә вакытында бер сорауга җавап бирә алмавын хәтерләп ачынды. Хәер, ул сорау башка мәсьәләләр арасында күмелеп тә калды калуын. Тик, ни әйтсәң дә, Хөсәен җавап бирә алмады бит.

Ул юл буена шулай борчылып кайтты. Күл буе мәдрәсәсе янына житкәч, нидер күләгә куркынып чатка посты. Хөсәен, бөтен барлыгы белән күз ачып йомганчы, кысылган пружинадай, киеренке рәвешкә керде. Кем булуы мөмкин бу кешенең? Ул сак адымнар белән бара башлады. Чатка житкәч, ирексездән пырхылдап көлеп җибәрде. «Хәерсез икән! Мин тагы филер дип торам». Чаттагы коймага аркасы белән сөялгән кеше, тәгаен, гыйшык-мәгъшук хәлләре белән йөрүче Күл буе мәдрәсәсенең берәр шәкерте иде. Хөсәен озакламый үзләренең Екатерински урамына таба борылды.

Әтисе үлгәннән соң, әнисе атларны саттырды. Хәзер инде түр өйдә торучы Шәфигулла абзыйның кирәге калмады. Мәгәр ул күчәр җире булмаганга күрә, Хөсәеннәрне ташлап китмәде. Бибифатыймадан түләү хакы урынына йортыгызны саклармын, кирәге булганда, йорт эшләрегезне дә эшләрмен, дип фатирда калдыруын үтенде. Капкадагы звонок чыбыгы шулар өенә тартылган иде. Ләкин Хөсәен бүген аларны борчый алмый иде. Ул, капкага житү белән, тирә-юненә карап

алды да тиз генә койма аша төште. Әнә аны хатыны Хәдичә дә көтеп утыра, кысып куелган лампаның тонык шәүләсе сирпелә. Хөсәен, өс киемен каккалагач, тәрәзәгә ясмык чаклы гына таш җибәрде. Күп тә узмады, Хәдичә лампа пилтәсен күтәрде.

Хатыны аны күптән борчылып көтә иде инде. Хөсәен ашыгып баскычтан менде, хатынына бер-ике җылы сүз әйтте, тик өйгә керү белән аштан баш тартып, китап, брошюралар актарырга тотынды. Әйе, ул барысын да аңлый, Хәдичәнең игътибарсызлыкка хәтере калганын да белә, ләкин башка чарасы юк иде Хөсәеннең. Ул җавап тапмый торып тынычланмаячак.

Ниһаять, үзенең китаплары арасында баягы сорауга җавап юклыгы билгеле булды. Димәк, кемнеңдер ярдәменнән тыш Хөсәен үзе генә хәл итә алмый.

— Шуның белән бетте, Хәдичәкәй, — диде ул, аягүрә басып. Хатын бер сүз дә дәшмәде. Киресенчә, тиз генә караватында борылып, стенага карап ятты. Хөсәен, мыек астыннан гына елмаеп, башта китапларын урнаштырды, аннары йоклаган булып күренү өчен тешен кысып дәшми яткан Хәдичә янына барды. Башта ул караватт читендә, ниндирәк бер кызык эшлим икән дип, тын гына уйланып утырды. Ниһаять, мендәрдән чыгып торган йомшак кына йон алды да шуның белән Хәдичәнең кечкенә генә ап-ак матур колагын кытыклап куйды.

Күрәсең, хатын башта моның Хөсәен эше икәнлеген аңламады, апак кулы белән чебен куып маташты. Шулай да ул күз кырые белән генә ирен дә шәйләп алырга өлгерде, ниһаять, рәнҗү тулы зур коңгырт күзләрен Хөсәенгә текәде.

— Нидер әйтмәкче буласыңмы?

— Әйе, Хәдичәкәй, — диде Хөсәен, — мин бит сине сагынып кайттым. — Аның кара күзләре елмаюдан кысылып җемелди, йөзенә, арталчыгудан бигрәк, дуслык билгеләре чыккан иде.

Хәдичә, никадәр каты бәгырьле булып кыланмасын, көче җитмәде, йомшара төште.

— Соң, сагынгач, нигә... — дип, сүзеннән бүленеп калды. Аның да күзләре хәзер хәйләкәр елмаю белән балкый иде.

Хөсәен аны шундук үзенә каратып яткырды, кочаклады да суырып иреннәрен үпте. Хәдичәнең барлык кинә саклаулары шундук юкка чыкты. Ул бармак бите белән генә Хөсәеннең кыска итеп калдырып кырылган кара нечкә мыегын сыпырып куйды. Әйе, Хөсәен Хәдичәнең бик тыныч һәм иркәләнгән чагында гына шулай иткәнен белә. Бу аның сәер бер гадәте.

Хәдичә белән, теге сорауга җавап эзләү аркасында килеп чыккан, хәл җайланды, хәлбуки Хөсәен иртәгесен йокыдан уянгач та шул сорау турында баш ватып ятты әле. Ул ирексездән Андрей Степанович Кулешаны хәтерләде. Аның квартирасында берничә тапкыр булганы бар иде инде Хөсәеннең. Әле хәзер, аның турында уйлагач та, кичекмәстән шуңа барырга булды.

Иртәнге чәйдән соң ук Хөсәен киенеп чыгып та китте. Балык базарына җитте, аның шау-шулы мәйданын узып, Собачий тыкрык буйлап тауга таба менә башлады.

Кулешаның өенә якынлашкан саен, ул игътибарын көчәйтә барды, тирә-юньне ныклап күзәтте, хәтеренә барын да төшерергә тырышты. Менә алар моннан бер ел элек бергәләп шулай тауга менделәр. Кулеша Хөсәенне кисәтеп куйды. Артыннан өзлексез күзәтеп йөрүләрен, шуңа күрә килергә туры килсә, туп-туры капкадан керергә ярамаганлыгын, ә ике йорт аша узып, аннан коймадагы кечкенә капка аша керергә кирәклеген әйтте. Анда арткы койманың ике тактасы каерылган, капка дигәнем шул, диде. Алар шул юл белән кайттылар ул чакта. Ләкин ул вакыт көзнең караңгы төне иде. Ә хәзер бару ахмаклык булмасмы

соң? Хәер, иртәнгә якта филер тынычрак була, көндезге якгыга ышана ул.

Хөсәен, кайчандыр Кулеша өйрәткәнчә, өченче йортның ишек алдына керде. Теге вакытны бу ишек алды ничектер тар һәм кечкенә булып күренгән иде, баксаң-күрсәң, бөтенләй иркен икән. Хөсәен кечкенә генә капка янына килеп житте. Ул бер мәл икеләнеп торды. Монда бит теге чакны капка-фәлән юк иде. Ләкин килгән юлыннан кире борылу да мөмкин түгел. Ул, бер секунд эчендә барын да исәпләп, катгый карарга килде дә тәвәккәлләп капканы ачты, күрше ишек алдына чыкты. Ләкин ул, бик яхшы белсә дә, сул якка, Кулеша квартирасына борылмады, туп-турыдан суктырып, каршыдагы сары агач өйгә таба китте. Күзенә алдагы тәрәзә пәрдәсенең җилбердәп куюы чагылды. Сүз юк, капкадан чыккан һәр кешене сулга борылмасмы бу дип күзәтүче шунда утыра иде. «Бик күңелсез хезмәт, — дип уйланды Хөсәен филер турында, — көне буе шул тәрәзә янында утырып күзәт инде». Ләкин шулай да, ничек тә килгән-килгән, бу күзәтүчеләрне төп башына утыртып, Кулеша янына керәсе иде бит.

Кулеша торган йортның планын Хөсәен хәзер анык күз алдына китерә иде инде. «Димәк, болай, — дип фикер йөртте ул, — йортның капкасы күптән күзәтү астында, теге вакытны йөргән юлга хәзер капка ясалган, ул да күзәтү астында. Карап карыйк, янәшә арт ишек алды ничек икән?»

Хөсәен икенче урамга чыгып торган арт ишек алдының түрендәге ябык лапаска кереп китте. Ишек алдында атлар, авыл агайлары калды. Карамадылар да. Күрәсең, биредә һәрвакыт шулай авыл кешеләре куна керәләрдер һәм бөтен ишек алды шуңа җайлангандыр. Хөсәен атлар һәм нинди дер иске фаэтон, тагараклар торган, чи печән исе аңкыган лапасның арткы стенасы янына килде. Һа! Монда барысы да Хөсәен теләгәнчә эшләнгән икән ич! Ул караңгы почмакка кереп, какшаган тактаны бик ансат кына күтәрде дә ярык аша күрше ишек алдына керде. Каршыда гына Кулеша яшәгән флигель күренде. Хөсәен шул бәләкәй ялгыз өйнең бәдрәфе янына ук килеп чыкты.

Бераздан инде ул сакланып Кулешаның өй ишеген шакылдата иде. Әлбәттә, шул минутта ук ачмаячаклар. Хөсәен моны белә. Шулай да бераздан соң хатын-кыз тавышы килде.

— Ачыгыз, бу мин — Ямашев, — диде Хөсәен.

— Кем, кем? — диде хатын. Ләкин Хөсәен җавап бирел өлгермәде, эчтән ирләр тавышы ишетелде. Бу, тәгаен, Кулеша үзе иде.

— Бу мин, иптәш Кулеша, мин, — диде Хөсәен, пышылдап.

Ул арада ишек ачылды һәм ярым якты өй алдында мәһабәт буйлы, яшь булса да чәче коелган, киң, ак йөзле, ачык йөзле Кулеша күренде. Ул, тиз генә Хөсәенне өй алдына кертеп, ишекне бикләде.

— Нәрсә булды? Сез белмисезмени?..

— Исәнмесез, — диде Хөсәен, аның кулын тотып, — миңа сез кирәк идегез.

— Соң бит кирәк булсам, пассажда яки редакциядә вакыт билгеләргә була. Мин бит сезгә үземнең квартираның күзәтү астында икәнлеген әйттем.

— Борчылмагыз, мин юлын таптым, мине беркем дә күрмәде.

— Ә бит теге юл да хәзер күзәтү астында.

— Беләм. Мин бөтенләй яңа юл ачтым, Андрей Степанович.

Хөсәен сөйләп бирде.

— Менә җен! — дип куйды Кулеша ачусыз гына. — Керегез әйдә, узыгыз.

Өйгә кергәч тә кухня, сул якта бер кечкенә генә бүлмә, эчтә, түр якта тагы кечкенә генә ике бүлмә бар иде. Борынга сарымсак исе һәм тәмәке төтене килеп бәрелде. Гөлләр белән тулган түр як бүлмәдә

тәмәке төтене аерата куе иде. Хөсәен чишенеп әчкә узгач, зәңгәр клеенка җәелгән буш өстәлгә күз атты, ләкин анда көл савыты юк иде. Хөсәен шунда ук бу өйдә тагы бер кеше булырга тиеш дип уйланды. Мөгаен, ул ишек шакылдатканны ишеткәч тә яшеренгәндер, үзе белән көл савытын да алып чыгып киткәндер. Һәм чыннан да, Хөсәеннәр утырышкач, хуҗа түр яктагы бәләкәй бүлмә ишегенә карап:

— Володя, чык әле! — дип кычкырды.

Хөсәен ишек ачылганын көтте. Аннан кулына кәгазьләр, ниндидер брошюралар һәм пыяла көл савыты тоткан мыеклы яшь кеше килеп чыкты. Ул хуҗадан буйга әз генә кайтыш, чандыррак, озынча йөзле, зур борынлы иде.

— Үзебезнең кеше булып чыкты,— диде Кулеша, елмаеп,— танышыгыз.

Мыеклы, әйберләрен өстәлгә куйды да, Хөсәенгә кулын сузды.

— Владимир Викторович. — Яңа таныш, сынагандай, соры күзләрен текәп Хөсәенгә карап торды, аннары: — Адоратский, — дип өстәде.

Хөсәен үзенең исемен әйтеп өлгермәде, Кулеша аның сыйфатларын тезә башлады:

— Безнең Казан мөселманнары арасында эш алып баручы иптәш. Безнең эшкә җаны-тәне белән бирелгән. — Кулеша Хөсәенгә таба борылды. — Ә Адоратский әле генә Җеневадан, Ленин янынннан кайтып төште.

Хөсәен аптырап үк китте:

— Ленин яныннан? Сез аны күрдегезме соң?

— Утыр, сөйлә, — диде Кулеша Адоратскийга, көлеп. — Ленин турында сөйлә. Мин сизеп торам: сүзне шуннан башламый булмас.

Адоратскийның да күзләрендә ниндидер сәер елмаю чагыла иде. Күрәсең, ул үзенең өстенлеген тоя, күрәсең, аңа Хөсәеннең артык аптырашка калуы көлкерәк тоела иде. Ул сүнгән папиросын яңадан кабызды да тирән итеп төтен суырды.

— Сезне Владимир Ильичның кай ягы кызыксындыра соң, тышкы кыяфәтеме, табигатеме?

— Барысы да, — диде Хөсәен.

— Син аңа Владимир Ильич белән беренче тапкыр очрашуың турында сөйлә, — диде Кулеша, олыларча киңәш итеп.

Адоратский уйга калды. Әкренләп аның күзләре елмая башлады, Хөсәеннең юравынча, ул хәзер Ленинны күз алдына китерә, аның белән ничек очрашуын хәтерли иде.

— Ленин ул бик гади генә кеше, — диде Адоратский, ниһаять, кулларын җәеп.

— Шулай да? Сез барысын да төкми-чәчми сөйләгез инде. Минем Ленинны күргән кешене очратканым юк иде әле, — диде Хөсәен, ачылып.

— Ничек дип әйтим, әгәр инде сүзне Ленинның тышкы кыяфәтеннән башласаң...

Адоратский Ленинны тасвирлый башлады. Башта Хөсәен көткәнен тапмаудан хафаланып куйды. Ләкин бераздан бу күп тапкырлар үзе турында уйланырга мәҗбүр иткән революционерның, теория һәм тактика мастерының нәкъ Хөсәеннәрдәй һәм менә аның янындагы якын кешеләре Кулешалар һәм тагы бик күпләр кебек үк гади бер кеше булуына шатланып та куйды. Адоратский, сүзен дәвам иттереп, Ленинның бик катлаулы мәсьәләләрне дә гади һәм ансат кына аңлата белүе турында, аның һәр кешене зур игътибар белән тыңлый алуын, онытылып көләргә яратуын һәм кирәк чагында дошманнарын ачы хакарәт белән пыран-заран китерә алуын сөйләде. Ул, ниһаять, Ленин белән Казан каласы турында сөйләшеп утырганлыгын тасвирлый башлады. Хөсәеннең күңеле тагы шатлык һәм горурлык хисләре белән тулды.

Менә шушы, алда торган шанлы революция көннәрендә рульне үз кулына алырга лаеклы, рус революциясенең Робеспьеры булырга тиешле кеше Казанда укыган, алай гына да түгел, Хөсәеннең туган шәһәре Казанда революция юлына аяк баскан, менә хәзер Хөсәен йөргән урамнардан узган...

Хөсәен, үзе дә тоймастан:

— Ленин Казан турында сорашкан. Ә менә безнең халыкның тормышы турында сорашмадымы? — дип сорады.

Кулеша бераз сәерсенеп Хөсәенгә күз ташлады.

— Сез мөселманнарны күздә тотасызмы? — диде Адоратский.

— Әйе, менә безнең татар халкын. Ул, әлбәттә, революциягә безнең халыкның ни дәрәҗәдә ашкынганын тоя торгандыр. Чөнки бу үлемгә хөкем ителгән стройдан икеләтә газап күрүче халык бит ул.

Адоратский уйланып торды һәм:

— Ленин минем белән сөйләшкәндә хас сезнең халыкның хәле турында сүз булмады, — диде. — Ләкин мин Надежда Константиновнадан ишетеп беләм. Ленин Россиядәге изелгән вак милләтләрнең язмышы белән даими рәвештә кызыксынып тора. Хәлбуки тегеләр, беләсеңме, Андрей Степанович, — ул Кулешага карап сөйли башлады, — тегеләр милли мәсьәләгә Ленинча карамыйлар. Җитлеккән великодержавный шовинистлар.

— Гафу итегез, кем ул тегеләр дигәнегез? — дип сорады Хөсәен.

— Меньшевиклар, әлбәттә, — диде Адоратский, ничектер ачы елмаю белән.

Хөсәен ирексездән көлеп җибәрде.

Үзенә сорау белән аптырап текәлгән Кулешага ул кичәге түгәрәкнең чираттагы дәресе булуы турында һәм шунда үзенең нәкъ шушы мәсьәләне анык белми аптыравы турында сөйләде.

— Менә болай тора ул эш, — диде Адоратский. Алар икәүләшеп бу мәсьәләнең торышы турында Хөсәенгә сөйләргә керештеләр. Хөсәен аларны тыңлап, әйткәннәрен исендә калдыра барды, аның күз алдында «Искра»ны чыгаручы, большевикларның житәкчесе Ленин җанланды.

Хөсәен, бер ярты сәгать сөйләшкәннән соң, саубуллашып чыгып китте. Ул никадәр сак булырга тырышмасын, аның күңелендә һаман да Адоратский сөйләгән нәрсәләр иде. Хәлбуки, сакланырга кирәк иде. Аның кечкенә капкадан керүен филер зур игътибар белән күзәтте. Хөсәен ишек алдыннан узып урамга чыккач ук, филер, ниндәндер шикләнеп, аның артыннан урамга йөгерде. Ләкин ул Хөсәеннең күрше ишек алдына кереп китүен күрми калды. Хәзер исә тагы тәрәзә аша өендә, пәрәвез корып куйган үрмәкүч кебек, үзенә корбан көтә иде ул.

## Садыйк кайтты

Туку станоклары шаулап тора. Аларның гөрелтесе сүзне авыздан чыгу белән үк йотып ала. Садыйк яңадан Казанга кайтканлыгын, элекке эшенә керергә теләгәнлеген әйткәч, иреннәренә карап, мастерның нинди җавап кайтарганын шулай да аңлады. Мастер башта сүгенде, аннары:

— Бәхетең, гололобый, — диде. — Син эшләгән станокта берәү дә җүнләп эшли алмый. Буш тора ул. — Мастер мыек чылгыйларын сыпырып Садыйкка бераз карап торды да мыскыллы елмаеп: — бик баемаган, ахры, син? Анда барып баеп кайтмакчы идең, булмадымыни? — диде.

Садыйк моннан өч ел элек яңа туку фабрикалары салына, әллә, бәлкем, анда адәм рәтлерәк түләрләр дип, Урал якларына киткән иде. Ләкин кара сакалның һәрвакыт үзе белән йөргәнлегенә ул бик тиз ышанды.

— Кайттым, — диде Садыйк, каш астыннан гына карап, — солдатка караласым бар. Тик син, Иван Петрович, мине баемаган дип бик каты ялгышасың.

— Ә бу нәрсә соң башында? Шул ук ямьшәйгән ертык эшләпә бит. Өстеңдә тагы! Бай кеше болай йөрми, Сәгыев!

— Байлыкны берьюлы чыгарып күрсәтергә ярамый аны. Тора-бара күрерсең әле.

Мастер, бу юлы үз итүчәнлек белән елмая төшеп, Садыйкның иңбашына җиңелчә сукты да:

— Ярый, бүген үк төнге сменага чыгарсың, имән әкәләсе, — дип китеп тә барды.

Бик ихтимал, мастер Садыйкны Уралдан чынлап та кесә тутырып акча алып кайткан дип уйлагандыр, бәлки шуңа йомшаргандыр да. Ләкин Садыйк Уралның үзәге Екатеринбургта өч ел тукучы булып эшләп, бары өмет хәзинәсен генә баеткан иде.

Садыйк Екатеринбургта политик каторжаннар белән аралашты. Әнә шулар аның өмет йолдызын кабыздылар.

Дөресен генә әйткәндә, ул өенә Казанны сагынудан кайтмады. Солдатка каралуны сылтау иткән булса да, аның үз алдына куйган җитди, хәтәр бер максаты бар иде.

Ул, Алафузовның туку мастерскоена урнашу белән үк, ашкынып кайнар теләкләрен гамәлгә ашырырга керешге. Ләкин эш ул уйлаганча булып чыкмады. Кемгә генә барып орынмасын, барысы да Садыйкка кырын карыйлар, җилкәләрен җыералар, аңардан йөз чөерәләр иде. Моңа кадәр Казанда революцион рухтагы кешеләр белән бәйләнеше булмаган Садыйк башта, бу мескеннәр чистый төшеп калган әлләзиләр икән, дигән фикергә килде. Үзенчә ышанычлырак дусларына аңлы булырга, үз мәнфәгатьләрең өчен көрәшә белергә кирәклеген төшендерә башлады. Ләкин дус дип табылганнары да Садыйкның бу сүзләренә карата илтифатсыз булдылар.

Ниһаять, көннәрдән беркөнне көтелмәгән яңалык ачылды. Сменадан кайтып, ашарга гына утырганда, энесе Зариф үзе шул турыда сүз башлады.

— Ни пычагыма син, абый, җүләр сатып, коткы таратып йөрисең?— диде ул.

— Син нәрсә, үсеп җиттеңмени? Миңа акыл сата башладыңмы инде?! — диде Садыйк. — Әллә үзеңне кешечә яшим дип исәплисеңме? Тормышмыни бу! Ашаганыбыз кара ипи белән бәрәнге... Безне хайван урынына да күрмиләр. Нәрсә, шуларны әйтергә ярамыймы?!

— Туктале син, абый, — диде Зариф, күзләрендә ачу утлары уйнатып, — алай булмый бит ул!

— Нәрсә «булмый»?

— Алай итеп, һәркемгә бәйләнеп, эчеңдәгене тышка актарып йөрергә ярамый, абый.

Садыйк, нидер сизенеп, тукталып калды. Серле һәм үтенүле бер тонга күчеп:

— Нәрсә соң, эш нәрсәдә? Аңлат миңа, энем, — диде.

Зариф абыйсының йөзенә текәлде:

— Бүген Вәлиулла абыйны очраттым. Әйт абыеңа: җүләрләнеп йөрмәсен, ди.

— Тукта, тукта, әллә... — диде Садыйк.

Күзләре ялтырап китте. Күңелендә берьюлы әллә ничә төрле юрау туды. Бәлки, Садыйк оештырырга хыялланып йөргән яшерен революцион оешма фабрикада бардыр инде. Бәлки, аның энесе үзе дә шул оешмада торадыр. Ә бәлки, бөтенләй киресеседер. Бәлки...

Садыйк түзмәде:

— Әйт, хәзер үк әйт, — диде Зарифның иңбашларыннан кысып, — бездә андый оешма бармы?

— Нинди оешма тагы? — диде Зариф, сәерсенеп.

— Революционный кружок!

Зариф муенын жыерып кына куйды.

— Әллә син үз абыеңнан да шикләнәсеңме инде? — диде Садыйк, рәнжеп.

— Андый жирләргә йөргән кешегә ни буласын мин беләм, абый, — диде Зариф.

— Шуңа күрә миннән яшерәсең дәме?

— Мин берни дә яшермим синнән, абый, тик...

— Соң шулай булгач, әйт, нигә мине азаплыйсың?!

— Азаплыйсың дип, нәрсә әйтим соң мин сиңа?

— Син минем башымны катырма, беләдеңме? — диде Садыйк, тәмам туарылып. — Барысын ачыктан-ачык әйт, кем белән сөйләшергә кирәк, кем аша эш йөртергә кирәк? Мин хәзер үк, менә шушы минутта ук, жанымны аямыйча, шул эшкә ташланам.

— Мин бер әйбер дә әйтә алмыйм.

— Я ни өчен инде алай, әллә туган абыеңнан яшермәк буласыңмы? Әллә инде үз туганыңны ят күрә башладыңмы син? Курыкма, минем Уралда күзем ачылды. Анда чын революционерлар белән таныштым мин. Миңа алар бик күп нәрсәләр аңлаттылар. Безгә бер генә юл калган, энем, я жанны фида итеп ирек өчен көрәшергә, я инде егылып үләргә. Менә шуны аңладым мин!

— Мин бернәрсә дә әйтә алмыйм сиңа, абый, — дип кабатлады Зариф. Ләкин аның күзләрендәге усаллык инде беткән, күренеп тора, күңеле йомшарган иде. Ул:

— Мин бары Вәлиулла абый әйткәннәрне генә житкерәм сиңа, — диде. — Алай ярамый, һәркем алдында ачылып, ыштансызланып йөрергә ярамый. Башың себер китәр, алла сакласын!

Зариф бу сөйләшүдә абыйсына берни дә әйтмәде. Ләкин Садыйк шулай да әчке бер сизенү белән шул көннән башлап тирә-юньдә революцион эш алып барылганлыгын тойды.

Энесе белән сөйләшкәннән соң ул элекке таныш-белешләре арасында тыелган гәпкә артык керешмәде. Мәгәр кемнәрнеңдер үзен игътибар белән күзәткәнлеген ул сизми түгел иде. Тагаен, аны хәзер ике як та бик нык өйрәнә иде.

Һәм, чыннан да, бер атна вакыт узмады, ул чишенү бүлмәсендәге үзенең кием шкафыннан кечкенә генә бер төргәк тапты. Төргәкне бәдрәфкә кереп сүтте. Анда революцион прокламацияләр төрелгән иде.

Садыйк, прокламацияләрне тикшереп, берничәсен укып чыкты да тәвәккәлләп итек кунычына тыгып куйды. Башы куркынычлы уйлар белән тулган иде аның. Станогы янына чыгып баскач, бер мәл эшкә керешә алмый торды. Станок гөрләп эшли башлагач та, йөгерек, житез сусаларга, зур музыка коралы кылларыдай тартылган нигез жепләренә карап байтак вакыт айный алмый газапланды.

— Уток жебең! — дип мастерның сүгенеп кычкыруы аны уятып жибәрде. Ул тиз генә күнегелгән эшенә керешге. Садыйкның башын кәезлаган нәрсә «Нинди максат белән бу, провокацияме, я булмаса сынаумы?» дигән сорау иде.

Әйе, теге көннәрдә артын-алдын уйламыйчарак һәрбер таныш-белешенә тыелган сүзләр әйтеп йөргәннән соң, Садыйктан шикләнеп, охранка кешеләре прокламацияләрне юри аңа ташлаулары бик ихтимал бит. Әмма бөтенләй башкача булуы да бар. Бәлки, идән асты оешмасының эшедер бу? Ихтимал, алар, син бик батырланып йөргән идең, хәзер кем икәнлегеңне күрсәт инде, дип шулай эшләгәннәрдер? Садыйк прокламациянең нәрсә икәнен бик яхшы белә. Әгәр хәзер үк тенти башласалар һәм, әйтик, прокламацияләрне тапсалар, ким дигәндә аны берничә елга каторгага сөрәчәкләр.

Садыйкка әлеге прокламацияләр ничектер куньчка начар тыгылганнар, берәрсенең почмагы күренеп торадыр кебек тоелды. Ул күзләрен станогыннан аерды, каерылып итекләренә карады.

— Син нәрсә, әллә махмырлап килдеңме? — диде мастер.

Гөнаһ шомлыгына каршы, ул Садыйктан күзләрен алмый һаман күзәтә, һаман Садыйк тирәсендә болгана иде.

Садыйкка бер мәл, барысы да мәгълүм, шик юк, ул тотылачак, озакламый аңа килеп бәйләнәчәкләр, аннары полиция участогына алып китәчәкләр кебек тоелды. Бу шул дәрәҗәдә ачык иде, Садыйк хәтта үзен саклау, котылып калу турында уйламады да. Менә аның прокламацияләрен участокта алдына җәеп салачаклар, бик каты кыйнаганнан соң: «Болар каян? Кем бирде?» — дип сорый башлаячаклар. Әлбәттә, Садыйк дөресен әйтәчәк: «Миңа аны кемдер шкафыма салган», — диячәк. «Яхшы, ышандык, ләкин ни өчен соң шундый тыелган нәрсә икәнен белгәч, һич югында мастерыңа илтеп бирмәдең?» — диячәкләр. Әйе, ул прокламацияләрне итек куньчына салды, чөнки аңа шундый кадерле әйберләрне дошманы кулына бирергә вөҗданы кушмады. Фу, чәнчелеп китсенсәнә! Тагы җеп өзелде. Садыйк, гадәтенчә, җепне тиз генә ялгады да, уйларыннан аерылырга, куләгәсе кебек янында йөргән дәһшәттән котылырга теләп, эшенә кереште.

Станок гөр-гөр итеп тыныч кына эшли иде. Ремизкалар бер төшеп, бер менеп чайкалалар, валлар әйләнә, ә йөгерек сусалар күз иярмәслек җитезлек белән хәрәкәтләнәләр. Бер ритмдагы тавыш һәм мастерның бөтенләй теге очка китеп юкка чыгуы Садыйкны ничектер тынычландырып җибәрде. Ул үзенә үзе сорау бирде: «Син шул дәрәҗәдә куркакмыни, Садыйк? Ә бит революцияне бары батыр кешеләр генә ясый ала». Әйе, әйе, бу сүзләрне Екатеринбургта сөргендә ятучы карт революционер әйткән иде. Ул кеше һәрвакыт тыныч, бервакытта да аек фикер йөртү сәләтен югалтмый иде. Күкрәгенә кадәр төшкән кара сакаллы, тимер кысалы күзлек кигән бу кеше, һич курыкмыйча, Садыйклар яткан баракка килә иде. Чыннан да батыр кеше иде ул. Хәер, ул сөргендә иде бит. Аңа нәрсәдән куркырга? Алай дисәң, сөргендәге кешеләргә дә закон бер түгелмени? Хәтта катырак та әле. Һәм шул кара сакаллы карт көннәрдән беркөнне юкка чыкты. Аның исемен дә, фамилиясен дә белә алмадылар.

Тукта, тагы икенчесе дә бар иде. Анысы кавказлы иде, әллә әрмән, әллә грузин инде. Анысы бик шау-шулы иде. Ә, гомумән, йөзеннән елмаю сирәк китә иде ул каторжникның. Була бит шундый кайгыга бирешми торган егетләр. Ул хәтта бер тапкыр үзләренчә биеп тә күрсәтте. Шул ук баракта. Такта кушеткаларны бер яккарак этәрделәр дә монда биергә мәйдан әзерләделәр һәм бу, авызына пычак кабып, үзенең җиңел сөякле адәм икәнлеге белән бөтен барак эчендәгеләрне шаккатырды. Инде ни белән бетте диген әле! Ят бер кешенең баракка килеп керүе булды, бу кавказлы биегән җиреннән үк, пычагын ташлап, ачык тәрәзәгә сикерде һәм юкка чыкты. Соңыннан белделәр. Килеп кергән кеше шпик икән.

«Чыннан да, — дип уйланды Садыйк, — тәрәзәдән сикерү ихтималын һәрчак истә тот, егет. Чыннан да, ни өчен соң әле бу прокламацияләрне үзе белән йөртә ул? Ә кайда яшерергә мөмкин булыр икән соң? Бәлки инде фабрикада тентү булмас, ләкин бит фабрикадан чыкканда тентиячәкләр. Ни өчен соң әле ул курәләтә үзен хәтәр бер хәлгә куя. Ни өчен аңа прокламацияләрне итек куньчына яшерергә кирәк? Ул прокламацияләр монда калырга тиеш. Садыйк прокламацияләргә яшерен урын эзли башлады.

Әнисе аны эш вакытында станок янында тапкан иде. Ундүрт яшь тулгач, ул шушы ук туку мастерскоена эшкә керде. Мондагы һәрбер почмак Садыйкка таныш. Хәер, ул әнисе янына әле эшли башлаганга

кадәр үк килеп йөрде. Ул чагында аның дәү әнисе дә исән иде. Ул, суынмасын, йөрәгенә ял булыр, бар, улым, әниенә илтеп кайт дип, агач табактагы кайнар ашны тастымалга кат-кат төреп җибәрә иде. Баштарак Садыйк әнисен капка төбендә көтте, ә соңыннан, сакчылар белән тәмам дуслашып киткәч, аны мастерскойга да кертә башлады-лар. Менә шул вакыттан бирле үк ул үзе дөньяга килгән урынны якын итте. Монда бөтен җирне тузан һәм тавыш басып киткән иде, станок-лар, рәт-рәт тезелеп, җитен киндере тукыйлар. Алар әкәмәт җан иләре кебек. Садыйк мастерскойның һәрбер почмагын биш бармагыдай белә.

Хәзер ул күңеленнән прокламацияләр яшерердәй урын эзләп торды. Ләкин, кая гына куймасын, табарлар кебек иде! Ниһаять, ул тапты. Мастерскойның чоланында зур калай бак белән фонтан суы тора. Ә бак янында гына стенада зур тишек бар. Садыйкның әле дә исендә, яшьрәк чагында өйгә кайтыр алдыннан ул тәмәкесен шул тишеккә яшереп калдыра торган иде.

Садыйк, бәдрәфкә кереп, итек кунычындагы прокламацияләрне яңа-дан алып төрде, җиң эченә яшереп, су эчәргә чыкты. Сак кына тирә-ягына карана башлады. Кеше юк, хәзергә хәвефләнерлек берни дә күренми. Садыйк, су эчкән булып, әкрен генә, сиздермәстән генә прок-ламацияләрне мәгълүм тишеккә кертеп җибәрде. Ләкин нәкъ шул чак-ны ике яктан да ишекләр ачылып китте. Урам ягыннан пенсне күзлекле ниндидер бер аксак кеше килеп керде, эчтән исә тукучы рус хатыны Фекла чыкты. Тегеләр ишекне ачканда, Садыйк прокламацияләрне кулыннан ычкындырмаган иде әле. «Күрделәр!» дигән дәһшәтле уй аның миен көйдереп алды. Пенснеле кеше исә, җитмәсә, узышлый Садыйкка мәкерле бер караш ташлады.

— Яле, миңа да берне агызып бир әле, — диде Фекла. Аның да күз карашы серлерәк иде. Ләкин Садыйк сынатмады, калай кружкага су агызды да хатынга сузды. Бары аның кулы гына сизелерлек дерелди иде. Хатын моны күрде.

— Махмырданмы? — диде көлемсерәп. Садыйк иркен сулап алды.

— Булды инде хәлләр!

— Һи-и, җеннәр! — диде Фекла, сукранып, — җилгә очырасыз, җүн-сезләр, тир коеп тапкан акчаны!

Садыйк цехка кереп, яңадан станогы янына баскач, тәмам алҗыган хәлдә барысына да, барысына да кул селтәргә, артык бу прокламация-ләр турында уйланмаска булды.

Һәм уйламады да. Үзен көчләп онытырга мәҗбүр итте. Бер караң-гыдан икенче караңгыга кадәр сузылган эш көне һәм әлеге борчулар аны тәмам интектергән иде. Ул өенә йокымсырап, эленке-салынкы гына кайтып керде. Бер тәлинкә ашны көчкә ашап сәкегә менеп ауды. Башы мендәргә тию белән, калгып та китте. Бераздан үзенең каты гырлавын-нан куркынып уянды. Шул кыска гына йокы арасында ул әллә нинди төшләр күрергә дә өлгергән иде. Төшендә үзенең сөйгән кызын күр-де. Садыйк, уянгач, уйлана башлады. Өйләнергә вакыт җитте. Инде артык сузуның кирәге юк. Ул менә язын солдатка каралырга тиеш, сол-датка алынса, өйдә нчмаса әнигә ярдәмче хатын-кыз кулы булыр, дип уйланды. Юкса, әнисе картаюдан да битәр артык таушалган бит.

Ул менә түй уздырырлык әз генә акча әмәлләр дә шул ук Алафузов фабрикасында эшләүче Гөлнисага яучы җибәрер.

«Син армиягә барам, дисең, — дип уйланды ул, — японнар белән сугышырга, ә менә аның урынына этап белән Себергә озатсалар сине? Ә ни өчен озатсыннар?» Садыйкның күңеле җу итеп китте. Тукта, прок-ламацияләрне яшергәнне күрделәрме, юкмы? Тәгаен, күрделәр. Алай дисәң, алар яшерелгәннән соң да әллә ни гомер вакыт узды ич инде. Нигә кулга алмадылар аны?

Садыйкның бөтенләй йокысы качты. Ул эченнән үзен куркаклыкта гаепләп, беренче сынауда ук шүрләп-тетрәнеп калуы, шик-шөбһәләргә бирелүе өчен хурланып ятты.

Бераздан аңа теге хатын, я булмаса әлеге күзлекле аксак кеше барын да күргән һәм хәзер прокламацияләр жандарм начальнигы өстәлендә яталардыр кебек тоелды. Тәгаен, алар, һич уйламаган рәвештә тозак корганнардыр. Эх, мин тиле дә инде! Чыкканда җүнләп тентемәделәр дә ич, рәхәтләнеп алып кайтасы да урам буена таратып йөрисе шуларны. Әйдә, тамакларына таш тыгылсын иде патша тәлинкәсе ялаучы паразитларның! Ул прокламациядә язылган һәрбер сүз бомба хезмәтен үтәрлек бит. Эх, дип куйды тагы ачынып Садыйк.

Ул торып утырды, күзләрен уып тирә-юненә каранды. Өй эче тыптын, өйдәгеләр барысы да йоклый, бары чикерткә генә бер көйгә мич артында сайравын белә. Менә шушы эшчеләр өчен салдырылган хуҗа өенә күчкәннән бирле, дөресрәге, Садыйк үзен белгәннән бирле бәхет теләп сайрый шул җүләр чикерткә. Садыйк башын тагын мендәргә салды һәм шунда ук тәвәккәл тойгылар белән җанланып план кора башлады. «Хәзер төн, төнге эшкә калучыларның гына станоклары эшли, халык аз, тыныч, — дип уйланды ул, — барып карасам, ни булганын анык белсәм, ә?»

Ул әкрен генә урыныннан торды да сәкедән төште. Ләкин никадәр генә сак кыйланмасын, анасы Фатиха апа уянып күзләрен ачты.

— Садыйк улым, синме?

— Мин лә.

— Ни булды?

— Фабрикка барып кайтырга кирәк.

— Менә тагы, нигә алай? — диде Фатиха апа, аптырый төшеп.

— Онытканмын, — диде Садыйк. Ләкин нәрсәне онытканлыгын әйтмәде, чөнки анысын уйлап чыгарырга өлгермәгән иде әле. Ул тиз-тиз генә киенде дә авыз эченнән сукранып чыгып китте.

Фабрика капкасында аны тоткарламадылар. Садыйк ашыга-ашыга мастерскойга кереп китте. Су багы артындагы тишеккә кулын сузды. Мең шөкер! Садыйкның бөтен күкрәген җылытып тынычлану рәхәте йөгерде: беркем дә прокламацияләргә тимәгән иде.

Садыйк аларны чалбар кесәсенә салды, ашыгып, чишенү бүлмәсенә керде. Караңгы салкын бүлмәдә ул, бер мәл тукталып, урталыкта уйланып торды. Инде аның күңелендә яңа уй-теләкләр канат ярып өлгерде. Ул баягы хатасын хәзер төзәтергә тиеш. Ул хәзер үк прокламацияләрне мастерскойдагы эшчеләргә бирәчәк. Яшерен типографияләрдә, хәвеф-хәтәрнең күзенә карап, шулар укысын дип чыгармаганнармыни аларны!

Садыйк төргәкне сүтте дә эшчеләрнең кием яшикларындагы ярыктан прокламацияләр төшерә башлады.

Кинәт ишек турысында кыштырдау ишетелде. Садыйк сискәнеп артка чигенде. Каһәр суккан күсе! Егет ачу белән идәнгә төкерде, калган прокламацияләрне ишек алдында төшереп калдырырга булып, мастерскойга чыкты.

Ишек алды буйлап узганда, Садыйк сиздермичә генә прокламацияләр ташлап калдыра башлады. Тикшереп чыгару будкасына җиткәндә, аның кесәсе буш иде инде.

Иртәгесен эшкә баргач, Садыйк мастерскойда ниндидер үзгәреш тойды. Эшчеләр үзара чышын-пышын сөйләшәләр, аларның йөзендә ниндидер серле елмаю чагыла. Мастер исә ачулы һәм борчулы иде.

Садыйк, берни булмагандай, станогы янына басты һәм тыныч кына эшенә кереште. Көндезге аш вакытында мастерскойда ниндидер ят, күз күрмәгән кешеләр күренде. Озакламый мастер конторкага Садыйкны чакыртты.

— Син төнге икедә фабрикага килдеңме? — дип сорады өстәл артында утыручы инженер формасы кигән кеше.

Садыйк үзен кулга алды, йөзенә мәгънәсез елмаю чыгарып:

— Килгән идем шул, ваше высокородие, — диде.

— Нигә килдең? — диде чытык йөзле мастер.

— Нигә дип, Иван Петрович, әчкечне алъяпкыч кесәсендә онытып калдыргаммын.

— Нинди әчкеч ул?

Садыйк тагы да мәгънәсезрәк итеп елмаерга тырышты.

— Сандык әчкече. Хәтерлисезме, теге чакны байлык турында сүз барган иде, Иван Петрович. Әйтми булмый хәзер, байлык яткан сандык инде. Төнлә уянып киттем дә хәзинә исән микән дип карасам, әчкеч юк. Нишлим, кот алынды, йөгердем фабрикага!

— Таптыгызмы соң? — дип сорады теге өстәл артында утыручы инженер, кара янып.

— Таптым, ваше высокородие, аллага шөкер, — диде Садыйк. — юкса менә үлә язып курыккан идем. Ни әйтсәгез дә, анда бит өч ел буена эшләп җыйган байлык.

— Я, алайса күрсәт әле безгә ул әчкечеңне?

Садыйк бөтен бите белән елмайды да алъяпкыч кесәсеннән кашык кадәрле сандык әчкече чыгарып күрсәтте.

— Татарская морда! — дип кычкырды инженер. Аның ачуыннан борынына кыстырылган күзлеге төшеп китте. — Марш безнең яннан, эт!

Садыйк бу юлы да үзен кулдан ычкындырмады.

— Эт булмыйча булмый, ваше высокородие, — диде бик төче телләнеп, — бүрене этсез ничек куасың аны!

Ул мөмкин кадәр тыныч кыйланган булып мастерскойга чыкты. Ләкин үзен көчләп тыныч тоту аңа җиңел булмады, гадәттә күз ачып йомганчы ялгана торган җепләр бу юлы кәҗәләнеп үзәккә үттеләр. Ләкин, ни булса да, барыбер тегеләрнең Садыйкка бәйләнергә нигезләре юк! Без әле эшләп күрсәтербез! Ул хәзер генә ачык итеп үзенә хәерхаһ булган, теләктәшлек күрсәткән иптәшләрен абайлады. Алар төрле ишарә, я булмаса кинаяләр белән Садыйкка үзләренең хөрмәтләрен сиздерәләр иде. Юк, хәзер аны ялгызлыкта калу дәһшәте куркытмый. Куллары калтыраса да, рәхәт иде аңа.

Өч көннән соң энесе Зариф көндезге аш вакытында аңа:

— Сине Вәлиулла абый чакыра, ул ишек алдында, — диде.

Вәлиулла исә Садыйкны күрү белән култыклап читкә алып китте. Аның киң йөзе дустанә елмаю белән балкыган, күзләреннән ягымлы җылылык сирпелеп тора иде. Алар аулак урында тукталдылар.

— Садыйк дус! Сине бер кеше белән таныштырасым килә минем, — диде Вәлиулла.

— Кем соң ул?

— Баргач күрерсең. Якшәмбе көн, иртәнге сигезләрдә миңа сугыл.

Садыйк әйтелгән көнне Вәлиуллаларга барды һәм аларның өендә үзләрендә үк эшләүче иске танышы Ефим Панкратьевич Табейкинны очратты.

Бу кеше, әле кырык-кырык биш яшьләрендә генә булса да, чаларган иде инде. Өстендә утырма кыек якалы кара күлмәк, кыска постау суртюк, аякларында күн итек. Ул төптән юан, киң җилкәле бер тукучы иде. Күкрәгенә төшеп торган сакалы, куе бөдрә чәче аны аерата күркәм һәм солтанатлы итеп күрсәтә иде.

Ефим, көләч коңгыр күзләрен кыса төшеп:

— Я, ничек соң, Садыйк, бераз баш ватарга туры килдеме? — дип сорады.

— Мин аңламыйм сине, Ефим агай, — диде Садыйк.

Табейкин бу юлы көлеп үк җибәрде.

— Аңламыйсыңмыни? Мин әлеге прокламацияләр турында әйтәм.

Садыйк, ни дияргә дә белмичә, куркынып, сорау белән Вәлиуллага текәлде. Аның да киң түгәрәк йөзе елмаюдан балкый иде.

— Курыкма, — диде ул. — Бу безнең «әткәй», без барыбыз да аның җитәкчелегендә эшлибез.

Садыйк каты итеп Ефимның кулын кысты.

— Мин бит... мин бит әз генә дә сине шундый кешедер дип уйламаган идем, Ефим Панкратьевич. Рәхмәт.

Табейкинның йөзенә җитдилек йөгерде, ул, кашларын җыерып, сөйли башлады. Соңгы көннәрдә үзенең охранка тарафыннан бик нык эзәрлекләнүен, бары шуңа күрә генә Садыйкны өенә чакырта алмавын, ләкин инде ул кулга алынган хәлдә дә аптырап калмаска, революцион эшне дәвам иттерергә кирәклеген аңлатты. Садыйк, аныңча, белемен арттырырга, марксистик түгәрәк дәресләренә йөрергә тиеш иде.

— Ә бармы соң андый нәрсә бездә? — дип сорады Садыйк.

Бар икән шул. Барысы да бар икән, тик Садыйк кына берни белмәгән.

— Мин сиңа бер явка бирәм, — диде Ефим егеткә. — Син ул кешене эзләп тап. Ә аннан ул уздыра торган түгәрәк утырышларына йөри башларсың.

Садыйк тиздән бу кешенең Ямашев икәнлеген белде.

## Агачларга рәхәт

Хөсәеннең хатыны Хәдичә әле бүген генә Чистайдан кайтып керде.

Ул инде күптән, беренче пароход белән үк, юлга чыкмакчы булган иде, тик көтмәгәндә әнисе Гыйззелбанат апа авырып китте. Инде аның аякка басуы булды, Хәдичә үзе суык тидереп атнага якын ятты. Шулай итеп, сәфәр шактый озакка тартылды. Хәзер исә болар барысы да арттл калган хәлләр иде. Хәдичә, дөнья кадәр күчтәнәч, бүләк төяп, Казанга кайтып төште. Ул үзенең Хөсәенен бик-бик сагынган иде. Ләкин милли йола аңа пристаньда ук, эчке тойгыларын ачык сиздереп, иренең муенына сарылырга рөхсәт бирмәде. Шулай ук өйгә кайткач та әле байтак кына вакыт каенанасы алдында өй эшләре белән чуалырга туры килде. Инде иркенләп ире белән генә ялгыз калыйм дисә, Хөсәен, иптәшләренә ияреп, каядыр китеп барды.

Хәдичә бакчага караган верандага чыкты, әле замазкалардан арчылмаган тәрәзәне шытырдатып ачып, яшеллеккә күмелгән агачларга карап утыра башлады. Табигать үзенең яшьлек чорын кичерә иде. Агачларга рәхәт. Хәдичә белән Хөсәен дә шундый гүзәл бер чор кичерергә тиешләр бит. Ник соң Хәдичәгә бик авыр?

Ул үзенең Чистаенда узган яшьлеген хәтерләде. Көннәрдән беркөнне инде үсеп буйга җиткәч, ул бер хәбәр ишетте. Аныниндидер Казан сәүдәгәре улына кияүгә бирергә җыеналар икән. Ходаем! Хәдичә сәүдәгәр малаена чыгарга җыена идемени соң?! Ул хосусый мөгаллимнән русча укыды һәм иренең разночинец, алдынгы кеше булачагы турында хыялланды. Тик башны ташка орып булмый.

Көннәрдән беркөнне асрау кыз: «Почтальон урыс килгән, сине сорый», — диде. Хәдичәнең хәсрәте хәттин ашкан иде, шуңа күрә почтальонга артык игътибар да итмәде, ул биргән пакетны алып өстәленә кертеп ташлады.

Ә туй булып никах укылгач, Хәдичә беренче тапкыр үзенең кияүен күрде һәм тәмам аптырашка калды. Ходаем! Теге вакытны почтальон урыс кыяфәтенә кереп килгән кеше иде ич Хөсәен!

Ә аннан соң ни булды? Хәдичәнең ире Россия империясендә ниндидер яна тәртипләр урнаштырырга йөрүче революционер социал-демократ булып чыкты.

Хәдичә ачык тәрәзә янындагы камыш кәнәфигә утырган килеш шуларны уйлады. Бик авыр иде аңа. Йөрәгенең әрнүенә түзә алмыйча, ул урыныннан торды. Тынычланыр өчен өй эшләре белән онытылып булаша башлады. Ул арада хәл белешергә дип килгән туган-тумача, дус-иш күренде. Хәдичәнең Чистайдан кайтып төшүе «чыбыксыз телефон» аша ни арададыр ишетелеп өлгергән иде.

Бераз күңеле күтәрелеп киткәндәй булды. Хәдичә бер кунакны озатты, икенчесен каршы алды, килүчеләрне Чистай күчтәнәчләре белән сыйлады, хәбәрләр, яңалыклар сөйләде, мәгәр шулай да күңеле белән һаман Хөсәенен көтте.

Менә кич тә житте инде, Хәдичә кайту хөрмәтенә Нәкыя зал яктагы асылмалы зур лампаны да кабызып җибәрде. Соңгарак калган кунаклар да өйләренә кайтып киттеләр, ләкин Хөсәен һаман күренми иде әле.

— Мин югында һаман шулай йөрмәгәндер бит, әни? — дип сорады Хәдичә.

Бибифатыйма барысын да аңлады, тик дәшми калды. Хәдичәнең күңелендә шомлану тойгылары үскәннән-үсте. Бибифатыйманың улы өчен борчылуын, аның язмышы өчен ут йотып яшәвен Хәдичә моңарчы ачык тоя иде. Ул каенанасы йөзендә үзенә сердәш табарга теләде. Ләкин ни өчен Бибифатыйма бу юлы болай сәер, серле итеп карады.

Хәдичә, батырчылык итеп:

— Мин тегендә дә аның өчен ут йотып тордым, әни, — диде. — Ниләр булды соң?

— И килен, — диде Бибифатыйма, — нигә әллә нәрсә уйлап шулай шикләнәсең? Сиңа әйтә торгандыр ич ул?

Әйе, әйтә иде. Хәдичә бик күп нәрсәләр белә иде. Ләкин ул, Хөсәенне ятратканга күрә, бәхәскә керми иде. Хәдичә сүзсез генә каенанасына текәлде.

— Бүген бутышник Гайнулланы урамда очраттым әле, — диде Бибифатыйма шыпырт кына.

Хәдичәнең куркуы йөзенә чыкты. Татар полицейскиеның хәерле сүз әйтмәве билгеле иде инде.

— Соң? — диде ул, агара төшеп.

— Шушы көннәрдә сезгә тентү белән килеп чыкмагайлары, сак була күрегез, — ди.

— Тентү? — диде Хәдичә. — Нәрсә ул? Ни өчен?

Хөсәеннең ниндидер китаплар, брошюралар укыганын, хәтта үзенә дә берсен бирен укытканын хәтерләде. Китап Хәдичәне мавыктырмады, дөресен генә әйткәндә, тиешенчә аңлашылмады да, ләкин аңар куркынычлы, хәтәр сүзләр язылган иде. «Мәкруһ» әдәбиятны Хөсәен тәрәзә астындагы куышка яшереп куя. Хәдичәнең башыннан шулар узды.

— Болай китеп югалуы тикмәгә генә түгелдер әле аның алайса? — диде ул.

Ашыгып урыныннан торды да йөгереп күрше бүлмәгә чыкты. Обой кәгазен сак кына аерып, элеге куышка кулын сузды. Ләкин анда бер әйбер дә юк иде. Шулай да Хәдичә тынычланмады, йөрәге Хөсәеннең язмышы өчен куркып, ул кулга алынгандыр дигән уйдан кысылып авырта башлады.

— Әни, нишлибез соң инде? Хөсәенне кулга алмаганнардыр бит? Син тентү турында әйттеңме соң аңа?

— Белмим инде, аллага тапшырдык, — диде Бибифатыйма, үз уйларына чумып. Ул килененә Хөсәенне шул ук көнне кисәтеп куйганлыгын әйтмәде.

Ни буласын көтүдән башка чара юк иде. Килен белән каенана икесе ике бүлмәгә кереп киттеләр. Ләкин берсе дә йоклый алмады. Ялгыз калгач, отыры уйландыра иде. Ачык форточкадан бүлмәне аңкытып табигать сулышы үзе белән ятрак тавыш алып керсә дә, алар сискәнеп урыннарыннан торалар һәм озак-озак сагаеп тәрәзә янында хәрәкәтсез калалар иде. Өй эче тын, бары үз бүлмәсендә йоклаган Нәкыянең генә ирләрчә гырлавы ишетелә, бары ул гына гамьсез рәвештә йокы сүтә иде.

Сәгать төнге уникене сугып, яңа тәүлек башлангач, кинәт ишек дөбердәттеләр. Хөсәен булырга тиеш иде бу. Ул шулай сак, өзеп-өзеп йодрыгы белән өч тапкыр суга иде. Хәдичә, эчке күлмәкчән генә, аягына иске кәвешләр элəктерде дә өйалдына чыкты. Бибифатыйма да уяу, ул да торган иде инде.

— Хөсәен, — дип калды ул, шатланып.

Хәдичә дөбердәп баскычтан төште, озын келәне күтәреп җибәрде. Чыннан да, гыштa елмаеп Хөсәен басып тора иде. Алар ашыгып өскә күтәрелделәр. Бер генә минутка өйалдында тукталдылар. Хәдичә еламсырап ирена текәлде:

— Нигә шулкадәр соңга калдың?

— Гафу ит, Хәдичә, — диде Хөсәен, хатынының кайнар тәнен кочып. Хөсәеннең киеменнән дә, йөзеннән дә тәмәке исе аңкый иде. Димәк, алар тагы кайдадыр җыелышып утырганнар. Ләкин Хөсәеннең күңеле бик күтәренке, аның ап-ак тешләрен Хәдичә караңгы өйалдында да шәйләде. Ул хатынын кочып, уң як битеннән үпте дә, өйгә керделәр.

Хөсәен ашап, Хәдичә янына кергәндә, хатыны караватта ята иде инде. Ул, ирен күрү белән, күкрәкләрен юрган белән каплаган хәлдә, ялангач аякларын салындырып караватка утырды. Хөсәен чишенә башлады.

— Хөсәен, син әз генә дә мин... — Хәдичә сүзеннән бүленеп калды.

Хөсәеннең елмаюлы йөзе кинәт җитди бер кыяфәткә керде. Чөнки Хәдичәнең бөтенләй төсләре киткән иде.

— Ни булды, Хәдичәкәй?

— Сон инде... — диде Хәдичә һәм, никадәр генә үзен батыр тотарга тырышса да, калтырана башлаган иреннәрен тыя алмыйча аска карады.

— Җан кисәгем, — диде Хөсәен, хатынының янына утырып. — Син минем соңга калып кайтуымны кичерә алмыйсың? Әллә моны сине сагынмаудан дисеңме? Киресенчә, мин сине менә йөрәгемдә генә саклап йөртәм.

— Һем-м, кызык икән синең мәхәббәтең, — дип куйды Хәдичә, елап җибәрүдән көчкә тыелып. — Мин айдан артык читтә булдым, ә син...

— Син үпкәләргә тиеш түгел, Хәдичә, — диде Хөсәен, хатынын кочаклап. — Мин башкача эшли алмадым. Сәбәбен хәзер генә сөйли алмыйм. Ләкин сөйләгәч, син мине мотлак гафу итәрсең.

— Һич аңлый алмыйм мин сине, Хөсәен. Нигә кирәк ул андый кысыр хәсрәтләр. Һич булмас, һич булачагы юк эшләр артыннан нигә йөрергә?.. Нигә бик матур башланган тормышны авыр хәсрәткә дучар итәргә?!

— Юк, алай түгел, Хәдичә! Йөрәгем шатлык белән тулы минем. Мин бәхетле. Син мине барыбер аңларсың дип уйлыйм. Барысын да аңларсың һәм син дә кинәт минем яклы булырсың, бәхетле булырсың дип уйлыйм.

Хөсәен Хәдичәнең чигә чәчләрен кулы белән сыпырды да башта яшь белән чыланган яңагыннан, аннан тулып торган матур иреннәреннән үпте.

Хәдичә тирән итеп көрсенеп куйды. Ул тынычланган иде. Ире аны, әлбәттә, сөя. Хәдичә Хөсәеннең куенына ук кереп утырды, бармак бите белән аның мыегын сыпыра башлады.

— Җәйгә эти безне кунакка чакырды, — диде ул.

Хөсәен җәһәт кенә кашларын күтәреп куйды.

— Юк, быел җәй эш бик күп булыр кебек, Хәдичәкәй. Хәер, белмәссең, — дип өстәде ул бераз уйлангач, — бәлки, барып та чыгарбыз.

Хәдичә тагы баягы мәсьәләгә кайтты:

— Хөсәен, мин синең карашың, мәсләгең турында Чистайда чакны бик күп баш ваттым...

Ләкин сүзен әйтеп бетермәде. Кинәт кемдер, бөтен өйне тетрәтеп, капка дөбердәтә башлады. Хөсәен дәррәү урыныннан сикереп торды, ашыгып киенә башлады.

— Бар, ач, тик озаграк маташ, тегеләр булса кирәк, — диде ул, агарынып. — Мин сез кереп җиткәнче ычкынган булырмын.

— Ничек? — диде Хәдичә, куркынып.

— Мин өйдә юк, — диде Хөсәен. Шундый куркынычлы бер минутта иренең югалып калмавы Хәдичәне бераз тынычландырды. Ул үзенә иптәшкә Нәкыяне уятты. Ул арада куркынган Бибифатыйма да күренде.

Аз гына арада бөтен семья аякка басты. Ә капка дөбердәтүчеләр ни өчендер кинәт тындылар. Капканы Шәфигулла абзый ачты, ахры. Барысы да тынып көттеләр. Кинәт ишек алдында кемнәрдер тавышлана башладылар. Колакка тимер чыңлавы ишетелеп китте. Бераздан өй ишеген дөбердәтергә тотындылар. Хәдичәнең башына килгән беренче уй Хөсәеннең язмышы иде. Ул Нәкыяне уяткач, әле генә Хөсәен ялгызы калган бүлмәгә яңадан ташланды. Ләкин, гаҗәпкә каршы, анда хәзер ире юк иде. Аның үзе белән алып кайткан китап-брошюралары да, эшләпәсе дә күренми. Хәдичәнең башына, Хөсәен караван астына яшеренгән, ахры, аннан бик тиз табарлар бит, дигән шомлы уй килде. Ләкин Хөсәен анда да юк булып чыкты. Артык вакыт калмады. Ишекне котырынып-ярсып шакыйлар иде. Хәдичә йөгереп залга чыкты һәм, шашып аптырап калган Нәкыяне нәртеп, ишек ачарга төшеп китте.

Ишек янында озын буйлы ябык пристав белән берничә полицейский торалар иде. Алар артында Шәфигулла абзый да Хәдичәнең күзенә чагылып китте. Аны пүнәтәй итеп нәрткәннәр, ахры.

— Мадам! Бик каты йоклыйсыз, — диде пристав. Тавышы кискен һәм ачулы иде аның.

— Төн уртасы ич, ничек йокламаска! — диде Хәдичә. Полицейскийлар дөбердәп өскә менә башладылар. Ишек төбендә дә, капка төбендә дә аларның кешеләре күренә иде.

Хәдичәнең үз гомерендә беренче тапкыр мондый хәлдә калуы иде әле. Ул һаман Хөсәен турында уйланды. Бу кылычлы, револьверлы усал кешеләр аның кадерлесен тотарлар да хәзер үк төрмәгә, караңгы тынчу зинданга илтеп ябарлар кебек иде. Ул барлык көчен куеп сынатмаска тырышты, бөтен тәненә салкын тир бәреп чыкты, тез буыннары калтыранды.

Пристав, өй эченә керү белән, Хөсәенне таптырды. Хәдичә кинәт сулышы тыгылуын, башына ниндидер кайнар дулкын менүен һәм авызы артык кибеп китүен тойды. Ул бер мәл телдән язып калды.

— Хөсәен Минһаҗ улы Ямашевны сорыйм мин сездән! — дип кычкырды пристав. Хәдичә аның чекри соры күзләрендәге усал очкынны, тычкан койрыгыдай нечкә мыек чылгыйларының нервланып селкенүен абайлады.

Ярдәмгә Бибифатыйма килде. Ул барысыннан да тынычрак иде. Русча ватып-сындырып булса да, ул Хөсәеннең өйдә юклыгын, аның көндез үк университетка китүен, хәзер иптәшләре белән шул уку йортына керергә әзерләнеп йөрүен аңлатырга тотынды.

— Нәрсә сөйли ул, әйбәтләп русча аңлатып бирегез, — диде пристав Хәдичәгә. Хәдичә бераз тынычлана төшкән иде инде, русча төшендереп бирде.

Полиция чиновнигы әле яна гына өйгә килеп кергән яшел күзле, сюртуклы бер кешегә текәлде.

— Сез нәрсә?! — диде ул тәнбиһ белән.

— Ваше благородие, — диде теге, — ул өйдә, яшеренгән булырга тиеш. Алдый мадам.

— Тентергә! — диде пристав. Иң беренче булып түр якка әлеге сюртуклы кеше үзе узды. Аның кулында камыш таяк, башында котелок эшләпә иде. Ахры, бу кеше Хөсәен күп тапкырлар әйткән филер, шымчы иде. Күрәсең, ул әле дә Хөсәен артыннан сагалап килгән. Бәлки, ул аның яшеренгәнен белә дә торгандыр.

Хәдичә куркуыннан хәлсезләнеп утыргычка чүкте. Озакламый тентү башланды. Барлык бүлмәләр каралды, барысы актарылып ташланды. Өйалдындагы баскычтан менеп чарлакның астын өскә китереп төштеләр, ниһаять, фонарь яндырып, үзләре белән Нәкыяне ияртеп, подвалга төшеп киттеләр.

Барысы да яңадан залда очрашкач һәм эзләгәннәрен таба алмагач, утырып протокол язарга керештеләр. Хәдичәнең күз алдыннан үзе белгән китаплар, брошюралар һәм прокламацияләр узды.

Тентүчеләр бик бәйләнчекләнеп барлык нәрсәне тикшерделәр. Стеналардагы шамаилләргә кадәр әйләндереп карадылар. Шкафтагы китапларны туздырып ташладылар. урын-җирне, сандыкларны, кер саклана торган комод ящикларын актардылар. Ләкин, бәхеткә каршы, берни дә таба алмадылар.

Ниһаять, алар, тентү нәтиҗә бирмәде дип язылган протоколга кул куйдырып, таң сызылып атканда китеп бардылар. Хатын-кыз шашыптетрәнеп зал уртасында басып калды. Бөтен өй эченең асты өскә килгән, тузган. Хуҗаларның бүген өйдә нинди дә булса тәртип урнаштырырлык хәлләре дә калмаган иде. Барысы да курку һәм хурланудан бетерешкәннәр, алҗыганнар иде.

Хәдичә тузгытып ташланган караватка ятты да балаларча үксеп еларга кереште. Менә аның күрәселәре шушы икән!

Ул газаплы уйлар белән бәгырен телгәләвендә булды. Бераздан кемнеңдер сак кына адымнар белән караватк янына килүе ишетелде. Кемдер хатынның башыннан сыйпады. Хәдичә яшьле күзләрен күтәреп карады һәм, ни әйтергә дә белмичә, тынып калды. Янында Хөсәен басып тора иде.

— Я, нигә еларга? — диде ул. — Яле, күз яшьләреңне сөртик.

Кесәсеннән Хәдичә үзе бөгеп биргән ак кульъяулыгын алды, хатынының күзләрен сөртә башлады. Хөсәенне күргәч тә туган беренче гаҗәпләнү һәм шатлык минутлары узды. Хәдичә кинәт шомлана башлады.

— Кая яшеренеп калдың син? — диде. — Сине бит хәзер тотып алалар.

— Алмаслар, алар киттеләр инде, — диде Хөсәен, тузанга буялган пиджагын каккалап.

— Кайда яшеренеп тордың син? Мин куркып үлә яздым.

Хөсәен саран гына елмаеп куйды.

— Үз өемдә ничек тә җаен таптым инде.

— Ходаем, — диде Хәдичә, — карале, йөрәгемне тотып карале, зинһар, һаман сикерә әле.

Хөсәен кесәсеннән бая үзе белән алган китапларын чыгарды, аларны, учы белән сыпыргалап, өстәлгә салды.

— Менә минем бәхетем шул икән инде, — дип куйды Хәдичә.

— Ә ул хакыйкатән бәхет!

Хәдичә, колагы ишеткәнгә ышанмыйча, Хөсәенгә текәлде:

— Нәрсәсе бәхет аның? Шулай тетрәнеп яшәүме? Шулай хурлык һәм түбәнлекләргә дучар ителүме?

Хөсәен урыныннан купты да килеп Хәдичәне кочаклады.

— Куркулар, тетрәнүләр алар барысы да узгынчы, Хәдичәкәй. Ә түбәнлек, хурлык юк монда. Түбәнлек ул беләсеңме ничек була?

Хөсәен бераз тынып торды да:

— Әнә теге камыш таяк тоткан котелоклы кеше бар бит, — диде. — Күзенә чалындымы? Әнә шуның көненә калу ул түбәнлек.

— Син аны беләсеңмени? Ул бит сине сагалап килгән, Хөсәен, ничек сизмәдең соң?

Хөсәен дәшмәде.

Ул ашыкмыйча гына чишенде, аннары караватка барып ятты.

— Син артык өзгәләнәсең, Хәдичә, — диде ул. — Мин сиңа бик авыр икәнлеген беләм. Ләкин бит авырлык әле ул бәхетсезлек түгел. Үзеңнең мәсләгең өчен көрәшеп яшәү, үз кыйблаңа таба көрәшеп алга бару бәхетсезлекме әллә?

— Мин сине югалтырмын дип куркам.

— Шулаймы? — Хөсәен яткан җиреннән сикереп торды һәм хатынына үзенең эшләре, максатлары турында сөйли башлады. Ләкин боларның берсе дә аның Хәдичәсенә булган мәхәббәтен киметмиләр, киресенчә, зур, бай эчтәлек белән сугаралар. Бу минутта Хәдичәнең күз алдына тимердәй салкын явыз пристав килеп басты. Аның артыннан ук әлеге сатлык җан филер... Әйе, Хәдичә я шуларны, я булмаса, үзенең янында яткан кешене якларга тиеш.

*(Дәвамы бар.)*

—□—

*Шәүкәт Галиев*

# ЯҢА ШИГЫРЬЛӘР

* * *

Җир баласы идем, үлән ашап,
Каеннарны имеп үскәндә,
Чишмәләрдән кайнап чыккан суны
Кайнатмыйча гына эчкәндә.

Җир баласы идем, чап-чап басып,
Яланаяк йөгереп йөргәндә,
Җиргә якын, туфракка үз идем,
Салмак атлап сабан сөргәндә.

Куркасы юк кием буялыр дип,
Тәләгәнчә сузылып ят инде!
Ыспай киенеп килгән вәкилләр
Җиргә, безгә ул чак ят иде.

Мин үзем дә хәзер асфальт таптыйм,
Әмма шунсын үтим ачыклап —
Шигърияттә кырлар илчесе мин,
Чын туфракны кайтам тансыклап.

Җырларымны дөресләргә кайтам,
Сыенырга кайтам җан тартып —
Толстой да яланаяк йөргән,
Җиргә якынлыкны яңартып...

Туган туфрагымнан, игенчедән
Яшим табигыйлек, көч алып.
Кайчан гына кайтып күрешсәм дә,
Ачык миңа кырлар кочагы.

* * *

— Яшьләр, яшьләр, кая ашыгасыз?
— Ни кызык бар безнең якларда —
Сәфәр чыктык яңа җирләргә без,
Офыкларны үтеп атларга!

— Картлар, картлар, кая юл тоттыгыз?
— Сагындырды илләр ифрат та.
Читтә йөреп гомер әрәм үтте,
Кайтып ятыйк туган туфракка...

* * *

Тормышымда
Азмы күрелгән,
Азмы бәгырь
теленгән?
Аз булганмы
Сыкранулар,
Сукранулар?
Аз булганмы
Икеләнүләр,
Ээләнүләр,
Үзгәрүләр?
Каләм алсам,
Узган юлны
Җыр юлына салсам,
Һәммәсе дә шома,
шома...
Газапланам шуңа!..

* * *

Ашыкма, каләм,
Күптән күнеккән
Юлларга борма,
Трамвай шикелле
һаман бер эздән
Чабарга торма!

* * *

Яшьрәк чакта барыбыз бергә идек,
Дустың иде һәрбер табындаш.
Тормыш күргәч, ил танығач, хәзер
Күңелләрдә күбесе табылмас.

Килер еллар, беләм, минем йортка
Кочак-кочак дуслар китермәс;
Тик фикердәш чын дус була икән,
Сирәк була икән фикердәш...

* * *

Сабыр диеп,
Тыйнак диеп,
Мактадыгыз безне
Аркабыздан сөеп,
Күкләргә чөеп.
Тыңладык без
Җылы сүздән сөеп,
Горур башны
Түбән иеп.

Баксак —
Тынычландыру икән,
Юашландыру икән
Сезнең максат!

Шуңа күрә минем
Кызасым килә,
Тузасым килә,
Үзем турындагы
Шәп фикерне
Бозасым килә!

* * *

Үнеченче елга чагыштырып
Сөйләүләрнең бетте кызыгы —
Ул дәрәҗә күптән артта калды,
Ул дәрәҗә күптән узылды.

Заманасы бик акыллы хәзер —
Галәмгә дә уйдык тәрәзә.
Шигърияттә әмма үрнәк һаман
Унөченче елгы дәрәҗә —
Бөек Тукай торган дәрәҗә!

* * *

Исемеңне алып җырга куштым,
Җырым китте илләр буена.
Исемеңә туры килә диеп
Җырлаганнар, диләр, туеңда...

Җырдан алып хәзер исемеңне
Кызларына күпләр кушалар.
Эх, ул кызлар синдәй гүзәл булса,
Синнән бәхетлерәк булсалар!..

## Хәтерлим

Җиләк өзеп бирдең син миңа,
Һәм өздереп күзгә карадың.
Күзләреңнән сине аңладым,
Җиләкләрне генә алмадым.
Җиләк күргән саен хәзер мин
Әллә нигә сине хәтерлим.

Чәчләремә чәчәк кададың,
Иңнәремә кул да салмадың.
Әллә мине ялгыш аңладың,
Озатырга нигә бармадың?
Чәчәк күргән саен хәзер мин
Күрсенәм дә сине хәтерлим.

Бер сүз әйткән идең син миңа
Очраганда беркөн кич белән,
Тынгы белмим инде һич кенә,
Кабат-кабат уйдан кичерәм.
Хәтерлим мин, барысын хәтерлим,
Оныталмыйм сине хәзер мин...

## Сөйгән ярым минем тылсымчы

Ул югында дөнья тонык, төссез,
Тирә-якны күпме күзләмә...
Ул килдеме, әкияттәге сыман
Бер мизгелдә барысы үзгәрә:

Зәңгәрләнә күкләр, яктыра көн,
Каеннарның арта аклыгы,
Куакларда кошлар телгә килә,
Иңә җиргә таңның сафлыгы.

Йокымсырап, оеп йөргән чакта
Килә дә ул әллә нишләтә —
Канны кайнарлатып, ут уйнатып,
Искитәрлек эшләр эшләтә.

Үзгәртә ул шулай бар дөньямны —
Сөйгән ярым минем тылсымчы.
Минем янга килсә ул тылсымчы,
Минем янда гына торсынчы!

* * *

Белеп булмый, кай якларда сине
Нинди яңа җырлар көтәсен —
Кыска гына шигырь юлы өчен
Озын-озак юллар үтәсең.

* * *

Үткәннәрне хөкем итү ансат,
Күрү җиңел алар ялгышын;
Киләчәкнең үлчәү табагына
Синең дә бер төшәр язмышың...

* * *

Ярмаланган карлар саркып ята,
Яшел чирәм үрләр түрендә;
Әйтерсең лә, шунда яланаяк
Чабып йөргән чагым күренә...

* * *

Күпсенгәннәр күпме казынмады,
Бәйләнерлек урын табылмады.
Рәхәтләнеп бер тәпәләр өчен
Көтә алар минем абынганны.

* * *

Үзең юк... Рәсемнән генә
Күзләреңә карыйм мин.
Моңнарыңны да аңлыйм мин,
Тик юата алмыйм мин...

* * *

Сурәт сурәт инде — дәшми,
Берсүзсез карап тора...
Бик сагынган минутларда
Шунсы да ярап тора!

* * *

Хак түгелме, хакмы, алар барда
Үтәлүчән була кушканнар.
Каян килә димсең ул куш җаннар?
Ашатучы барда — куштан бар.

* * *

Миңа каршы сине котырта ул,
Сиңа каршы мине котырта,
Шулай итеп үзен оныттырта,
Кем җиңсә дә һәрчак улота!..

——□——

## *Равил Фәйзуллин*

* * *

Туган якка оча аккош.
Җилпенүе җиңел икән!
Сәлам яздым канатына,
Күрдегез микән?

Туган яктан оча аккош.
Кагышлары авыр, авыр.
Канатларыннан укыдым:
«Итә күр сабыр!»

## Читтә

Кемгә хаҗәт шатлык-кайгың?
Янма, көймә — барыбер ят син.
Хәтта матурлыгы үрти:
«Син кем кадерлесе монда!..»

Кеше сабыр. Түзә. Күнә.
Иялэшә күз дә, тел дә.
Ә җан тынмый — үрсәләнә —
«Син кем кадерлесе анда?..»

* * *

Яшь беткәнче елыйлармыни?
Ни йотарсың, дошман янап:
«Ялын! Ялвар!» дисә?
Яшь беткәнче елыйлармыни?
Күзең ни белән белдерер
Күкрәп шатлык килсә?

* * *

Көн шыксыз дип карадым,
Юл котсыз дип карадым.
«Казармага кадәр, дидең,
Барам дигәч, барамын!»

Килеп җиткәч, күзгә карап,
Бераз керми тор, дидең.
Күк зилзиләсенә ымлап —
Үзәк өзгеч җыр, дидең.

Хәрбиләрчә коры гына
Бу җыр түгел, кар, дидем.
Үзем җибәрмәскә кочкан,
Үзем: кайтчы бар, дидем.
Кердем, киттем. Син урамда
Калдың буран эчендә...

. . . . . . . . . . .

Хәзер май. Җирдә яшеллек.
Карның беткән исе дә.
Ә ул көннең ул бураны
Бөртегенчә исемдә.

Карап ятам казармадан,
Майның аяз кичендә.
Күз алдымда син торасың
Яшел буран эчендә.

* * *

Ярлар күчәр, дулкын бәрсә.
Тик... торсыннар безнекеләр!
Тимәгез җанкайларга!

Ут естенә ут өрмәгез!
Болай да ялкында без.
Тимәгез җанкайларга!

Исән булып бер кайтырбыз,
Ничек тә бер юатырбыз...
Тимәгез җанкайларга!

* * *

Куеп тереклек итүнең
Мең башлы мәшәкатен,
Куып бер якка көннәрнең
Каһәрен һәм шәфкатен,
Үз хозурында бу җанны
Бер рәхәткә талдырып,
Керфек эрерлек яшемдә
Кояшны чагылдырып,
Килә елыйсы кайчакта,
Килә өзгәләнәсе!
Ярый — нечкәрәбез. Юкса
Нишләр җирнең бәндәсе...

* * *

Шатлыгы киләмө бүген?
Әллә кайгысы микән?..
Нигә әле бу уй башта?
Кыр казы исе килә!

Бу яз көнне, аяз көнне
Сөеп назлыйсы килә!
Җаны йокымсыраучыга:
«Терел! Яз!» — дисе килә!

Бардыр... Бәлки, кемнәрнеңдер
Кабер казыйсы килә...
Бу чакта ничек үлим соң —
Кыр казы исе килә!

## Мескен

Дуслыгының тирәнлеге
Бары ике илле!
Шуның өчен нигә ул ел
Көчәнергә иде?

* * *

Кайгы чәчеп, җыя икән
үзенә шатлык —
төкер аңа!
Шатлык чәчеп кайгы урсам да
шөкранә!

* * *

Минем турыда
шатлыклы сүз ишетсәгез —
җиткерегез әниемә.
Хәсрәтле сүз ишетсәгез —
сөйгәнемә.

## Күз

Язын өмет булган икмәк
келәт тулы, чолан тулы...
Тышта яңгыр. Өйдә рәхәт —
мич алдында җылы!

Чү! Әнә сабан тургае
тәрәзәгә кунган!
Күңелем убылып китте:
тамчы гына булган...

* * *

Катлаулы икән,
кызык икән
тормыш гармониясе!
Әле ия, әле чөя,
әле сөя, әле төя!..

Ә син миңа
шуның барысын
көйлә дисең
бер көй белән?

Күз — дәрья.
Күңел — дөнья.

Сыйган аңа
шарлавык та,
тын елга да,
бал да, кан да,
гөлле уч та,
ут-кылыч та...

Төрле көчтә,
төрле эштә,
төрле тында,
төрле тонда,
төрле тәмдә,
төрле ямьдә
шигырьләр дә!

* * *

Тышка чыксам, өн ишетәм:
«Сак бул, зинһар! Гарип итмә!
Без дә кешеләр шикелле —
җан кирәк һәм кан кирәк!»

Өйгә керсәм, өн ишетәм:
«Гарип итмә! Гарип итмә!
Без дә кешеләр шикелле —
җан кирәк һәм кан кирәк!»

Мин сүзләрдән сурәт ясыйм, —
алар миннән җан сорый.

* * *

Башны салларга салып
китәсе иде агып...
Бер күңел булыр иде!
Шатлыгым ургыр иде,
я сыктап-сулгыр идем...
Башны салларга салып
китәсе иде агып.
Дәшәр әле дулкыннар
бер шагыйрь җанны танып...

*Рәшит Гатауллин*

## Барысы да әле ярты юлда

Барысы да әле ярты юлда,
Өметләрем, язылыр җырларым.
Барган саен авыррак кебек,
Озынрак кебек юлларым.
Авызлыгын чәйнәп чапкан
аттай
И талпына йөрәк...
Ярсый ла.
Сез көтегез мине,
тик көтегез,
Юлда әле, юлда барысы да...
Күпме кеше өмет төяп
чыгып
Ярты юлда калган тукталып.
Калганнары калган...
кайберләрен
Алып барып чыккан җырлары.

Барысы да әле ярты юлда,
Ә барасы ерак, бик ерак.
Берсен-берсе куып
хыялларым,
Шигырьләрем килә юл сорап.

●

Әллә нигә уйландыра:
Күккә баксаң уйландыра,
Җиргә бассаң уйландыра.
Әллә нигә гомер буе
Баш очымда уйлар тора, —
Бер тарала, бер куера.
Ятуымны көтеп тора
төрле уйлар,
Иртәләрен тормас борын
көтеп тора.
Кайчагында уйларыма
кояш куна,
Күп чагында уйларымда
болыт була.
Әллә нигә уйландыра:
Күккә карап уйландыра,
Җиргә карап уйландыра,
Уйландыра...
Тормыш, мине моннан соң да
Уйландырмый уяндырма.

—□—

*Габдрахман Әпсәләмов*

# ЯФРАКЛАР КОЕЛА

*Язучының күңел дәфтәреннән*



*Х. Әхмәтҗанов рәсеме.*

Эх, бу тормыш...

Көтмәгәндә, уйламаганда авырып киттем. Иң яхшы хыяллар да, киләчәккә төзелгән мавыктыргыч планнар да, яшәүгә үзеннән нур өстәп, аңа кабатланмас мәгънә биреп торган хезмәт тә, семья тынычлыгы да — барысы-барысы да челпәрәмә килде. Инде һәммәсен, бала кебек, яңабаштан башларга кирәк. Әгәр гомерне дә шулай яңадан башлап булса, моңа артык көенмәс тә идең, әмма, аккан су кире кайтмаган кебек, яшәгән көннәр дә кире кайтмый. Күрәсең, җимерелгән, ватылган, какшаган арбаны актык станциягә кадәр шулай тартырга туры килердер...

Ике айдан артык больницада ятуларны язмыйм. Белгәннәр белә, белмәгәннәргә күрсәтмәсен. Больницада чакта шул сүзләрне ишетеп калган идем. Гыйбрәтле сүзләр. Анда авыруларның үзенә күрә тормыш фәлсәфәсе тупланган. Моның белән килешмәскә мөмкин, ләкин игътибарсыз калдыра алмыйсың. Әрнү дә, моң да, йокысыз үткән төннәр дә барысы бергә җыелган монда, аз гына кузгатсаң да йөрәккә тия.

Инде, ниһаять, балконга, аннары ишек алдына, ахырда йортыбыздан илле-алтмыш адымдагы бакчага чыга башладым. Беренче көннәрдә мин моңа бала кебек шатландым: шушы кадәр сынау, газаплардан соң терелү! Моны бит әйтергә генә ансат. Инде якты дөнья белән саубуллашкан, бар кебек гомергә һәм эшләнгән эшләргә, ничек булдыра алсам, шулай йомгак ясалган иде. Шуннан соң яңадан терелә башла, имеш. Моңа шатланмас җирдән шатланырсың һәм, әлбәттә, яшәү турында уйланырсың. Кеше, мөмкинлек барында, бу дөньядан тиз генә китәргә теләми икән!

Авыруның күңеле бик болытлы. Тормышны никадәр яратсаң да, никадәр оптимист булсаң да, тора-бара салкын зынҗырлар сине селкенмәслек итеп кысып ала. Яктыра башлаган дөньяң, чыга башлаган кояшың яңадан әллә кая тәгәри, суык җилләр исә. Син башыңны иясең...

Мин бакчага чыга башлаганда, карт юкәләр әле яфрак та ярмаган иде. Бакча үтәдән-үтә күренә, әйтерсең, бөтен матурлыгын ачып куйган. Аннары яфраклар куера, эреләнә. Сиңа инде күп нәрсә күренми, ләкин син яшел шау-шуга җинелчә генә исереп утырасың. Әлбәттә,

сәламәт кешеләрнең моңа артык исләре китми, аларның үз эшләре бар: алар каядыр ашыгалар, бакчада аз гына вакытка туктыйлар, нидер бәхәсләшәләр, аннары тагын чабалар. Безнең ише кешеләрнең генә ашыгыр эше юк, гүя алар арбадан төшеп калганнар, уйланалармы, болай утыралармы — аларга берәү бер сүз әйтми. Ник көне буе шунда булмыйлар.

Атап әйтерлек эшең булмагач, тирә-юньне күзәтәсең. Кызык икән ул зур шәһәрнең бакчасы. Тере кебек, яшь кебек ул. Болай гына узып китсәң, моны сизмисең дә. Агачлар, эскәмияләр, аллеялар, ял итүчеләр... — барысы да бер-берсеннән аерым, бәйләнмәгәннәр кебек. Әмма көннәр, атналар, айлар утыра башласаң, серләр әкрен-әкрен генә ачыла, пәрдәләр күтәрелә һәм син чак кына гаҗәпләнәсең: күр, бакчаның үз тормышы бар икән!

Безнең бакча шәһәр үзәгенә бик якын булса да, ул ничектер калага аркан утырган кебек. Зур һәм мәшһүр исеме аны коткара алмаган: аның кайда икәнен күпләр белмиләр дә. Тик шул тирәдәге йорт хуҗалары һәм студентлар гына аны үз иткән. Имтиханнар якынлаша башлагач, бакчаның барлык урындыклары яшь-җилкенчәк белән тула, утырыр урын табу да читенләшә, бигрәк тә иртәнге һәм өйләдән соңгы сәгатьләрдә. Урындыклар китап, дәфтәрләр белән тулган була. Соңыннан студентлар сирәгәя, ахырда тәмам бетә. Бакча бер мәлгә тынып, бушап кала, анда инде балалар белән картлар гына хөкем сөрә. Ә син... .һаман утырасың. Таякка таянып, эшләпәң астыннан әйләнә-тирәңне тын гына күзәтәсең. Күрсенмисең, зарланмыйсың, әмма синең бу күз карашыңны кешеләр күрмәсә яхшырак булыр иде. Ниндидер авырлык, хәсрәт һәм бетмәс-төкәнмәс уй бар анда. Хәер, уен тәгаен генә әйтеп тә булмастыр аның, бәлки уй да түгелдер ул, ниндидер әйтелмәгән, эшләнмәгән һәм инде беркайчан да эшләнмәячәк, әйтелмәячәк бер нәрсәдер. Очы да юк аның, кырые да.

Бераз вакыттан бакча тагын бераз җанланып, терелеп китә: аны яшьләр сырып ала. Аларга карыйсың да аз гына көләмсерәп куясың: тәҗрибәләре дә юк, киемнәре дә башка сыман. Алар әле мәктәптән арынып җитмәгәннәр. Кичәге белән бүгенге арасында яшиләр. Ләкин алар инде институтларга керү имтиханнары тапшыралар. Нәкъ шул күчмә хәлнең беткәнлеген белдереп, бакчада студентлар юкка чыга һәм анда тагын шул пенсионерлар белән авырулар гына кала. Билгеле инде, карчыклар бар җирдә бала-чага кайнаша...

Күр, яфраклар коела инде! Әле күптән түгел генә берәм-сәрәм өзеләләр иде алар, аннары әкрен генә, теләр-теләмәс кенә һавада кыйгачлап очалар иде. Күбесе яшел була иде. Ләкин кулыңа алып карасаң, аларда җан әсәре юк, төсләре яшел булса да, җилекләре кипкән. Күрәсең, болар шулай яшел килеш, агач башында торган килеш (нәкъ искәрмәстән авыруга дучар булган кешеләр кебек) яшәүдән туктаганнар. Аларга әллә нихәтле карарга һәм уйланырга мөмкин, тик уеңның очына гына чыга алмыйсың.

Әкренләп яфраклар саргая, күбрәк коела, хәтта җилсез көндә дә өзелеп җиргә төшәләр, эскәмияләргә яталар.

Бакчага чыга башлаган көннәремнең берсендә мин бер танышымны очраттым. Я алла, нинди шатлык! Ул минем белән кочак җәеп күреште, бик шат, бик шат, болай булгач, бирешмисең, дип тезеп китте. Мин халык арасына яңа чыгучы булганга, эредем дә киттем. Кызыксынгач та, сораштыргач та аңа авыруымның бөтен тарихын сөйләп бирдем. Хәтта башкаларга сөйләү түгел, үземнән дә яшерә торган (кайчагында үзеңне дә алдыйсың икән) хәлләрне дә аңа ачтым. Шулкадәр өметләндерүче, шулкадәр яхшы сүзләр әйтүче икенче берәүне

тагын кайчан табарсың! Кыскасы, мин аның сәгатенә карап алуын да сизмәдем, сөйләдем дә сөйләдем. Аннары... аннары шул ук бакчада мин аны кабат күрсәм дә, ул минем яныма туктамады. Кайчак баш иеп, кайчак читкә карап үтә башлады. Билгеле, аның күрмәмешкә салынуына мин бик рәнжедем, ә соңыннан... күнектем. Чөнки ул бер үзе генә шулай эшләми, башкалар да шулай итәләр иде. Кешеләрнең шушы беркатлылыгына мин бик озак карап тордым, исем китте. Ә соңыннан шундый фикергә килдем: сәламәт кешеләр авыру янында нишләсеннәр, бер-ике мәртәбә, хөрмәт йөзеннән, хәл сораштыралар да шуның белән эш бетә, сөйләр сүз калмый, чөнки алар синең хәлеңне сорыйлар, ә син аларга шул һаман бер нәрсәне — авыруыңның тарихын сөйлисең. Моның кемгә кызыгы булсын!

Шушы кечтеки генә хакыйкатьне аңлагач, мин үзәк юлдан ераграк утыра башладым. Хәзер инде кешеләргә читтән генә карыйм.

Ахырда шундый көн килеп житте, күңелем тәмам кайтты, бакчага теләр-теләмәс кенә чыга башладым. Аннары авыру да үзенекен итте. Минем хәл көткәнчә үк яхшырмады, атналар, айлар үтә торды, ә авыруым гүя кузгалмый, гел бер урында кадакланган кебек, алга китеш һич юк. Вакыты да бик әкрен үтә, мин әйтер идем, чамасыз әкрен үтә. Сәгатем туктаганмы әллә, дип ничә алдандым...

Әйткәнемчә, бакчада пенсионерлар байтак иде.

Менә шуларның берсе минем хәлне аңлады булса кирәк, таякка таянып, бер читтәрәк арлы-бирле агылучы халыкны күзәтеп утырган җиремә ул да килә башлады. Билгеле, башта мин аңа да бик салкын карадым, бераз такылдар да китеп барыр, дип көттем. Әдәп йөзеннән тыштан гына ачык чырай күрсәтүне һәркем дә аңлый лабаса! Ләкин Громов — фамилиясенә игътибар итегез, зинһар — торып китәргә ашыкмады. Минем төксе утыруымны сизгәндер, билгеле, аннары авыру кеше тойгыларын алай ерак яшерә дә алмый бит. Әмма мин аның тарафыннан бернинди дә ясалмалык сизмәдем. Ә берничә көннән аңа яхшы ук ияләштем, танышымның бакчага чыгуын үзем көтә башладым. Озаграк килмәсә, турсайган чакларым да булгалады. Тик мондый күңелсез минутлар артык озынга сузылмый. Ул, бакча башында ук карчыгыннан аерылып, минем яныма килә һәм берничә сүз белән тоткарлануының сәбәбен әйтеп бирә иде. Шул ук вакытта ул күзләре белән карчыгын барларга да өлгерә.

Громов сөйләргә яратса да, телендә әллә ни бизәкләр юк, укымышы да чамалы. Боларны ул беренче көнне үк сөйләгән иде. Ләкин аның сөйләшүендә кешене якын иттерә торган икенче бер нәрсә бар. Мин исә андый нәрсәгә бик игътибарлы. Шуңа күрә без бер-беребезгә бик мач килә идек.

Ул үзе уртачарак буйлы, корсагы бик аз ускән, шуңа күрә гәүдәгә шактый төз күренә, аяклары бераз кәкрерәк. Ялгышмаганмын икән, соңыннан үзе дә сөйләде: яшьлегендә ул кавалериядә хезмәт иткән. Күзләре, кыр чәчәге кебек, зәңгәр, ничектерерактан һәм сыный төшеп карыйлар. Чәчен такыр итеп алдырган, башы ярыйсы матур. Көннәр эссе торганга, өстендә я бөрчекле чуар күлмәк, я тимер юлчылар кия торган кыска яшел форма була. Погон эзләре бераз беленеп торса да, погоннары инде күптән юк. Җиңел эшләпәсен күбрәк кулында тота. Яхшы үтүкләнгән кара чалбар белән кара туфлиләр артык күзгә ташланмый. Борыны кылыч, яисә, халык әйтмешли, карчыга борын. Сакал-мыек һәм чәч кырылган булганга, аңа ничә яшь икәнен тәгаен генә әйтеп булмый, әмма үзеннән ишетеп аңа җитмешләр тирәсе икәнен беләм. Җитмеш өчен ул шактый яшь күренә иде әле.

Вакытында зуррак квартир алырга мөмкинлеге булса да, нәфесен тыя белгән. Хәзер карчыгы белән унөч метрлы бер бүлмәдә тора. Бер-

дәнбер кызы күптән инде тормышта, Белоруссиядә. Карчыгы гипертония белән авырый, ләкин телевизорны бер дә калдырмый. Кызыклы тапшырулар булса, бакчадан тизрәк кереп китәргә тырыша. Бигрәк тә хәрби картиналарны карарга ярата икән, чөнки яшьлегендә озак еллар хәрби сестра булып эшләгән. Карт үзе, футбол булмаса, телевизорга болай исе китми. Пенсиягә чыккач, биш-алты ел буе йорт идарәсендә парторг булып эшләгән. Хәзер инде тыныч, карчыгын гына карый.

Громов белән мин моннан 20—25 еллар элегрәк танышкан булсам, ихтимал, аның турында зуррак әйбер язарга да тотынган булыр идем. Хәзер инде озын язарга күңел теләми, аннары, гомумән, бүгенге эшне бүген бетерәсе килә. Громовның исәпсез күп грамоталарын күздән кичергәч, уйлап та куям: юк, болар инде үткән тормыш билгеләре, болар турында язар өчен шул тормышка кайтып чумарга кирәк, болай алар җансыз кәгазьләр генә. Сине җылытмаган, дулкынландырмаган шикелле, башкаларны да дулкынландырмас.

Менә шул, без бакчада утырабыз, әкрен генә яфраклар коела. Сары яфраклар хәзер көннән-көн күбәя. Әкрен генә трамвай тавышлары ишетелә. Бәлки трамвай тавышлары да түгелдер, коелган яфрак шулай кыштырдыйдыр. Тыңлыйсың, шул ук вакытта эчтән генә уйлыйсың: моның миннән башка кызыксынучысы бармы икән? Кешеләр яшәү белән мәшгуль. Үткән дә беткән, моның нәрсәсе аларны мавыктырсын?

— Кешеләргә үпкәләргә ярамый, — ди Громов, минем уйларны белгәндәй. — Бу тормышта бернәрсә дә эзсез үтми, ләкин яшь кеше күбрәк хәзерге реаль тормыш белән кызыксына, аның капшап карыйсы килә. Кеше тотарга, капшарга ярата!

Ләкин кызык хәл: ул үзе күбрәк үткәннәрне сөйли. Тора-тора да шул ерак үткәннәрне хәтер чоңгылыннан өскә чыгара. Әллә инде тыңлаучы табылганга шатланамы? Хәер, аның өчен үткәннәр коры сүз генә түгел. Ул, зәңгәр күзләрен кыса төшеп, каядыр еракка карый, әкрен генә көлә, я елмая. Ул күпне күрә, без белмәгәннәрне ишетә торгандыр. Мин шулай уйлыйм һәм аңа карыйм. Ялгышмыйм, һич ялгышмыйм. Менә ул ат өстендә чаба, кылычын уңга да, сулга да болгый; менә ул кызыл командир; менә ул тимер юлда эшли инде; ул чактагы тимер юл — ташка үлчим; ләкин еллар үтү белән ул тамырдан үзгәрә...

Громов тимер юл идарәсендә бик күп эшләрдә эшли, зур начальник була. Кул астында эшләүчеләр аны яраталар; ирелнми, кычкырмый, сүгенми. Бигрәк тә җирле милләт кешеләре белән үзен тигез тота, аларга тирән хөрмәт белән карый. Моның өчен югарыда аны яратып та бетермиләр. Ул елларда тимер юлда, бигрәк тә җитәкче урыннарда, татарлар аз була. Булганнары да русча ару сөйләшмиләр, ваталар, сындыралар. Ә тимер юл көненә ике тапкыр Мәскәүгә рапорт бирергә тиеш. Громов җирле халыктан кадрлар әзерләүгә бик җитди карый, аларны эшкә, хәтта сөйләшергә өйрәтә. Мәскәүгә рапорт бирергә булса, гел бүлегендәге татарларга куша, үзе шунда ук телефон янына килеп утыра. Егет рапортны дөрес бирә, тик акценты гына сизелә. Бу Мәскәүдәге тимер юлчыга ошамый, ул Громовны чакырып ала.

— Громов, синең башың икеме әллә?.. Кемне телефонга утырттың? Нәрсә, бирермен мин сиңа дөрес сөйләгәнне... Син анда татаркага өйләнгәнсең бугай...

Бервакытны Громовны үзен Мәскәүгә чакыртып алалар. Әлбәттә, күңелгә төрле уйлар килә, ихтимал, эшендә кимчелекләр дә бардыр, ул әүлия түгел, әмма куралатә эшләгән хаталар юк, монысын ул теләсә кемгә ярып салачак. Ләкин ул турыда аңа авыз ачарга да бирмиләр, дөресрәге, аның белән ул турыда сөйләшмиләр дә. Громовны

Мәскәүнең Казан вокзалына начальник итеп билгеләләр! Минем андый зур урыннарда эшләгәнем дә юк, фәлән-төгән дип әйтеп карый. Тыңламыйлар да. «Беләбез!» диләр. Ә вокзалда, хәтта урамнарда да кеше — дингез кебек, барысы кычкыралар, әрләләр, сүгенәләр, елыйлар. Барысына бер генә нәрсә — билет кирәк, каядыр Уралга, Урта Азиягә. Җитмәсә вокзал подвалларына шпаналар тулган. Елап килгән кешеләрдән араланыр хәл юк: кайсының чемоданын тартып алганнар, кайсының киемен салдырганнар. Кем эше — шпаналар эше. Әнә шунда төшеп киттеләр, дип исәпсез-хисапсыз вокзал подвалларына күрсәтәләр. Тик анда төшәргә сакчыларның йөрәкләре җитми, төшсәң, чыгу юк. Подвалларда үзенә күрә караңгы бер патшалык. Анда җылы, шәмнәр яна, җырлаган, сүгенгән тавышлар ишетелә, нәрсәдер саталар, алалар, каргыйлар, әрләләр.

Громов, яктыргач, беренче чиратта балалы хатыннарны озатырга куша. Ә икенче көнне, караса, аның ишеге төбендә балалы хатыннардан зур бер чират хасил булган. «Начальник, билет бир, Челкарга кадәр генә. Өченче көн инде ашаганыбыз юк...» Мең төрле кеше һәм барысында да шул бер үтенеч: «Начальник, билет бир...» Шабыр тиргә бата Громов, ләкин каян барысына да билет аласың?

Беркөнне аның янына вокзалда носильщик булып эшләүче бер татар килеп керә. Тыйнак кына исәнләшә, аннары озак кына аска карап тора, башын кашый.

— Начальник, яхшы эшләмисең бит, — ди ул, авырлык белән генә сүз эзләп. Үзе таза, киң җилкәле. Русча сөйләшүе — вата-сындыра гына. Татар икәнлеге әллә кайдан күренеп тора. Хәер, Мәскәүлеләр дә аның Казаннан икәнен белеп алганнар инде.

— Нәрсә дөрес эшләмим, Еникиев?

Күр, носильщикның фамилиясен дә белеп алган! Бу картка бик ошый. Ул начальникның үзенә кеше итеп каравын сизә. Гәүдәсен турайта, бүреген арткарак этәрә.

— Синең яныңа бүген бер яшь кенә хатын кердеме, начальник?

— Я, кергәндер.

— Баласы бар идеме?

— Минем янга баласызларны кертмиләр бит.

Еникиев башын селкеп алды.

— Шул шул. Ә син бернәрсә дә белмисең. Балаларны саталар!

Громов шакката.

— Нәрсә сөйлисең син? Кая саталар?

Бер карасаң, бик гади, бер карасаң, коточкыч хәл: спекулянтлар балалы хатыннарны сатып ала башлаганнар. Билгеле, балаларда аларның эше юк, аларга билет кирәк. Балалы хатыннарга билет бирәләр икән, нигә аларны шунда ук сату-алу эшенә җикмәскә. Спекулянтка акча исе генә кыйммәт, калганы аңа чүп.

Громов Еникиевка рәхмәт әйтә һәм бу хатасын бик тиз төзәтә. Хәер, монысы аның иң җиңеле була, ә менә аны шпаналар бик борчый. Ни генә эшләп карамый, әмма файдасы юк. Аптырагач, рәсми органнарга да әйтеп карый, ә анда болай да эш күп икән. Шул көннәрдә аның янына тагын Еникиев килә һәм подвалларга керү юлларын барысын да таш белән ябарга киңәш итә. Ташларны кипкәнче үк эчтән ватмасыннар өчен, ишек төпләренә сакчылар да куярга мөмкин. Шунысын әйтергә кирәк, Громов, әгәр килешсә, эшне бервакытта да озакка сузмый, бик коры һәм тиз тота. Бу юлы да шулай була. Кирпечләрне көндез үк ишекләр тирәсенә ташып өеп куялар. Төнлә, бөтен кеше йоклаган чакта, барлык ишекләрне дә кирпеч белән каплыйлар, тик бер-ике урында гына тәрәзәчекләр калдыралар, янәсе, сөйләшү өчен. Ике көн-

ме, өч көнме эчтән жыр гына ишетелә, кайчагында бик каты сугеләләр, бөтен вокзалны пыран-заран китерү белән яныйлар. Громов та, вокзал кешеләре дә тын гына йөриләр, төннәрен саклар көчәйтелә, подвалларга керми калган берән-сәрән шпаналар әкренләп барысы да кулга алына, шикле кешеләр шулай ук бетерелә. Бер атна дигәндә шпаналар гайрәт чәчүдән туктыйлар, сөйләшү өчен калдырылган тишекләр янына киләләр, чыгаруны үтенәләр. Ниһаять, Громов аларны берәм-берәм чыгара һәм чыгарган берсен Петровкага озата...

Громов боларны бик озак, бик тәфсыйллы итеп сөйли. Мин ашыктырмыйм, түземсезлек күрсәтмим. Безнең барыбер ашыгыч эш юк бит, бүгенге көн житмәсә, иртәгесе бар. Әлбәттә, сүз берсе-берсенә бәйләнгән ике-өч эпизод белән генә бетми, берсенә ялганып икенчесе, өченчесе чыга. Шулай көн кичкә авыша, кайтырга вакыт житә. Без, зур бер эшне тәмамлаган кебек, әкрен генә, сыкрана-сыкрана гына таралабыз. Икенче көнне тагын очрашабыз.

Менә бер елдан соң Громовны, үзенең соравы буенча, яңадан Казанга кайтаралар. Монда ничектер колач та таррак, кешеләре дә башка. Громов шатланып туя алмый, тик чыкмаган кояшына шатланган икән ул. Озакламыйча утыз жиденче еллар башлана. Громовны эшеннән алалар. Ул кем беләндер бергә эшләгән, кемнедер фаш итмәгән, стена газетасында язган мәкаләсендә политик хата . жибәргән... Кыскасы, аны бик каты кисәтәләр, әмма... утыртмыйлар. Берникадәр вакыттан соң аны яңадан элекке эшләгән урынына алалар, ә аннары сугыш башлана.

Бу хәвефле көннәрдә Громов тимер юл складында начальник булып эшли. Меңнәрчә, йөз меңнәрчә кешеләрнең соңгы станцияләре дә рәтләп күрсәтелмәгән багажлары килә, учреждение маллары килә. Боларның бөтенләй адреслары да юк. Күбесен юлда актарып бетергәннәр, урлаганнар. Аларга ниндидер тәртип кебек нәрсә бирер өчен гажәп күп эшләргә кирәк була. Громов өенә дә кайтмый башлый, төнкөн складлар буйлап чаба. Ә фронттан берсеннән-берсе хәтәр хәбәрләр килеп тора. Житмәсә, каядыр еракка билгеләнгән поездларны Казанда туктаталар да, әйберләрен тиз генә бушатып, яңадан фронтка озаталар. Громовның йөзендә әлеге шул зәңгәр күзләре генә утырып кала. Ләкин ул зарланмый, гомумән, ул сүз бөтенләй телдән алына: сугыш! Хәзер инде сугыш дәһшәтенең жимерү көче снарядлар, бомбалар ярылган урыннар белән генә чикләнмәве, иксез-чиксез зур илгә таралуы һәркемгә ачык.

Шулай төнне көнгә, көнне төнгә ялгап эшләп торганда, Громовны район башкарма комитетына кучерәләр, аннары, 1942 елда, шәһәр тимер юлының начальнигы итеп билгелиләр. Я. хода! Шәһәр тимер юлы бөтенләй чыгырыннан чыккан. Кешеләр, бигрәк тә ирләр, бөтенләй диярлек юк. Громов Министрлар Советында да, өлкә комитетында да дөресен әйтеп бирә: шәһәр тимер юлында мин нәрсә белэм, берни булдыра алмам, ди. Министрлар Советында аңа бары тик үйларга кушалар. Ә берничә сәгатьтән аны өлкә комитетына чакыралар. Министрлар Советы кичәсе кичә шәһәр тимер юлының бөтенләй эшләмәвен, трамвайларның берсе дә линиягә чыгарырга ярамавын, соңгы шәһәр тимер юлчыларының армиягә китеп баруларын әйтә дә, менә иптәш Громов, ул эшне рәтләр, дип сүзен бетерә.

Алай-болай булса, каршы әйтергә дип Громов үзенчә сүзләр әзерләп куйган була, ләкин бюрода утырганда барысын да оныта. Күренеп тора ич: хәл чамадан тыш авыр. Министрлар Советы, өлкә комитеты бюросы Громовны шул эшкә куярга калган икән, димәк, башка кеше юк, барлык чаралар беткән. Мондый чакта сөйләп торудан ни мәгънә?

Громов өлкә комитеты бюросыннан туп-туры шәһәр тимер юлы конторасына кайта. Бу вакытта ярты төн күптән узган була. Контора дигәне кечерәк кенә бер бүлмә, буп-буш. Бары тик бер кеше — карт инженер гына өстәлдә бөгәрләнеп йоклый. Громов аны уята да үзенең каян һәм кем булып килгәнлеген әйтә. Икәү уйга калып утыралар. Кайдан башларга, кемне эшкә кушарга? Иртән ике-өч хатын килә, ләкин аларның да нәни балалары бар. Нәкъ шуны сизгәндәй, хатыннарның берсе баласын Громов алдына бастыра да: «Мәнә, иптәш начальник баланы карасын, мин эшкә чыгам», — ди.

Ихтимал, менә шунда Громовның чәче коелып беткәндер һәм ул, шуны кешегә күрсәтмәс өчен, чәчен алдырып йөри башлагандыр. Ул чакта көннәр ничек үткәндер дә, ничек эшкә башлаганнардыр — хәзер беркем дә әйтә алмас инде. Уйласаң, исең китәрлек. Громов өлкә комитетына чаба, кеше сорый, даулый. Ниһаять, аңардан «Ничә кеше?» дип сорыйлар. Громов ничә кеше кирәклеген үзе дә белми, әмма югалып калмый, түшәмнән алып булса да әйтә: 200 кеше!

Уйлаша һәм телефоннан шалтырата торгач, ана 50—60 кеше табып бирәләр. Ләкин нинди кешеләр! Беренче тапкыр шәһәргә килгән, чын трамвайны да гомердә күрмәгән чын авыл кызлары!

Аларны эшкә чыгару, эшкә өйрәтү — язмасаң да билгеле. Торырга урыннары булмагач, алар шул ук конторада йоклыйлар да. Бер запас часть юк, электростанцияләр эшләр-эшләмәс кенә. Шулай да, берәнсәрән генә булса да, трамвайлар юлга чыгалар. Громов аларга ниндидер космик корабльне җибәргән шикелле карап кала. Дөрес, тыштан ул аз гына да шатланмый. Моның кирәге дә юк, ләкин трамвайлар йөри бит!

Беркөнне караңгылы-яктылыда юлга чыгып китәләр. Громов үзе дә чыга, төрле идарәләрдән нәрсә дә алып булмасмы дип уйлый. Ә трамвай аз гына бара да туктый, аз гына бара да туктый. Халык сүгенә, эшкә кичегәбез дип шаулый, ләкин трамвай кузгалуга ишекләргә дә, түбәләргә дә халык ябырыла. Суык, тәрәзәләргә ике бармак калынлыгы боз каткан, күренми, караңгы.

Ниһаять, трамвай бөтенләй туктый. Вожатый, яшь кенә кыз: «Мин нәрсә эшли алам? Әнә начальниктан сорагыз», — дип күз яшьләре белән кычкыра. Громовны тотып алалар. Халык, әһә, гаепле кеше табылды, дип тынып кала. Бер генә минутка тын кала, ә аннары...

Мин инде Громовның кайчан сөйли башлавын күптән оныткан идем. Аны сүзенең иң кызык, дөресрәге, иң драматик җирендә карчыгы алып киткәч, бер мәл ни эшләргә белмичә утырдым. Аннары тынычландым, мин бит әле кич буе, төнлә дә, иртәнге якта да эшнең ни белән беткәнен уйлый алам. Шулай булгач, нигә ашыгырга? Громовның шулай көтмәгәндә китеп баруы бер яктан яхшы да булды әле. Аның киткән чакта: «Нәкъ мең дә бер кичә булды бу», — дип әйткән сүзләренә соңга калып булса да елмайдым.

Ләкин мин үземнең авыру, аның карт булуын бөтенләй истән чыгарганмын. Икенче көнне көне буе диярлек яңгыр яуды, шуңа күрә мин өйдән чыкмадым. Аннары кәефем начарланып китте. Бер атна буе диярлек урында яттым. Билгеле, бу вакыт эчендә мин әллә нәрсәләр уйлап бетердем, Громовны ничек кенә күз алдыма китермәдем. Ләкин, барыннан да бигрәк, сугыш турында уйладым мин. Без сугышны ничектер фронтта гына итеп күз алдына китерергә күнеккән, ә аның менә нинди яклары да бар икән. Яшь-яшь авыл кызының кар чокыйчокый елавы, вожатыйның күз яше аралаш: «Мин нәрсә эшли алам? Әнә начальниктан сорагыз», — дип кычкырып җибәрүләре — болар бит бар да сугыш нәтиҗәләре, шуннан аерып алсаң, һичбер мәгънәләре калмый, аларны аңлап та, аңлатып та булмый.

Бакчага чыккач, бер мәл аны таный алмыйча тордым: яфраклар шактый сирәгәйгән, яшел агачлар инде ышык урыннарда гына; аллеялар, урындыклар — һәммәсе кипкән яфраклар белән капланган, кешеләр дә бакчада аз күренә, булганнары да безнең кебек утырып тормыйлар, тизрәк китү ягын карыйлар. Трамвай тавышлары аермачык булып ишетелә. Карасана, алар ничек күңелле чыжылдыйлар. Мин шул тавышларны тыңлый-тыңлый Громовны көттем. Әйтәм, трамвайларның ничек күңелле чыжылдауларын аңа әйтәм, дип уйладым. Әмма ул килмәде. Икенче, өченче, дүртенче көннәрдә дә күренмәде. Ниһаять, беркөнне аның карчыгын күрдем. Карт авырган икән, аны больницага салганнар, бүген-иртәгә операция булырга тиеш!

Миңа ничектер ямансу булып китте. Уйга чумдым. Бакча буйлап берөзлексез кешеләр узып тора, кайчагында эскәмияләргә дә утыралар, сөйләшәләр яисә болай гына карап торалар. Сугыш турында, аның нәтиҗәләре турында, белсәләр дә, ишеткән булсалар да, хәтта аны күргән, кичергән булсалар да уйламыйлардыр, аларның күңелләре инде башкада. Их, тормыш, тормыш! Кичәгесе сизелмәстәй артка чигә, авырлыклар онытыла, алар булмаган да кебек. Теге трамвай конторасында баласын Громов алдында калдырган хатын кайда икән? Баласы инде күптән егет булгандыр, үзе картайгандыр. Юк, мин аларга авыр сүз әйтергә җыенмыйм. Андый кеше булсам, җир кутәрмәс иде мине. Алар бит сугыш авырлыкларын иңнәрендә күтәреп чыкканнар. Громовны да бары тик яхшы исем белән генә телгә алам. Белмәгәч, кеше турында әллә нәрсә уйлыйсың, белгәч, уйларың үзгәрә икән. Мин кайчакта Громовны батырлар рәтенә дә кертәм, аннары уйлап куям: бу минем эш түгел бит, — бу халык эше, ә халык кирәклесен онытмас! Ә миңа картның хәлен белеп торырга кирәк, бик кирәк.

Бүген җил юк, ә яфраклар барыбер тын гына коелалар. Алар инде бик күп, юлларда да, эскәмияләрдә дә, бөтен җир — бар да сары күбек. Давыл гына чыкмасын, давыл чыкса, алар дөньяны баса, бернәрсә дә күренми...

1966 ел.

Кичә, 1967 елның 14 мартында, Павел Петрович Громовны җирләделәр. Әллә ничек кенә бу тормыш, кешеләр китәләр дә баралар.

15 март 1967 ел.

——□——

# Яз галәмәте



*Фатих Хөсни*

## Хикәя

### I

Яз дигәнең шәһәрне дә үзенчә киендерә, үзенчә хәрәкәткә китерә, тик язга гына хас моңнары белән төрә. Гадәттәге трамвай, автобус шалтыр-шолтырларына бакча-паркларлардагы карт тирәкләргә оялаган кара каргаларның дәртле шау-шулары килеп кушыла, тротуар буйларыннан челтерәп гөрләвекләр ага, яшьләр урамда ялан баш йөри башлыйлар, картлар капка төпләрендәге эскәмияләргә тезелеп, сәгатьләр буена кояшта кызынып утыралар һәм, озак утырып эчләре поша башлагач, нишләргә белмәгәннән, дөньяны, ялан баш йөрүче яшьләрне, малай анасы булганы — киленен, кыз анасы булганы кияүен чәйнәргә керешә. Дөресен генә әйткәндә, алар моны елның башка фасылларында да ярыйсы гына булдыралар, әмма яз көне, үзләренең инде әллә кайчан узган яшь чакларын тирәнтенрәк кичереп искә төшерә башлагач, шул үтеп киткән язларны инде берничек тә, берничек тә кире кайтарып булмаслыкны төшенеп, ул бичараларның бүгенге дөньяга вәсвәсә аша караулары аеруча көчәя. Ә «бүгенге дөнья» исә, мондый капка төбе тәнкыйтьчеләре белән әллә ни исәпләшеп тормастан, үзенчә мәш килүен белә: кешеләр барасы җирләренә баралар, кайтасы җирләреннән кайталар, көләселәре килсә көләләр, елыйсы булсалар, анысы өчен дә оялып тормыйлар, елыйлар да, күзләрен сөртә-сөртә тагын үз юлларына ашыгалар...

Һәм, әлбәттә, яз булгач, мәхәббәте дә поты беләндер инде.

Күпләрдән, бик күпләрдән берсе, әнә Казанка ярында, көймә базасында, бер егет ярга чыгарып салган көймәсен буяп маташа. Әлбәттә, яшь. Әлбәттә, чибәр. Әлбәттә, күңеле дә урыныннан купкан булса кирәк. Юкса соң, кояш күрдем дигәч тә, берьюлы шулай чишенеп ташлармы кеше?! Кояшын кояш та, шулай да кыштан арынып кына киләбез ләбаса! Казанка елгасы боз кабыгын әле тик салып кына аткан, ләкин боздан бөтенләй үк арчылмаган, аннан, әле өстәл чаклы, әле өстәл артында утыручы «дәү абзый»ларның үтәлмәс вәгъдәләре чаклы, зур-зур бозлар аккалап тора, анда-санда тәнне чиратып язгы җил исеп куя, су дымы да бар, шаукымга бирелеп, алай берьюлы

чишенеп ташларга иртәрәк әле, иртәрәк. Шуның өстенә тагын, ул егет әлеге теге капка төбе тәнкыйтьчеләреннән берәрсенең якыны да булып, ул акыллы сакалбай бу тиле җилбәзәкне, әйтик, бер читтән күзәтеп тә торса? Әй, шәп түгел егетнең эшләре читтән карагандa...

Ләкин читтән карагандa гына. Ә үзенә, күрәсең, бик шәп. Салкын тимәгәе дип хәвефләнеп торырга аның вакыты юк. Күр, ничек кызыпкызып эшли. Тирә-юньгә күтәрелеп тә карамый. Башта пиджагын гына салган иде, инде менә күлмәген дә салып, майкадан гына калды. Пумаласын, буяу изгән котелогын җилтерәтеп кенә йөртә. Көймәсенең әле бер ягында. Ул ягын бераз буягач, киптерү эшен кояшка тапшырып, икенче ягына сикереп чыга, икенче ягын буйый башлый. Ә кояшка, чынлап та, эш житәрлек бүген: буялган көймәләрне киптерергә кирәк, яшь-җилкенчәкне котыртып, урамга тартып чыгарырга кирәк һәм шулар өстенә тагын... җирдә яз ясарга, ужымнарны җылытырга, әлегә күкәйдән чыкмаган каз бәбкәләренә куәт-җан өрергә кирәк.

Егетнең атлет фигурасы, читтән, тау башыннанрак карагандa, менә шулай маташыр-маташыр да көймәне «эһ» тә димичә култыгына кыстырып алып китәрдәй күренә: яшь, сыгылмалы, беләк мускуллары кояш яктысында уйнаклапмы-уйнаклый.

Шулай да болары аның читтән карагандa күзгә ташлана торганы гына. Ә бит әле аның, шул тышкы бизәкләре өстенә тагын, күзгә күренми торган эчке дөньясы — күңеле бар. Яз дигәнебез бигрәк тә күңелен иләсләндергән булса кирәк егетнең. Узган ел әнә шушы гадәти генә көймәсендә, «Москва» моторы куелган һәм бортына бик матур хәрефләр белән «Карлыгач» дип язылган шул көймәсендә, су спорты ярышларында катнашып, Татарстан күләмендә призлы урыннарның берсен яулап алган кеше ул. Бу, әлбәттә, алай шаккатарлык дан түгел түгеллеккә. Ләкин шуны онытмыйк, ул бит узган ел булган хәл. Булган да беткән. Ә быел менә... дөрес, моны ул кешегә әйтми, моны ул күңеленә китерергә дә кыймый. Ләкин бу кояшлы язның кешене иләсләндерә торган бер коткысы тагы шул булса кирәк: кешегә әйтү түгел, күңелгә китерергә дә әллә ничегрәк тоелган фетнәле хыялларны да тергезә, аларга канатлар куя.

— Кара әле, җан кисәгем, студент Гыйльманов, — дигән кебек була аңарга әлеге шул тынгы белмәс эчке хыял, — кай җирең кешедән ким синең? Көймәң ярыйсы; моторың «Москва», йөрәгең моторыңа карагандa да ярыйсырак. Шулай булгач... әйтик, көннәрдән беркөнне, шау-шу күтәрмичә генә, чыктың да киттең, көймәңә утырып. Казанкадан Иделгә. Иделдән канал буенча Донга. Аннары Дон аша Азовка. Азовтан Кара диңгезгә. Кара диңгездән Босфор аша Мәрмәр диңгезе буйлап Урта диңгезгә. Аннары Италия, Испания ярларына сәлам биреп, Гибралтар аша выжт — Атлантик океанга. Бу беренче омтылышыңда ук Атлантиканы, бәлкем, кичә дә алмассың, шулай да, парин, күпме ил-җир күрәсең бит... Аннары тәвәккәллегең үзе ни тора! Әйтик, Казан арты егете, татар студенты Әнвәр Гыйльманов, үзенең гадәти генә «Карлыгач»ында өч елга, ике диңгез бугазы, дүрт диңгез аша үтеп, Атлантикадан урап кайтты, ди.

Фетнәле түгел диген син аны, язны! Әнә бит, шушындый чалт аяз көндә кешенең күңеленә нинди коткылар салып тора.

Ә салса соң! Хыялсыз һәм, ай-һай ла, салкын тидермәгәем дип куркып яшәүгә карагандa, канатлы хыяллар белән очынып яшәү хәерлерәк түгелмени? Җитмәсә тагы, язы да шулай күңелне җилкетеп торганда. Моның өчен гаепләп булмый ул Гыйльманов дигән егетне. Ул көймәсе янында ялгыз үзе генә — кем күргән дә аны, кем аның хыялы артыннан куып җиткән!

## II

Ә бактың исә, күреп тора иде аны берәү.

Шул ук Казанка ярында, бераз сулдарак, ярдан бераз күтәрелә төшебрәк, баскыч борылышында, култыксага яртылаш янтая биреп, куе алтын чәчле, нечкә билле, кыска итәкле, бәлки шунлыктандыр, сыйраклары аеруча озын һәм шыр күренә торган, читтән караганда челәнгәрәк охшаган, менә болай су якасында ялгыздан-ялгыз басып торуы белән дә челәнне искә төшерүче бер кыз тукталып калган. Менәргә дә ашыкмый кыз, түбәнгә таба төшеп киткәне дә күренми. Баскан, тора, әледән-әле җил туздырган чәчләрен төзәткәләп куя, башын артка чөеп, әледән-әле зәңгәр күккә карый, шул арада үзе, әллә нидә бер, ялгыш кына күзе төшкәндәй итеп, ярда көймә буяп маташучы егеткә дә карап-карап ала. Юк, без тагы ашыгыч кына әллә ниткән хәтәр уйларга бата күрмик: янәсе, бу кызның ул көймә буяучы егеткә күзе төште түгелме? Яз көне ике яшь арасында андый хәлләр дә, әлбәттә, бик мөмкин. Ләкин, ай-һай ла, шул ук яз коткысы булмасмы алай җиңел уйлау?

Әгәр дә мәгәр без уйлаганча булса, кем тышау салган ул кызның озын сыйракларына. Баскычтан йөгереп төшәр иде дә барып басар иде көймәче егет янына. Ә бит ике аягының берсен дә атламый, төшми, борылып та карамый. Үзара гына әйткәндә, анысы болай борылып караштыргалый инде караштыргалавын, ләкин кемне кем гаеп иткән караган өчен генә. Шул ук вакытта бит ул бөтенләй икенче якка, Караваево, Түбән Ослан, Идел якларына да караштыргалый. Кем белә, бәлки аның, Идел кузгалмадымы икән, дип каравыдыр. Казан өстендә апрель кыздырып торганны истән чыгармыйк. Андый чакта күзе бар кеше кайларга гына карамас икән.

Алайса нишләп соң ул менеп китми? — дигән сорау кылә шундук башка. Менә бусына мин берничек тә җавап таба алмыйм, дусларым. Юкса, кояшы болай бик балкып торса да — кояш бит ул югары. Ә монда Казанка кузгалган чак, боз ага, су җиле тәнне чирата. Кызның өстендә нәрсә булганлыкны күрдек: кыска итәкле юбка да, булган табигый байлыгы белән мактану өчен, тегеннән тарттырып, моннан бөрдереп, кысып куйган тар кофта. Башында нәрсә икәнлекне шулай ук күрдек: көлтәсе белән алтын чәч, ә чәч өстендә җил дә зәңгәр күк. Болай караганда, туңа башларга бик вакыттыр инде ул кызга, югыйсә. Баядан бирле бер урында басып торып, аяклары да талмый микәнни?

Күрәсең, талмый. Күрәсең, кыска юбка, кыланчык кофтасы эченнән кызны җылытып тора торган хыялы кузгалган булса кирәк.

...Әйтик, әнә көймә тирәсендә маташа торган егетне, атлет гәүдәле, җиңел хәрәкәтле, мускуллары һәм куллары уйнаклап торган ул житез егетне кыз — әйтик, бусының исеме Флюра булсын, ди — үзе эшли торган конструкторски бюрога алып китте, ди. Әйтик, алар икесе дә бергә кара-каршы утырып эшли башладылар, ди. Дөньяда юкны түгел, дөньяда булырга тиешлене, дөньяга кирәклене эшлиләр, кыскасы, гадәттә эшләнә торган эшне генә эшлиләр. Әмма бергә утырып эшлиләр, кара-каршы утырып эшлиләр, эш арасында күтәрелеп-күтәрелеп бер-берсенә карашып та алалар һәм, гүяки, шул җитә: гадәттә эшләнә торган шул эштән кинәт гадәти булмаган, күз-колак ишетмәгән, башкаларны таң калдырырдай могҗиза килеп туа...

Алай булырмы, бүтәнчәрәк килеп чыгармы? — анысын ук юрау читен, анысы алар эше һәм киләчәк эше. Ә хәзерге минуттагысы шул: кыз, тылсымланган кебек, бер урында кадакланып калган. Аны су җиле куркытмый. Аны шулай ук егетнең игътибарсызлыгы, бу якка әйләнеп карамавы да куркытмый. Эшли бирсен эшен. Карамаса карамасын бу

якка. Хәтта егетнең карамавы кыз өчен хәерлерәк тә. Үзе бер читтә күренмичә калып, менә шулай егетнең эшчән кулларына, йөгерек мускулларына карап тору кызга әйтеп бетергесез рәхәтлек бирә...

Болай булгач, димәк, ышандырып ук әйтергә мөмкин: кызның егеткә күзе төшкән генә түгел, кыз егеткә башы-аягы белән гашыйк. Әлбәттә, шушы көнне, шушы килүләрендә үк берсен-берсе табышырлар, матур сүзләр әйтешерләр, аңлашырлар, кичен киногa китәрләр, ә иртәгесен... Иртәгесен бергә тора башларлар дип юрамыйк. Мәхәббәт эшен алай ансатка әйләндерүчеләр без юрамасак та чыккалап тора.

Ә менә болай юрарга була: Флюра атлы ул кыз, чынлап күзе төшкән ул егетне инде бервакытта да, бервакытта да күздән югалтмады, ди. Алар табыштылар, таныштылар, йөрделәр, озак йөрдėләр, аңлаштылар, үпкәләшүләр дә булды, тагын килештеләр, бер-берсенә вәгъдәләр бирештеләр һәм, ниһаять... бу яз узып, киләсе язга яки аның киләсесенә, яз булмаса, көз көне — анысы ул хәтле әһәмиятле түгел — аларның зур шау-шулы, тантаналы туйлары булды, ди.

Ә туйдан соң тугызмы, унмы ай узгач, я булмаса бер елдан, я өч елдан соң, әйтик, аларның я берсенә, я икенчесенә охшаган, я булмаса икесенә дә берьюлы охшаган бәләкәй генә, елак кына бер малайлары дөньяга килде, ди... Һәм, әйтик, Флюра атлы ул кыз аны, кайчан да булса дөньяга киләчәк ул адәм баласын, үскәч, нәкъ әнә шул көймә буяучы егет кебек буйчан, җиңел һәм җитез хәрәкәтле, мускуллы һәм көймәле бер егет булуын теләсә? Акыл яки аң белән түгел — болай уйларга әле аңарга иртәрәк һәм болай уйлау өчен әле ул хәзергә кирәгеннән артык тәкәббер дә — ә акыл астында йокымсырап яткан инстинкт белән шулай күз алдына китерсә? Ах алла, монда соң табигать законнарына каршы килә торган ни бар? Шулай булгач, ул кызның, Казанка баскычында, ярты юлда кадакланып калган кыска итәкле ул кызның, ни аска төшмичә, ни өскә менеп китмичә, җилдә чәчләрен туздырып, шулай озак басып торуының серен барыбыз да төшендек бугай инде!

## III

Шул ук вакытта монда, тау башында, Фуксовский бакчасының тәбәнәк коймасына корсагын сала биреп, киң кырыйлы иске эшләпәсе астына ышыкланып, ябалактай тынып калган тагы бер адәм басып тора. Монысын инде тау астында көймәсе тирәсендә мәш килүче атлет егет тамчы да кызыксындырмый. Әллә нидә бер күзе төшә, ләкин ул аңарга игътибар итми, хәтта бөтенләй күрмәгән дә кебек. Тау уртасында, баскычта, култыкса буенда чәчләрен җилдә уйнатып әллә кайчаннан бирле басып торучы кызга, әлбәттә, күзе төшкәли. Күрше-күләне, хатыны-балалары, оныконыкчалары ишетә күрмәсен, хәтта бик төшә күзе. Ләкин нишләмәк кирәк: ул кыз белән бу «мәче башлы ябалак» арасында үтеп һәм җимереп булмаслык стена тора — ул да булса — картлык. Ә картлык нишли ала? Картлык модадан чыккан эшләпәсе астыннан ерактагын аерып җиткерми, якындагын үтә чекрәйтеп күрсәтә торган бозык күзләре белән, анда да «кеше күрмиме икән?» дип курка-курка гына, бары тик карап кына тора ала. Яшен кебек, алны, еракларны ялтыратып күрсәтә торган йөгерек хыял инде юк, «Нәрсә булса — шул!» дип уйламыйча ташланучы тиле тәвәккәллек шулай ук беткән, барысы да чамалы, исәпле калган, бары тик үзеннән-үзе шаулаучы склерозлы баш та, ул башны әнә сәлперәйгән эшләпә каплап тора. Аннары тагын, көя төшеп, чит-читләреннән инде чәрдәкләнә башлаган элекке авторитеты, карт эттәй, артыннан юаш кына ияреп йөри. Шулай да бик-бик кадерен белә ул моның. Көн саен иртә торгач, сел-

кеп, тузанын каккандай итә, «Бүген кая барасым бар дигәнием әле мин?» дип карчыгыннан сорый, барасы җиренә бер минут сонга калмыйча барып житә, белгән-күргән кешеләр белән нәзакәтле генә исәнләшә, хәтта, кәефе яхшырак чакта туры килсә, сәясәткә кагылмыйча гына берәр анекдот та сөйләп ташлый. Инде алай-болай яшьләр турында сүз кузгала-нитә калса, аларны әрләмичә, тәнкыйтьләмичә калмый да калмый.

Кызганычка каршы, менә бүген, ичмасам, шундый мәшәкатьләр дә килеп тумады. Өйдә утырасы килмәде картнын. Өйдә утырып сон кемгә акыл өйрәтеп була да, кем син биргән акыл белән яши? «Казанка кузгалган, диләр... барып, үз күзләрем белән карап кайтыйм әле», дип чыгып китте ул. Чөнки шулай өйрәнелгән, һәр яз саен Казанка бозын үз күзләре белән озатып калмаса, картыбыз никтер ямансылап йөри, үзен кем алдындадыр гаепле сыман тоя иде.

Шундый юк кына сылтау белән чыгып киткән кешенең, кара әле, гөнаһы-шомлыгы түгел диген, әлеге теге баскыч уртасында җилфердәп торучы ялан башлы кызга күзе төште бит чәнчелеп киткере.

— Китте мода, хәер... Кыш китеп өлгерми, башларын салып ташлыйлар, — дип, авыз эченнән мыгырданып куйды ул иң элек. Бу чаклысына үпкә дә юк, кемне булса да тәнкыйтьләмичә, яки кемгә булса да акыл өйрәтмичә соң, бу дөньядагы калдык гомерене ничек үткәреп бетермәк кирәк!

Аннары ул күз бәбәге астыннан җилфердәп басып торучы алтын чәчле «гөнаһы-шомлыгы»ннан тизрәк күзләрен алып, карашын еракларга дан — Казанка артындагы киңлекләрдән, Дербышка, Савиново яклардан «әйләндереп» кайтмакчы булды, ләкин ул яклардан аңарга, агы-карасы бергә кушылып, ниндидер силуэтлар гына чагылып күренә иде.

Ераграк әтрафлардагын күзләре аерып житкерми торган, хыял дигәне инде бөтенләй сүнгән, иртәгә яки бер елдан соң булачак тормыш турында уйлауны юкка баш вату, комнан аркан ишү дип караучы, шул ук вакытта башының бер өлешендә әлегә нәрсәдер кыймылдаучы, бөтенләйгә үк сүнеп бетмәгән бичара картнын күңелгә вәсвәсә салучы теге «тузгалак баш» алдында, шулай да, бер өстенлеге бар: ул бик тәфсилләп, бөтен ваклыкларын күз алдында яңадан тергезеп, жанландырып һәм беркадәр шигъри моңсулыкка төреп, узгандагы хатирәләренә әйләнеп кайта ала иде. Менә бу минутларда да ул, андасанда аккалап торучы Казанка бозларына карый-карый, шул ара үзе, ояла-уңайсызлана булса да, әлеге теге кыска итәкле гөнаһы-шомлыгына да күз салгалап, узгандагылар турында, шулар арасыннан кавышу насыйп булмаган бер мәхәббәтен аеруча күз алдына бастырып, татлы хыялларга чумды.

...Ходавәндә, әнә шул гөнҗәлә баш төсле генә, гомумән, хәзергеләр кебек кенә идеме соң аның ул вакыттагы Рабигасы! Булыр иде шундый вакытлар — сирәк була торган иде, ләкин була торган иде: истә-оста юкта, бернинди бәйрәм түгел бервакытта, киенеп-ясанып, вак кына адымнарын мәрҗән урынына тезеп, сыгылма билен уйнатып, әмма башны тәкәббер рәвештә югары тоткан хәлдә, як-якка каранып һич ваксынмыйча, шул җөмләдән болар тәрәзәсенә дә күз салмыйча, май күбәләге кебек, боларның өй турыларыннан шул Рабига үтеп китәр иде. Хәзерге пеләш башлы абзагыз, Фуксовский бакчасында сәлперәйгән эшләпәсе астында күмелеп калган «мәче башлы ябалак» ул вакытта әле авылда яшь иде һәм урта бармак кебек авыл егете иде. Урта бармак кебек булмаса да, һәрхәлдә, төшеп калганнардан түгел, гармуны кулында, сузып җибәрсә — кешеләрне елата, җыр башласа

тавышы бар, моңы бар иде. Әнә шул егетне, авылда бер гармунчы егетне саташыр чиккә җиткерде бит шул Рабига дигән кыз. Һай, әйтерен генә бармы, әйтеп, аңлатып бетерергә мөмкинме? Кайберәүләр кебек, егет алдына чалкан әйләнеп төшәргә тормыйлар иде ул вакыттагылар.

«Кайберәүләр»не исенә төшергәч, исерткеч хатирәләреннән кинәт айнып киткәндәй булды карт, «ни белән хыялланганымны күреп тормасыннар тагын» дигәндәй, башын селкеп куйды, як-ягына каранды — анарда әле өч сыйфат: узганны сагына белү, бүгенгене тәнкыйтьләү, ничек кирәк алай сакланып калган калдык-постык авторитетын югалтмаска тырышып сагаю сыйфатлары бик-бик көчле иде. Шулаен шулай да, башын күтәреп карауга, кадалып кына китсен лә, күзләре тагы әлеге теге баскычта шаккатып калган «тузгый баш»ка төште бит, хәерсез.

«Ник китми? Ни күреп хәйран калды, гөнаһы-шомлыгы?» дип, вәсвәсәләнеп, сөйләнеп куйды ул үзеннән-үзе. Ә чын дөреслектә бу сорауны ул кызга түгел, үзенә үзе куярга тиеш иде. Кузгалып китә генә алмый бит менә шушы урыннан. Узгандагыларны искә төшерсә төшерә, ә менә «хәзергеләрдән» аерылып китә алмый, юк, китә алмый. Китәргә теләсә дә, тырышса да, китә алмый.

Апрель, 1967 ел.

——□——

*Айдар Хәлим*

## Колмак җыя кызлар...

Өязекәй буйларында туган як гүзәлләре
Бергәләп колмак җыялар, гөр килә үзәннәре.

Кызларымның буй-сынына соклана тал — нечкә бил,
Нечкә бил талларга кунып хискә баткан йомшак җил...

Күзләрендә мәхәббәтнең чакма ташы чаткысы.
Кемнәргә бәхет китерер бу күзләрнең яктысы?

Ургылып аккан толымнар, сез таулар чишмәсеме?
Чишмәләр сафлыгын мактыйм, кызларым, ишетәсезме?

Аяк асты — абага, абага чыгын кага...
Абагаларга сарылып, талгын гына җил ага.

Өязекәй — омтылып ла аккан су-у-у,
Синнән башка күңелем ямансу-у-у...

Туктамый җыегыз колмак, туктама, җыр, туктама!
Колмак булып итәкләргә алкалы бәхет тама...

Өязекәй буе тал-тирәк,
Күңе-е-лең якын иткә-ә-ән яр кирә-әк...

Кызлар күңеле — кыңгырау, җаелә кыңгырау чыңы.
Әй чыңлый, чыңлый кыңгырау, чөнки нәкъ чыңлар чагы.

Туйлар белән гөрләп тора кышларын туган ягым.
Башкортым куя табынга елкысын, ачы балын.

Мин кайтырмын, гүзәлләрем, тауларда күлләр тонгач,
Чут-чут итеп сайрар шулчак йөрәгемдә сандугач:

И җирем, түгәрәк табын, ап-ак шәлеңне ябын,
Ябын да ап-ак шәлеңне, шәмдәлләр булып кабын!

Кабынсын шәмдәлләр булып Өязе үзәннәре,
Яшәсен тауларда үскән Кәркәле [1] гүзәлләре!

...Өязе — елгам буйлары, тугае, үзәннәре...
Бергәләп колмак җыялар туган як гүзәлләре.

## Тальян моңы

Бусагамнан бөтен нәсел-ыруым
Озатканда мине солдатка,
Әйтте анам:
— Җырыңны югалтсаң,
Кайтасың юк, балам, бу якка!

Яшьнәде кодрәтле яшен айкап күз карасын.
Тальяным бир, бир тальяным, анам,
ялгызы калмасын!..

---

[1] Тулы исеме Бәләкәй Кәркәле.

Яулык чите белән яшең сөртеп
Сүзсез калдың басып ак ташка.
Мин утыргач, ярсып кешнәде дә
Киң юлларга чыкты ак кашка.

Тальяным моңыннан
Сискәнде кыялар...
Бала чактан мине аңлый алар!

Яшәп килгән гади хакыйкать бар:
Күкрәп җиргә килгән ир бала
Тугрылыгы, яуда гына түгел,
Тып-тын тауларда да сынала.

Уйнады ла өзелеп һай тальяным...
Артта калды анам, илем, ярым...

Сизенә тальян — нәрсәдер бар!
Зәңгәр җил, анама җыр алып бар!

...Кайгы мине танкодромда тапты.
Кара болыт килеп люкны япты...
«Үл-де... үл-де... үл-де-еү... а-на-аң
үл-де-еү...»

Шуннан белмим, әллә нәрсә булды...
Эскарплар [1] ,таулар, карурманнар,
Блиндажлар, буш гильзалар, полигоннар,
Киң далалар, аһәңле чишмәләр
Күзләремдә куышып әйләнделәр...
— Ялган, һич ышанма, — диде дуслар.
— Ышан, — диеп пышылдады таулар...
Тартышты гәүдә, үләннәрне иеп.
Көл булды кояш, чепләрәмә килеп...

...Соң инде, соң, бәгырем, ялың чайкап,
Тоякларың бәрмә как ташка.
Толпарымның тавышларын ишетәм:
Туган якта кешни ак кашка.
Ана үлсә — илгә кайгы ята.
Бер кайгыга мең шатлыклар бата.

Хәсрәтләрдән ут кабызды кырлар...
Үлми ярлар — чишмә туңмаса.

Тик шулай да, дуслар, кайчак мине
Тальян күтәралмас моң баса...
Җыр югалтсам — җирдә ни кала?
Син — йөрәгем төере, ил-ана...

---

[1] Танкка каршы эшләнә торган махсус корылмалар.

——□——

*Гамил Афзал*

## Кызыл йолдыз

Мин туганда күктә йолдыз туган.
Мин үлгәндә көмеш юл сузып,
Минем йолдыз сүнәр.
Шул чагында
Бер Сәйфетдин туар җир шарында.
Сәйфетдиннең көмеш йолдызы да,
Ул үлгәндә галәм бушлыгында
Зәңгәр балку сызып югалыр...

Шулай диде миңа чегән кызы,
Мин ышанмыйм хәзер ул кызга,
Мин ышанам кызыл йолдызга.

Бәйгеләргә чыксаң,
Мәйдан тотсаң,
Кызыл йолдыз булсын юлдашың.
Кызыл йолдыз булса, ай, юлдашың,
Мең дошманны җиңәр бер башың!

●

Поэзия,
Сиңа багышладым
Изге минутларын гомернең.
Синең белән таңнар каршыладым,
Синең өчен үлеп терелдем.

Шигырь булып туды әманәтем,
Шигырь булып чыкты хәсрәтем,
Матурлыкка — чиксез мәхәббәтем,
Явызлыкка — чиксез нәфрәтем.

## Бер елмаю

Бер елмаю — аяз, якты иртә,
Бер елмаю — күңел аклыгы
Бер елмаю — җәннәт вәгъдә итә,
Бер елмаю — өмет шатлыгы.

Бер елмаю — хәтәр, үткен пычак,
Бер елмаю — йөрәк ялкыны,
Бер елмаю — уты сүнгән учак,
Бер елмаю — котып салкыны.

# Мине картайткан, йөзне саргайткан өч нәрсә

Бер карашым, күз сирпүем алды
Асыл егетләрнең төн йокысын;
Менә хәзер мина торып калды
Елак бала,
исерек ир,
чи утын.

Ай караган серле төннәремдә
Сандугачлар кунды мендәремә;
Хәзер менә йөзгә сары сала
Исерек ир,
чи утын,
елак бала.

Җиләк гомерләрем үтеп бара,
Сирәк кенә калып чәч агара;
Төен генә булып төйнәлде чир:
Чи утын,
елак бала,
исерек ир.

# Борылам да карыйм

Әлмәт урамнары уң якта,
Бигәш басулары сул якта.
Нигә микән, борылам да карыйм,
Борылам да карыйм шул якка.

Таш урамны ташлап кырга чыгам,
Тук башаклар шавы уемда
Күзләрем туйганчы карап торам
Яшел дулкын кебек уҗымга.

Юл буенда зәңгәр гөтен сибеп,
Машинада үтеп барышта,
Саубуллашу кебек сагыш сизеп,
Каерылам да карыйм арышка.

Буразнаны сагынам икән мин лә,
Тургай булып кагынам икәнмен
Болыннарны ташлап киткәнмен мин,
Басуларны ятим иткәнмен.

# Берәү

Гомер буе берәү тауга менә
сантиметрлап,
миллиметрлап,
Үткән юлларына бизәк чигә
мәтәмнәр җырлап,
гимнар җырлап.

Менә, менә, кыяларга сырыла
тырнагы белән,
тешләре белән,

Тар урында сукмакларга сугыла
терсәге белән,
түшләре белән.

Иң биеккә басып, үзен зурлап
күкрәген коча,
күзләрен кыса;
Эһ, дигәнче мүкле ташны тырнап,
упкынга оча,
бушлыкка оча.

ЗАМАНДАШЛАРЫБЫЗ

*Дамир Вәгыйзов*



# БАЛЫКЧЫЛАР

## ЯР БУЕНДА ЧАҢ АВАЗЫ

Балык заводы директоры Александр Николаевич ничәнче тапкырлар инде менә, өстәл артыннан торып, тәрәзә янына килеп басты. Бүлмәдәге утны сүндереп, тагын байтак вакытлар Кама өстен күзәтте. Әле күптән түгел генә анда, күктәге йолдызларны хәтерләтеп, навигациягә әзерлекләрен тикшереп йөрүче теплоходларның утлары җемелди иде. Хәзер аны караңгылык чолгап алган.

Җил көчәйгәннән-көчәя барды. «Алты балл булыр», дип уйлап алды Александр Николаевич. Ә җил дүрт баллдан артты исә, заводның трал тартучы катерларына эшкә чыгарга рөхсәт ителми. Директор, нидер өмет иткәндәй, стенадагы барометр-анероидка чиерткәләде. Аның стрелкасы, үч иткәндәй, һаман «давылга» шуыша иде.

Ишек шакыдылар. Бүлмәгә склад мөдире Пономарев керде. Ул, өстәл янына килеп, бер мәл кулындагы сәгатенә карап торды, аннары тирән сулап куйды:

— Тугыз тулып килә, Александр Николаевич, күпме көтәргә мөмкин? — диде.

— Мин нәрсә эшли алам соң?

— Кайтырга вакыт диюем. Өйдә, үзегез беләсез, хатын, бала-чагалар...

— Ә-ә, син әнә нәрсә турында икән... Әйе, кайт, кайт... Э-э, иптәш Пономарев, бер генә минутка!

Директорның карашы кичә иртә белән үзе юк вакытта инженер калдырган кәгазьгә төште. «Александр Николаевич! Мин киткәндә, сез заводта юк идегез, шуңа күрә сөйләшеп булмады. Сүз тагын Пономарев турында. Өченчекөн кич, үзегезгә мәгълүм булганча, Зотов һәм Никитин звеноларыннан балыкны катерга минем алда кабул итеп алдылар. Шул ук катерда үзем кайттым, мотористлар бер генә балыкны да алмадылар. Ни өчендер, склад мөдире квитанциягә бер центнер урынына сиксән килограмм гына язган. Балыкчылар зарланалар. Ул нәрсәдер хәйләли булса кирәк. Минемчә, аның башбаштаклыгына чик куярга һәм чарасын күрергә кирәк.

Рәкыйп Камалов».

— Зотов белән Никитин звенолары өченчекөн күпме тапшырдылар?

— Ә, менә нәрсә турында икән. — Пономарев, көлгән булып, янадан өстәл янына килеп басты. — Инженер сүзләре инде бу, беләм. Олы башың белән, Александр Нико-

лаевич, аның сүзен сөйләп торуына рәхмәт. Шулай болгата-болгата урынына да менеп утырыр әле. Белеме бар, сүз сөйли белә. Шундыйлар инде йомшак җәеп катыга яткыралар.

— Күпме тапшырдылар дип сорыйм мин синнән?

— Ну, күпме-күпме? Икесенә сиксән килограмм.

— Калган егермесе кайда?

— Төгәл үлчим дигән булып, үзем төпкә утырыйммы әллә?

— Алай икән?! — Директор урыныннан торып ике кулы белән өстәлгә таянды. — Икенче ишетмим андый сүзне. Аңладыңмы?

— Син җикеренмә, Александр Николаевич, үзең дә боз өстендә бит, әз генә аягың тайды исә, фьюйть! — Пономарев кулын селтәп ирен арасыннан әкрен генә сызгырды да чыгып китте.

Александр Николаевич күпме вакытлар ышанып йөргән иде ул кешегә. Аның аркасында Рәкыйпкә ачу саклады. Бәлки склад мөдиренең «ул синең урыныңа омтыла» дигән сүзләре дөрестер дә. Бәлки аны тиздән төшерерләр, аның урынына инженерны куярлар. Пенсиягә чаклы эшлисе килгән иде. Бер урыннан икенче урынга күчеп йөрер вакыты түгел. Яше дә алтмыш ягына авышты. Ә Пономарев ни дигән була бит. «Боз өстендә басып торасың». Үткәннәрне искә ала. Янәсе, аз гына ялгышу булды исә, башка сугачаклар. Ышанычлы кеше, киңәшчесе дип йөри бит шуны.

Александр Николаевич ун елга якын аракы заводында эшләде. Башта эшләр әйбәт барды. Соңга таба түзмәде, бераз капкалый торган булып китте. Тора-бара эш вакытында да аны кәефле күрә башладылар. Ниһаять, директор постыннан алып, дәвалау урынына җибәрделәр. Аннан киткәндә, врачлар аны нык кына кисәттеләр: ихтыяр көчен саклаганда гына дәваланунын нәтиҗәсе була, диделәр. Аның белән кайтучы, Алабуганыкы берәү, пароходка утыру белән, кәеф-сафа кылып җибәрде. Ә Александр Николаевич түзде. Хатыны, оныклары янына ул элеккечә саф йөзле Саша булып кайтты. Әле дә хәтерендә: иң кечкенә онысын кулына күтәргән иде.

— Дәү әти, башка эчмисең, неме? — диде малай.

— Әйе, улым, башка бер тамчы да, — диде аңа Александр Николаевич. Шул чак аның күзләренә яшь килде. Шатлыктан иде ул. Гүя шул минутларда аның алдында икенче бер тормыш үзенең ишеген ачты.

Бу вакыйгадан соң Кама өсте ике тапкыр боз белән капланып, ике тапкыр ташу китте. Икенче ел инде менә ул балык заводында эшли. Производствоны җайга салырга тырыша. Үзе теләп белемле, инициативалы инженер сорап алды.

Яр буенда яңгыраган чаң авазы аның уйларын бүлде. Мондый тревоганы, гадәттә, куркыныч булган чакларда гына бирәләр, ни булды икән? Директор пальтосын киде дә тышка йөгереп чыкты. Караңгыда кемгәдер килеп төртелде, чак кына бәреп екмады.

— Евсеич, син түгелме соң? Нәрсә булды?

— Тоташ боз килә, Александр Николаевич. Кырыйдагы судноларны затонга кертәләр, — диде каравылчы.

— Ә безнекеләр кайда?

— Кайтмадылар бит әле.

Директор соравының урынсыз икәнлегенә шунда ук төшенде. Аларның катерлары кайдадыр югарыда, бәлки, боз араларына кысылып чәлпәрәмә киләләрдер. Александр Николаевич ашыга-ашыга кабинетына борылып керде һәм Казанга идарәгә җибәрү өчен телеграмма тексты язды. Шуннан соң биш минутлар үткәндерме, юктырмы, телефон шалтырады. Инженерның әнисе борчыла иде.

— Микулай, синме бу? Кайтмадымы?

— Үзем дә көтеп торам менә, юк бит, — диде директор, авыр сулап.

— Ниткән хәл була инде ул, Микулай? Хатыны бәбәйгә авырый, ә ире кайдадыр каңгырап йөри.

— Хәле ничек соң? — диде Александр Николаевич, аны бүлеп.

— Начар шул менә. Әле генә үзен скорый пумыч алып китте.

— Һм, — диде директор һәм трубканы куйды.

Берничә сәгатьтән соң тагын телефон шалтырады. Монысы Казаннан иде. Аннан иртәгә иртән үк вертолет җибәрәчәкләрен әйттеләр.

# БЕРЕНЧЕ АДЫМНАР

Яз көненең беренче авына бишәү чыгып киттеләр: һәр ике катерга берәр моторист, ике звено җитәкчесе һәм завод инженеры үзе.

Катерлар агымга каршы бер-бер артлы юл алдылар. Урыны-урыны белән әле боздан арынырга өлгермәгән Кама үзенең болганчык язгы суын яр өстенә сибә. Рәкыйпнең мондый вакытларда элек тә йөзгәне бар. Ул берничә еллар «Урал комсомолы» теплоходында механик ярдәмчесе булып эшләде. Әмма ул вакытта аның күңелендә судан бигрәк машина иде. Ә хәзер ул, күзен дә алмыйча, шушы сихри көчнең төбенә карап бара. Ләкин берни диярлек күрә алмый. Су астыннан ниндидер яшертен давыл бара сыман. Бер урында ул бөрәнкә ясап бөтерелә, икенче урында куыклар чыгара.

Рәкыйп бермәл үзен әнә шушы яшертен давылга әләккәндәй хис итте...

Аны бу заводка производствоны җайга салу өчен җибәрделәр. Ай-һай авыр булып чыкты бу. Җиңелә калса?..

Күз алдына КПССның шәһәр комитетында партия билеты алган көн килеп басты. Ул аны түземсезлек белән көткән иде. Иртәдән үк бәйрәмнәрдә генә кия торган кара костюмын киде, ак нейлон күлмәге өстеннән таррак кына кара галстук такты. Шәһәр комитетының кабул итү бүлмәсенә беренчеләрдән булып килеп утырды. Шулай да аның исемен соңыннан атадылар. Менә ул искиткеч бер дулкынлану белән секретарь бүлмәсенә атлады. Тәбрикләп аның кулын кыстылар. Беравык бөтен дөньясын онытып, басып торды ул, аннары рәхмәт әйтеп чыга башлады.

— Иптәш Камалов,— дип туктатты аны секретарь һәм өстәл янынан урын тәкъдим итте.— Вакытыгыз кысынкы булмаса, миңа эшегезнең ничек баруы турында сөйләгез әле.

Рәкыйп үзе җитәкчелек итә торган участокның эшчәнлеген, андагы әйбәт кешеләр турында бәйнә-бәйнә сөйләп бирде. Җитешсезлекләрне дә яшермәде. Ничә әйтсәң дә, производствода травма алулар беткәне юк, елга бер тапкыр була тора. Рационаллаштыру һәм уйлап табучылык өлкәсендә йөкләмәләр арттырып үтәлә икән, бу әле барысы да эшләнеп бара дигән сүз түгел. Әйтик, кою һәм эш кораллары ясау цехларында байтак кына процессларны механикалаштырып яки автоматлаштырып булыр иде. Шулар турында баш ваталар хәзер ватуын...

— Син Астраханьда азык-төлек предприятиеләре өчен инженерлар хәзерли торган институтта укыйсың бит. Әгәр дә без сине, гараж җиһазлары заводыннан алып, укуыңа якынрак торган тармакка, әйтик, балык заводына эшкә җибәрсәк, ничегрәк карыйсың?

Рәкыйп бу заводта эшләрнең бик начар торуы турында ишеткән иде. Шуңа күрә ул күңеленнән бу тәкъдимгә каршы иде, әлбәттә. Ә уйлаганын әйтергә кыймады.

— Сез кушкач, мин каршы түгел, — диде ул.

Секретарь аның уйларын аңлагандай:

— Син шикләнмә, мөмкин булган кадәр ярдәм итәрбез, — диде. — Дөрес, коллектив таркау, тиргә батып эшләргә кирәк булачак. План үтәлми, балыкчылар әчәргә ярата-лар. Без алар белән чынлап торып шөгыльләнергә тиеш. Ә менә сез, яшь коммунист буларак, башлагыз бу эшне.

— Тырышырмын, — диде Рәкыйп. Ләкин биргән вәгъдәсенең ничек итеп тормышка ашачагын ул башына да китерә алмады.

Бер атна дигәндә ул яңа урында эшне кабул итеп алды. Заводның исеме генә завод иде. Балыкларны каклауны, киптерүне борын замандагы бабайлар ысулы белән эшлиләр. Барысы да кулдан башкарыла.

Йорт тирәләрен әйләнеп, тегесен-монысын карап, вакытны кечкә авыштыргач, ул кабинетына кереп утырды һәм тирән сулап куйды. Нәкъ шул чак ишек ачылды һәм рөхсәтсез-нисез ике кеше килеп керде. Ишек алдында алар бер тапкыр Рәкыйпнең күзенә чалынып алганнар иде инде. Аларның берсенә кырык биш яшьләр, икенчесенә егерме сигез-утыз тирәләре булыр. Керүчеләр өстәл каршына килеп утырдылар. Яше шунда ук сикереп торды һәм, кулын күкрәгенә куеп:

— Виноват, һәр культурный кеше эшне танышудан башларга тиеш. Шулай булгач, рөхсәт итегез, ярышның кире башыннан иң алда баручы Григорий Иванович Тачанов булам. Ә бу — безнен ише кешеләр өчен заводны яшәтеп торучы Пономарев диган

иптәш. Ә монысы... танышу хөрмәтенә. — Ул склад мөдиренә күз кысып алды һәм куен кесәсеннән ярты литрлы шешә чыгарып өстәлгә утыртты. — Э-э-э... Сезне автогараждан, значит, выжт?!

Рәкыйп баштарак берни аңламады. Нәрсә бу? Яңа килгән кешене сынап караумы, әллә чыннан да эштән куылган бәндә дип кызгануларымы? Аның өчен тегесе дә, монысы да кирәкми иде. Ул хәтта аларны якаларыннан тотып җилтерәтеп чыгарырга да уйлаган иде. Ничектер тыелып калды.

— Иптәшләр, мин эчмим һәм сезгә дә эш вакытында аның белән шөгыльләнмәскә киңәш итәм, — диде ул, тыныч кына.

«Инженер безнең кеше түгел, эчми икән, сатуы бар», дигән сүзләр балыкчылар арасында бик тиз таралып өлгерде. Алар арасында салкын мөнәсәбәт урнашты. Ул кая гына бармасын, балыкчылар аңа очрамаска тырышалар, ачылып китеп сөйләшмиләр, сораганга гына җавап биреп канәгатьләнәләр, күп вакыт эш булмаган җирдән эш табып, тиз-тиз шылу ягын карыйлар.

Март аеның беренче көннәрендә Рәкыйп Александр Мигачев звеносына барды. Иртәдән кичкә кадәр балыкчылар белән боз астыннан җәтмә тартышты. Тик ау уңышлы булмады.

— Менә шулай, инженер, кайвакыт үзеңә бер табалык та тота алмый кайтырга туры килә. Боз астында булсалар да, югарыда ни барын сизәләр алар.

Мигачев башы белән ымлап күккә күрсәтте. Ә анда, чыннан да, төньяктан айкалып-айкалып калын болытлар ябырылып килә иде. Озак та үтмәде, күз ачкысыз буран күтәрелде. Балыкчылар җәтмәләрен яңадан салып, яр буендагы землянкаларга юнәлделәр. Рәкыйп бу көнне Мигачев белән икәү бер землянкада кунды.

Звено җитәкчесе мичкә коры-сары өстәде дә юеш киемнәрен салып киртәгә элде һәм кечкенә генә тәрәзә янына куелган агач караватка менеп ятты.

— Күңелсез синең белән, инженер, — диде Мигачев, Рәкыйпкә арты белән борылды. — Менә шулай эшлисең-эшлисең дә тагын шушы зимләнкәгә кайтып ятасың. Ни кызыгы бар? Саласың, билгеле. Ә син менә кабарга да ярамый дисең.

— Һәрнәрсәнең үз вакыты бар, Александр Кузьмич.

— Синеңчә, хәзер менә вакыты түгелмени? — Мигачев урыныннан торды да мич арасындагы кыштәдән ике кружка, бер шешә һәм чиләктән җылынырга да өлгермәгән балык шулпасын алып, фанер ящик өстенә куйды.

— Бер караганда син дөрес әйтәсең, инженер. Һәрнәрсәнең үз вакыты бар. Мин үзем эшләгәндә җен шикелле. Тауларны актарырга әзер. Эшләгәндә эчкән кешене мин дә яратмыйм. Аннан соң, пажалысты. Бабай да, әти дә шулай иде. Безнең, үзең беләсең, бөтен династие балыкчылар бит. Утызынчы еллардан бирле шушында. Вот заманында монда чөгәләр иде! Агым көчле булганда. Беләмсең, нинди кыйммәтле балык ул. Кылчыгы-ние юк, авызда эреп тора. Ә бер тапкырында шундый хәл булды, сөйләсәң ышанмассың, ие-ие. Чыгабыз шулай иртәләрен, Кама өстен болгатыпмы-болгата бер әйбер. Су анасы дип белерсең. Әти әйтә, ак балык, ди. И теге хәзер суя ике тавыкны. Өттерә тегеләрне бик әйбәт иттереп, кармаклар ясый. И чыгып китә бу. Бер көн йөри, ике көн. Өченче көнне хатын белән чыгып карыйбыз — ул да безнең янда иде — этинең көймәсе әле бер якка, әле икенче якка элдерепме-элдертә. И теге күздән югалды бервакыт. Унбиш чакрым сөйрәгән, беләмсең. Соңгысын әти үзе сөйләде. Текә яр турысына җиткәч, тегенең хәле бетте, ди.

Азаплана торгач, алып кайта бу моны заводка. Ә тегендә үз күзләренә үзләре ышанмыйлар икән. Кузьма Кузьмич, бу бит үзе бер айлык задание, диләр икән. Гомумән, ул вакытта да без бөтенесеннән күп тотып килә торганыек.

— Хезмәт Кызыл Байрагы орденын ни өчен бирделәр сиңа, Александр Кузьмич?

Көтелмәгән бу сораудан Мигачев аптырап калды. Ул бер инженерга, бер тәрәзәгә карады.

— Һе, кызык сорау, ни өчен, имеш! Планны арттырып үтәгән өчен. Берәү планын үтәми, ә Мигачев ике норма бирә. Вот нәрсә өчен. И гел шулай.

— Минемчә, аны сиңа биреп ялгышканнар, Александр Кузьмич.

— Ха-ха-ха. Хөкүмәт ялгышкан, ә бу малай ялгышмый. Юк инде, дускай, аны син бирмәдең, так што син аңар сүз тидермә. — Мигачев, кесәсеннән папирос алып, мич каршысына барып утырды.

— Бездә аны һәрьяктан уңган кешегә бирәләр, — дип тыныч кына сүзен дәвам итте Рәкыйп. — Сүз дә юк, син әйбәт эшлисең, рәсемең мактау тактасында. Җыелышта президиумда утырасың. Бөтен кеше үзеңне шәп ди. Борын синең күтәрелә. Янындагы кешеләрне күрмисең. Кемне үзең шикелле шәп балыкчы итеп өйрәткәнең бар?

— Өйрәтү сезнең эш. — Мигачев папиросын ачу белән мичкә бәрде дә караватка килеп ятты. — Шуның өчен акча аласыз. Ә миңа, үзем белеп үзем эш итсәм, житкән.

Бу сөйләшү аларның икесенең дә йөрәкләрен мәче булып тырнады. Икесе дә, озак вакытлар йокыга китә алмыйча, кечкенә тәрәзәдәге аксыллыкка карап яттылар.

Икенче көнне Рәкыйп балык алырга килгән атлы белән кайтырга җыенды. Шул чак аны Мигачев читкә чакырып алды:

— Значит, курка дисең, инженер, ә? Юк, курыкмыйм. Давай, җый үзләрен. Бөтен белгәнемне сөйлим.

Рәкыйп моннан соң звеноларда тагын бер тапкыр булып чыкты, балыкчылар белән уртак тел табарга, аларда ярыш ялкыны уятырга тырышты. Баштарак аның планнарына ничектер көлеп карадылар. Янәсе, бар да сөйләп төкерелгән сүзләр. Тора-бара күпчелеге завод язмышын үз язмышыдай итеп уртага салып, чын күңелдән сөйли башладылар.

Мигачевтан тыш бүтәннәр дә үзләренең эш тәҗрибәләре белән уртаклаштылар, байтак кына тәкъдимнәр әйттеләр. Соңыннан директор кабинетына җыелдылар. Әлегә кадәр шешәдәш булып, бер-беребезгә җил-яңгыр тидермибез дип йөрүчеләр, кызып китеп, әйткәләшеп алдылар.

— Миңа сүз бирегез, җәмәгать, миңа. Бер нәрсә генә искә төште. Онытканчы әйтим диюем.

Җыелышта утыручылар барысы бергә артка борылдылар. Анда бүреген югары күтәреп һәм үзенә сүз бирүне көтеп, катер мотористы Фәезхан басып тора иде. Башка вакытларда да ул үзенең мәзәкләре белән арттагыларны көлдереп утыра, кул күтәрергә кирәк булса, исәп саны булып тора иде. Аның сүз соравы бу көнге җыелышта кайберәүләрне көлдерергә, кайберәүләрне «бу егет тагын нәрсә әйтер икән» дип сагаерга мәҗбүр итте. Сүзләренең ничектер калтырабрак, өзек-өзек чыгуы егетнең каушаганлыгын сиздереп тора.

— Сүз уңаенда гына... Иптәшләр! Эшләмибез бит инде, ничево сөйләп торырга. Менә Гришка Тачановны алыйк. Ие, дус инде ул минем. Бүген сөйләгәнгә бәлки ачуы да килер үзенең. Тәнкыйть файдалы булса да, ярага тоз бит ул, үзегез беләсез.

— Конкретрак, кыскарак тот!

— Ә син, Хәсән, кеше ат дагалаганда, бака булып, ботыңны кыстырып утырма, яме. Син үзең дә шул бер кәндидән су эчүче бит. Менә шул. Көз көне булды бу хәл. Мин болар урнашкан якка балык кабул итәргә киттем. Башта туктадым моның янына. Ну, мәйтәм, Гриша, давай балыгыңны. Күрәсең бит, Фәезхан, норма тулып беткәне юк әле, син инде кайтышлый кер, ди. Кайтышлый туктыйм моның станына. Карыйм, эт тә юк. Кычкырып карыйм, таллыклар эчендә, мәйтәм, ни дә булса эшләп йөрмиме. Юк. Монда озак торып булмый бит инде, үзегез беләсез. Чокырга төяп калдырмадымы икән дип, эчкәрәк керсәм, ни күзем белән күрим, безнең Гриша йоклап ята. Ник бер кило балык бирсен. Күршедәгеләр соңыннан әйттеләр миңа. Тоткан бар балыгын узгынчы пароходтагыларга сатып җибәргән икән ул. Шулай булгач, ниемә аңа план. Көнлек акчасын болай да артыгы белән кесәсенә сала бара.

— Син инде моны шешәдә үзеңә калмаганга ачу итеп сөйлисең.

— Кирәк булса, мин кешенекенә калмаган. И, иптәшләр, нәрсәсе кызыклы: гомерендә план үтәмәгән Гришкада һәрвакыт яңа җәтмә.

— План үтәмәгәч, эшләмәгәч, билгеле инде яңа була, — диде әлегә кадәр сүзсез утырган Пономарев һәм елмаеп директорга карады. Ләкин аның җитди йөзен күреп тынып калды.

— Үзенә дигәндә, бик шәп эшли ул. Просто кешеләрдән яхшы түгел. Зотовлар, әйтик, планны гел үтәп баралар, ә күпме вакыттан бирле инде яңа җәтмә алганнары юк. Кайчан барма, гел ямап утыралар.

— Фәезхан дөрес әйтә, бу мәсьәләне хәл итәргә кирәк.

Фәезхан тавыш килгән якка карап алды да урынына утырды.

Соңыннан Александр Кузьмич Мигачев звеносының социалистик йөкләмәсен һәм

башкаларга мөрәҗәгатен тикшерделәр. Ул байтак кешене чын-чынлап уйланырга мәҗбүр итте. Һәр звенога айга 27 центнер урынына 54 центнер бирү уен эш түгел иде, әлбәттә. Моны Рәкыйп тә, директор да яхшы белделәр. Шулай да авыр хәлдән ничек чыгарга? Беренче квартал планы үтәлми, ярты еллык өчен икеләтә көч куярга кирәк. Шулай булгач, кешеләрнең күтәрелеп киткән инициативасына таянырга һәм аны дөрләтеп торырга гына кала.

Балыкчылар җавап бирергә ашыкмадылар. Әлегрәк бара иде әле ул. Йөкләмәне кайчак сорап, кайчак сорап та тормый язып куялар. Кайдадыр ул саргаеп бетә, аның турында уйлаучы да булмый. Ә бу юлы атна саен тикшереп торачакбыз һәм план үтәлешен сораган кебек сораячакбыз диләр. Балыкчылар чыгып-чыгып тартып керделәр, бер-бере белән бәхәсләшеп алдылар. Беравыктан тынлык урнашты. Мөгаен, берсенең дә башлап сөйләргә батырчылыгы җитми иде бугай.

— Ягез, иптәшләр, болай утырсак, ярты төнне җиткерүебез бар, — диде директор, урыныннан торып. Ул, кемнән башларга дигән сымак, залдагылар өстеннән күз йөртеп чыкты. Карашын президиум өстәле белән янәшә утырган ябык чырайлы кырык биш-илле яшьләр тирәсендәге ир кешегә туктатты. — Иптәш Зотов, сез ничегрәк уйлыйсыз?

Зотов теләр-теләмәс кенә урыныннан торды. Җилдән яргаланып беткән озын бармаклары белән бүрек бавын бөтерде, ә аннары бер кулы белән төрле якка тырпайган ак чәчләрен сыйпап алды.

— Ничек уйлыйм дип, кеше уйлаганны инде, Александр Николаевич. Раз кирәк икән, язгыз минекен дә шулай иттереп. Болай аңардан күпкә калышмый торган идек. Тулькe, теге егет әйтмешли, яр башында җәтмә ямап вакыт үткәрерлек булмасын иде инде.

Зотовтан соң башкалар күтәрелделәр. Һәркайсы мөмкин булган кадәр тырышырга, коллектив шулай хәл итә икән, без каршы түгел, дип йөкләмәгә кул куярга булдылар. Бары тик Хәсән белән Гриша гына «кеше теләсә нишләсен, ә без икегә ярыла алмыйбыз» дип читтә калдылар.

Икенче көнне Рәкыйп завод складындагы товарларны карарга булды. Пономарев аны йөзен чытып каршылады. Әлегә кадәр завод җитәкчеләреннән берәүнең дә складтагы әйберләрне үзе килеп тикшереп йөргәне юк иде. Кемгә дә булса теге яки бу нәрсә кирәк икән, директор чакыртып ала да аңардан сорый иде. Ә Пономарев кирәк тапса, җибәрә, кирәкми икән, «юк» дип җавап бирә. Шуңа күрә кайбер балыкчылар, җитәкчеләргә мөрәҗәгать итеп тормыйча, турыдан-туры мөдир янына йөрүчән булып киттеләр. Боларның барысын да Рәкыйп яки ишетеп, яки күңеле белән сизенеп белә иде. Күп вакытын балыкчылар белән уздырганлыктан, аңа әле моңа кадәр Пономарев белән якыннан эш итәргә туры да килмәде. Мөдир тегене-моны хәл итәргә булса, һәрвакыт директор янына йөгерә, беренче көнне очрашудан соң, гүя ул инженерны бөтенләй күрмәмешкә салыша иде.

— Ревизияме бу? — Пономарев ишекне ача-ача Рәкыйпкә карап кинаяле елмаеп куйды.

— Ревизия түгел, шулай да кайбер нәрсәләрне карарга кирәк, — диде Рәкыйп аңа каршы.

Складта барысы да тәртип белән киштәләргә өеп куелган иде. Рәкыйп алгарак атлады һәм карана торгач, нәкъ үзен кызыксындырган нәрсәләрне күрде.

— Остаток буенча бу өч катлар — яңалары — ничәү булырга тиеш сездә? — Рәкыйп ашыкмыйча гына җәтмәләрнең искеләрен бер якка, яңаларын икенче якка аерып куйды. — Бирелә унсигез.

— Нишләп алай гына булсын. Калган сигезен кая куясың?

— Ну бит алары иске, күрәсең, җепләре ашалып, мыекланып беткән.

— Монда яңгыр үтә, күбрәк торсаң, җәтмә түгел, үзең дә мыекланырсың.

Кич белән, өй тәрәзәләрендә утлар күренә башлагач, склад мөдире, завод атына утырып, Кама яры буйлап Хәсән белән Гриша яши торган авылга китеп барды.

— Чабуына ут капкандай ашыга, атны харап итмәгәе, — диде каравылчы, проходнойдан чыгып килүче Рәкыйпне туктатып, һәм кулы белән күздән югалып баручы Пономаревка күрсәтте.

Язны бик иртә вәгъдә иткәннәр иде. Күпне күргән карт-корылар да апрельнең унбишләре-егермеләре тирәләрендә Кама ачылып, пароходлар йөри башлар дип көттеләр. Тик кешеләр уйлаганча булмады. Чистайның калкурак урамнарыннан карлар эреп агып бетте, кырлар чуарланды. Инде менә чем-кара җир чыга дигәндә, тагын тундырып җибәрде. Китә башлаган бозлар, бер урында бикләнеп, тагын күпмегәдер тынычланып калдылар.

Бөтенесе дә җайга салынып барганда, тагын план өзелү куркынычы килеп басты. Рәкыйп, Александр Николаевич белән, тиз йөрешле катерга утырып, түбәнгә барып карады, ләкин күп тә үтәргә өлгермәделәр, боз тыгылган урынга очрадылар. Борылып югары менделәр — анда да унбиш чакрымнан ары уза алмадылар. Ачыклык, үч иткәндәй, нәкъ балыкчылар булмаган урында — урталыкта иде. Ә боз өстенә керәп җәтмә салу турында уйларга да мөмкин түгел, ярылып, чәрдәкләнеп беткән.

— Көтәргә генә кала, — диде директор. — Башка чара юк.

— Әгәр дә тралдан файдалансак?

— Кайда?

— Югарыга менәбез, ачык урынга кадәр.

— Ә аннары боз кузгалып китә дә катерларың, тралларың белән бергә бөтереп ыргыта. Юк инде, җилкәмдә башым бер генә. Планга караганда кеше җаны кыйммәтрәк. Аннан соң кем хәзер трал белән балык тота? Килер вакыты, тотарбыз.

— Безнең катерларның тизлеге сәгатенә алты километрмы? Алты. Ә боз нинди тизлек белән ага?

— Менә анысын әйтә алмыйм.

— Шулай да, Александр Николаевич, сынап карарга кирәк.

— Белмим, белмим. — Директор, ни әйтергә белмичә, аптыраудан ике кулы белән башын тотты. Беравык шулай сүзсез торганнан соң: — Белмим, әгәр дә инде уңышлы чыгасына ышанып үз өстеңә алсаң гына, — дип өстәде.

...Менә алар хәлиткеч юлга чыгып киттеләр. Заводның даны, Рәкыйпнең шәһәр комитеты секретаре алдында биргән вәгъдәсе мондагы кешеләрнең тырышлыгына, аларның тапкырлыгына һәм кыюлыгына бәйле. Ул үзе белән янәшә басып папирос тартып баручы Хәсәнгә карады. Ул да аның шикелле үк яшь, таза. Тик аңарга караганда карарак, ничектер кыя ташын хәтерләтебрәк тора. Кызык: Хәсән ни уйлап бара икән? Мөгаен, эшнең уңышлы чыгачагына ышанмыйдыр. Чакыргач, «рас кушасыз икән, барам инде» дип кенә ризалык бирде бит ул. Күрәсең, һәрнәрсәгә ышанмыйча карагангадыр, эше дә бит аның башкаларныкына караганда сүлпән бара. Җае чыккан урында файда күреп калырга тырыша. Ничек тә булса өмет тудырасы иде аңарда. Ләкин ничек? Әнә рубка эчендә Мигачев белән Фәезхан көлә-көлә ни турындадыр сөйләшәләр. Мигачевы олы кеше, күпне күргән. Ә Фәезхан әле икенче елын гына эшли. Шулай да ярсу күңелле булса кирәк. Җыелышта тикмәгә генә чыгып сөйләмәгәндер. Барысы да аның кебек булса, эшләве җиңелрәк булыр иде. Балыкчыларда ничегрәк заводка мәхәббәт тудырырга? Монысы инде җитәкче кешенең эше. Ул берсенә болай, икенчесенә икенче төрле якын килә белергә тиеш. Ә Рәкыйптә андый сәләт юк, ахрысы.

## БОЗЛАР АРАСЫНДА

— Инженер!

Рәкыйп, уйларыннан бүленеп, рубкага карады.

— Килеп җиттек бит. — Мигачев кулы белән алга күрсәтте. Анда кичә генә Рәкыйп карап кайткан шыксыз боз өемнәре тора иде.

— Башладык, Александр Кузьмич, шушы урыннан.

Катер, йөрешен әкренәйтеп, агым уңаена борылды. Һәм арттан килүче икенче катерны янәшәсенә үткәрде. Рулевой-моторчылардан кала барысы да рубка артына чыгып бастылар һәм Мигачевның әмерен көтә башладылар. Ул трал өстендәге брезентны алып ыргытты да Рәкыйп белән Хәсәнне борт буйлап үз артына бастырды. Тралның икенче башын таккан катерга аерылырга кушып, кулы белән ымлады.

— Хәерле сәгатьтә, инженер! Башладык!

Өр-яңа капрон тралның җете ак калкавычлары болганчык су өстендә әзрәк күре-

неп барырга да өлгермәделәр, күздән югалдылар. Катерлар агым уңаена салмак кына йөзеп киттеләр.

Балыкчының йөрәген бимазалаган минутларның үтүе бик озак тоелды. Берәү дә сөйләшмәде. Һәркемнең күңелен булырмы-булмасмы? дигән сорау борчый иде. Ниһаять, Мигачевның рупордан икенче катер рулевоена кычкырган тавышы яңгырады:

— Якынай, давай!

Катерлар якынайдылар. Балыкчылар сүс арканны тигез ритм белән тарта башладылар. Тәҗрибәле балыкчы, гадәттә, арканга орыну белән җәтмәдә балык булуны чамалый. Ә Мигачев бер сүз дә дәшмичә һаман аркан буйлап кулларын шудыра иде. Рәкыйп бер аңарга, бер судан чыгып килүче трал канатларына карады. Ләкин күңел куандырырлык берни дә булмады. Бары тик саңаклары белән кереп кысылган алабугалар гына, җәтмәдән төшәргә маташып, койрыклары белән бәргәләнәләр иде. Димәк, инженерның бу мәшәкате дә барып чыкмады. Шул вакыт Александр Кузьмич үз артына басып трал канатын тартучыларны койрыкка чакырып алды.

Рәкыйптән алда Мигачев янына барып җиткән Хәсән кинәттән генә кычкырып җибәрде:

— Ура, дуслар! Болай булгач, яшибез!

— Әкрен, тилебәрән орлыгы ашаган нәрсә, балыкларны куркытасың. — Александр Кузьмич елмаеп Хәсәнгә карады.

— Килегез якынрак, күтәрергә кирәк. Только көч җитәрме икән? Ягез әле! Һоп-па!

Көч җитмәгәнне күреп, рубкадан Фәезхан йөгереп чыкты. Әмма тралдагы балыкны дәртәү дә күтәрерлек түгел иде. Арадан берсе катерга күтәртү краны куйдырмый торулары өчен кемнедер тиргәп алды. Шуннан соң икенче катерны беренчесе янына китереп бәйләделәр дә бишәүләшеп күтәрә башладылар.

Беренче сөзүдән үк заводтан алып килгән ящиклар балык белән тула язды. Балыкчылар тагын элеккеге урынга, югарыга менделәр. Һәм тагын трал салдылар. Монысы да баштагысы кебек уңышлы чыкты. Хәзер балыкларны кая бушатырга дигән сорау борчый башлады. Ә кайту турында берәүнең дә сүз кузгатасы килмәде. Алар читенә таллар үскән кечкенә генә бер утрау янында торалар иде. Уйлаша торгач, балыкларны шунда бушатып торырга булдылар. Тотылсын гына, корыдагы балыкны иртәгә дә ташырга мөмкин. Бозылу куркынычы юк, боз-кар белән күмәсең дә, эше бетте.

Алар бу көнне төшке ашны да ашап тормаска булдылар. Ару-талуны оныттылар, эшләгәннән эшлиселәре килеп торды. Ә балыклар «безнең монда бетәсебез юк» дигәндәй һаман керәләр, һаман керәләр иде.

Көне җылытып җибәргәндәй булды. Озак та үтмәде, көньяктан исеп торган җил күгелҗем болытларны куып китерде һәм яңгыр ява башлады. Тирә-юньне караңгылык чолгап алды. Җил көчәйгәннән-көчәя барды.

Александр Кузьмич брезент плащының җиңе белән маңгаена чыккан тир бөртекләрен сөртте һәм катердагыларга сораулы караш ташлады:

— Нишлибез, егетләр?

— Капкан саен майлы калҗа эләкмәс, тотылганда тотарга кирәк, — диючеләр дә булды.

Гомердә булмаган хәл.

Ә яшьләр директорны хәтта тыңларга да теләмәделәр:

— Башка вакытта моның өчен айлар буе йөрисең. Бүген күреп торасың ич...

Калкавычлар, тондыргычлар койрыкка төшәлгән такта идәнгә бәрелеп, шыбырдаша-шыбырдаша, тагын су эченә кереп югалдылар. Шуннан соң биш минут үткәндерме-юктырмы, койрыкка басып торган Рәкыйпның күзләре зураеп, йөзе агарып китте. Шул ук секундта ул рубкага ташланды.

— Тукта! Бозлар кузгалды.

Җылынырга дип, әле яңа гына трюмга төшеп киткән Александр Кузьмич белән Хәсән яшен тизлеге белән палубага күтәрелделәр. Рупордан тагын ярдәмче катерга җибәрелгән команда яңгырады.

— Якынай! Тизрәк! Тизрәк!

Рәкыйп, Александр Кузьмич һәм Хәсән тиз арада койрыкка йөгереп килделәр һәм тралны судан сөйри башладылар.

Бер-берена бәрелә-сугыла судноләр өстенә бозлар киләләр. Менә күп тә үтмәячәк,

алар катерларга килеп төртеләчәкләр һәм, урталарына кысып, үз ихтыярлары белән аларны кая да булса илтеп ыргытачаклар, яки йөзтүбән каплап, Кама төбенә җибәрәчәкләр. Фәезхан прожектор уты белән тирә-юньне әледән-әле капшап торды. Хәзер артка чигенергә мөмкин түгел. Як-яктан бозлар ага. Эш белән мавыккан балыкчылар аны сизми калганнар. Фәезхан прожекторны артка борды. Артта да тоташтан боз ага. Алар калган аралык һаман йомылганнан-йомыла бара. Күп уйларга вакыт юк. Ни дә булса хәл кылырга кирәк. Ул башын рубкадан тыгып, икенче катердагыларга кычкырды.

— Минем арттан!

Рулевойлар катерларны тиз генә суга бордылар һәм кара тасма булып күренгән су өсте буйлап бар көчкә агымга каршы юнәлделәр. Каршыдан килүче бозларның ваграклары бортка шатыр-шотыр бәрелеп үттеләр. Фәезхан, йөрешне бераз әкренәйтеп, инженер белән Мигачевка карады. Рәкыйп ярты гәүдәсе трюмнан чыгарган килеш салкыннан калтырана-калтырана ачык ишектән Кама өстен күзәтә иде. Ә Мигачев кулындагы озын колга белән бозларны төртергә хәзерләнеп бара. Аларның берсе дә бу бәладән чыгу юлын тәгаен генә белми иде.

— Фәезхан, син ничек уйлыйсың, ни өчен монда аралык бар? — диде Рәкыйп күзләрен алга төбәгән хәлдә. — Әгәр шушыннан алга таба үтсәк, ярга чыгып булмасмы?

Фәезхан йөрешне бераз тизләтә төшеп, прожектор уты астында катерны кара тасма буйлап тагын алга алып китте. Алардан өч метрлар гына артка калып икенче катер барды. Бераз юл үткәч, аралык тагын да киңәя төште. Ләкин күп тә бармадылар, каршыда тагын зур гына бер боз пәйда булды. Фәезханнан кала барысы да борынга ташландылар. Ул якынайганнан-якыная иде. Рәкыйп кулын күтәреп, тизлекне әкренәйтергә кушты. Алар, аптырашып, каршы килүче бозга карап тордылар. Әмма һич тә төшенә алмадылар. Ул бер караганда зураеп күренде, икенче караганда кечерәйгән сымак булды. Бераздан прожектор уты яктысында таллар күренә башлады.

— Безнең утрау бит бу, туганнар! — Шушы вакытка кадәр сүзсез барган Хәсән Рәкыйпнең биленнән кысып күтәрде дә берничә тапкыр әйләндереп, урынына бастырды. — Болай булгач, котылдык!

Бөтенләй үк истән чыккан утрауның каршыда җәелеп ятуы кешеләрнең йөзләрендә әйтеп бетергесез шатлык балкытты. Упкынга очканда җир үзенең ярдәм кулын сузгандай булды.

Катерларны бозлардан ышыграк урында ком өстенә утырткач, трюмдагы мичкә ягып җибәрделәр. Балык шулпасы пешкәч, күңелләр тагын да күтәрелебрәк китте.

Төнне чиратлашып йокларга булдылар. Беренчеләрдән булып утрауга Александр Кузьмич, Фәезхан, катер мотористының ярдәмчесе Бойко төштеләр. Хәсән белән Рәкыйп трюмдагы кечкенә генә каютада йокларга калдылар. Ләкин күз йомып никадәр генә ятсалар да, аларны йокы алмады. Хәсән әле бер якка, әле икенче якка әйләнеп ятты. Аннары күзләрен тутырып ачып инженерга карады.

— Рәкыйп Ризваныч, син йоклыйсыңмы әллә?

— Юк, — диде Рәкыйп. — Әнә, суның чопылт-чопылт итеп катерны кыйнавын тыңлап ятам. Нинди көч аңарда ә, Хәсән?

— Бездә дә көч юк түгел бит, Рәкыйп Ризваныч. Всю же без җиңдек бит. Монда чыгар алдыннан миңа Пономарев әйтә: «син нәрсә, барырга уйладыңмы әллә», ди. «Йөрмә, тиле», ди. «Синең башыңа ат типмәгән бит, бер дә юкка боз арасына керергә. Инженерга нәрсә аңа, ул дан алыр өчен йөри. Ә сиңа акча кирәк. План тутырам дип эшләп кенә акча табылмый», ди. Мин әйтәм, всю же барып кайтыйм әле, хәзергә болай да, тегеләй дә акча эшләп булмый. Анда барганнан аягым калмас, мәйтәм. Мине куркаклыкта гаепләмәсеннәр. Килдем дә бит менә хурга калмадык әле.

— Шулай да Пономарев белән әшнәләр инде сез, Хәсән. Тачанов та шулай ук.

— Әшнәләр?! — Хәсән беравык нидер уйлап дәшмичә торды. — Мин аны элегрәк яхшы кеше дип белә идем. Ничектер гел положениега кергән кебек. Синең өчен тегесен-монысын эшләгән була. Үз булып, синең белән салып утыра. Ә ул гел үзе өчен икән. Сөйләгән саен сүз дигәндәй, бер көн бу төнлә ат белән безгә килеп төште. Нигәдер каушаган, битендә борчак-борчак тир бөртекләре. «Гришканы тиз генә чакыр әле, ди». Чакырдым. Бу сразы безгә берәр кырлы стаканга тутырып акны салып бирә. Шуннан соң бераз торгач сөйли бу. «Мин сезгә теге вакытта берәр җәтмә биргән идем

бит. Сез аны өчәрне алдык дип әйтерсез инде, югыйсә, минем күп кенә җәтмәләр җитешми, урлаган булсалар кирәк», — ди. Ярар, без әйтәбез. Ә соңыннан Гришка белән уйлыйбыз. Браконьерларга җибәргән икән бу җәтмәләрне, дибез.

Бүген хет беркадәр җәфа да чиктек. Шулай да ничектер җанга рәхәтрәк булып китте әле. Всю же кеше уйлаганча, буш кул белән кайтмыйсың. Кайбер вакытларда шулай шәһәрдә йөрисең. Белгән кешеләр очрый. Көлә башлыйлар. «Балыкчының штаны юеш, тамагы ач. Кая балыгыгыз, сез анда завод исеме күтәреп нәрсә генә эшләп ятасыз», диләр. Ачу килә. Ашыйсың килсә, үзең тот дип китеп барасың. Просто кайчак йөрәк әрни. Ә аннары синең йөрәк әрнеп кенә нәрсә эшли аласың дип уйлыйсың да төкерәсең барысына, үз җаеңны карыйсың. Папирос бармы синең, Рәкыйп Ризваныч?

Рәкыйп йон одеал астыннан кулын чыгарып тумбочкадан «Беломор» пачкасы белән бер кап шырпы алып бирде.

— Шырпы бар минем, рәхмәт.

— Кая, булмаса мин дә тартыйм әле.— Алар икесе дә терсәкләренә таянып дәшми-тынмый гына көйрәтә башладылар. — Да, Хәсән, безнең турыда халык дөрес әйтә, — диде Рәкыйп беравык шулай ятканнан соң. — Завод кешеләрне канәгатьләндерерлек эшләми әле. Менә әйт әле син, аның киләчәгенә ышанасыңмы?

Хәсән бармагы белән чиертеп папирос көлен идәнгә төшерде.

— Ышанасыңмы дип, кем белә инде аны. Әйтик, бүгенге кебек бөтенесе дә тырышып эшләсә, ышанырга да була. Ә инде... — ул сүзен әйтеп бетермичә уйга калды.

— Мин әле шушы көннәрдә генә балыкларны каклату һәм киптерү участокларын реконструкцияләү турында баш ватып утырам, — диде Рәкыйп. Ул тәмәке төтенен тирән итеп суырды да, беркадәр вакыт эчендә тотканнан соң, киредән чыгарды. — Исәп-хисапларны Казанга идарәгә җибәрдем. Кабул итәрләрме, юкмы. Әгәр кире какмасалар, менә дигән булачак. Механизация. Сыйфат яхшырачак. Әлбәттә, балык булмый торып, син анда әллә нәрсәләр эшлә, барыбер файдасыз. Иң элек тотуны җайга салырга кирәк. Син дөрес әйтәсең. Моңа барысы да тырышса гына ирешеп була. Тачанов менә тырышырмы киләчәктә, син ничек уйлыйсың?

— Тачановмы? Кем белә бит инде аны.

Алар арасындагы сөйләшү шушы төгәл булмаган җавап белән өзелде. Озак та үтмәде, Хәсән йокыга китте. Ә Рәкыйп өен, хатынын күз алдына китерде. Тәскирәсе хәзер нишли икән, йоклыймы, әллә һаман аны тиргиме? Эше бетеп тә өйгә кайтмый йөри диме икән? Белми ул эшнең монда сәгатьсез икәнен. Аның исенә кылт итеп хатынының өченче көн әйткән сүзләре килеп төште. «Сизәсеңме, тиздән өчәү булачакбыз, әнә ничек итеп тибә», диде. Бәлки бүген дә ул дөньяга тумаган баланың тибүеннән рәхәт табып ята торгандыр.

Төнге берләр тирәсендә аларны Фәезхан кереп уятты.

— Су күтәрелә, Рәкыйп Ризваныч.

Алар өсләренә сырмаларын салып палубага күтәрелделәр. Кичтән комга утыртылган катерлар бишек сымак чайкалып торалар иде. Яңгыр туктаган. Кама тулып боз ага. Аларның кайберләре суднолар янында туктап, бөрөзлексез әйләнеп торалар. Рәкыйп белән Хәсән трап буйлап түбәнгә төштеләр һәм ашыга-ашыга утраудагылар янына килделәр.

— Нәрсә? — диде Рәкыйп.

— Күрәсең... — Александр Кузьмич балык өеменә җитәргә ике метрлар калган суга күрсәтте. — Тиздән юып алып китүе бар.

Рәкыйп та, Хәсән дә, башкача сүз катып тормыйча, балыкларны ящикларга төяп, югарырак урынга күчерә башладылар. Тотканда балыкның күплеге беркадәр сизелсә дә, ташыгандагы кебек үк булмагандыр. Ярты сәгать эчендә алар тирләп-пешеп чыктылар. Арып, өем янына тәмәке тартырга утырдылар.

— Дуслар, минем башка бер уй килде әле, — диде Рәкыйп һәм кайсы боз өстенә, кайсы ящик өстенә утырган балыкчыларга карады. — Әйдәгез, Тачановны да читтә калдырмыйк. Аның кайгысы зур бу көннәрдә. Ә без аны үзебез белән эшли дип исәплик. Мин барыбер тоткан исәптән алмыйм бит, ә аңа өлеш язарбыз. Формаль яктан караганда ул бик үк дөрес түгел, әгәр сез каршы килмисез икән, мин аны үз өстемә алам.

— Пажалысты, Рәкыйп Ризванович, кем каршы килсен.

Бары Хәсән генә бер сүз эндәшмичә урыныннан торды. Ул, аяк астыннан чуерташ алып, ачу белән, агып баручы бозлар арасына ыргытты һәм трап буйлап югары күтәрелә башлады.

— Әй, Хәсән! Син нәрсә? Керпегә утырган кешедәй сикереп тордың да китеп бардың? Каршымы әллә? — дип кычкырып калдылар аның артыннан.

— Каршы түгел, нигә? Кешесенә күрә ярый. — Ул борчылмыйча гына шул сүзләрне әйтте дә катер эченә кереп күздән югалды.

Таң алдыннан күк йөзе ачылып китте. Озак та үтмәде, кояш күтәрелде һәм үзенең алтын нурлары белән тирә-юньне коендырды.

Александр Кузьмич кайчандыр кисеп ыргытылган өянке төбенә менеп, әледәнәле Каманы күзәтте. Ләкин менгән саен өметсезлеккә бирелеп, түбән төште. Бозлар үч иткәндәй агалар да агалар иде.

— Көнне бик кыздырып җибәрсә, кичкә таба утрауны су басмагае әле, — диде Александр Кузьмич. Һәм ящикны күчереп, өянке төбенә сөялеп утырды.

Рәкыйп белән Фәезхан иртәнге ашка балык чистартырга дип катердан пычаклар алып чыкканда, үзләренә таба очып килүче вертолетны күрделәр. Менә ул утрау турысына җитте дә туктап бер урында пырылдый башлады. Балыкчылар урыннарыннан торып, кычкыра-кычкыра бүрекләрен селтәргә керештеләр. Ни булганын аңламыйча, тавышка Хәсән дә йөгереп чыкты.

— Әй, Хәсән, нәрсә йоклап ятасың? Сине алырга килгән.

— Тот капчыгың, килгән, — ул ышанырга да, ышанмаска да белмичә елмаеп җибәрде. Чыннан да вертолет баш очында бер әйләнеп алды да, җиле белән талларны сыгып, утрауга төшә башлады. Балыкчылар ышанмыйча бер-берләренә карашып алдылар. Вертолет төшеп, беравык канатларын җилпетеп торганнан соң, башына ниндидер шар сыман ак нәрсә кигән очучы кабина тәрәзәсеннән яртылаш гәүдәсен чыгарды.

— Бар да исәннәрме?

— Исәннәр, — диде аңа каршы берничә тавыш.

Шуның артыннан ук борчылудан аз гына чырае киткән директор вертолеттан төште.

— Әйттем мин сиңа, — диде директор, Рәкыйпкә кулын суза-суза. — Ярый әле ахыры яхшы бетте. Ярый, ярый, тәбрик итәм үзеңне.

— Ә нигә мине?

— Кызың бар, тиле!

— Кызым?!

— Әйе, хәзер мин монда калам, ә син вертолет белән кайтырсың. Көтәләр анда сине.

— Ә кешеләр, катерлар?

— Һе, монда сезгә генә күренми ул, югарыдан караган идек, Кама өсте, ерак та түгел, ачылып килә. Бераздан катерлар белән кайтырга мөмкин булачак.

Вертолетка балык төяп бетәр алдыннан Рәкыйп янына Хәсән килде һәм аңа солдат хаты сымак өчпочмаклап бөкләнгән бер пакет бирде.

— Рәкыйп Ризваныч, әгәр дә күрсәң, шушы язуны Гришкага тапшыр әле, ярыймы? Мин әле кичсез кайта алмам. Укый торсын.

Вертолеттан төшү белән яр буена җыелган халык арасыннан Рәкыйп Гришаны эзләде. Ул аның монда булуына ышанмаган да иде. Иң якын кешесен җирләп йөргән Гриша ничек килә алсын ди. Ләкин ул монда, балык кабул итеп алырга килгән Пономарев белән янәшә басып тора иде. Рәкыйп үз күзләренә үзе ышанмыйча аның янына килде һәм:

— Син ничек монда? — дип сорады. Аннары кесәсендәге хатны алып бирде.— Мә, Хәсән нидер язган.

Рәкыйп вертолет яныннан берничә адым гына атлаган иде, чалтыратып яңакка суккан тавышны һәм Пономаревның кычкырганын ишетеп, туктап калды.

— Рәкыйп Ризванович, шаһит бул, әнә, ани үлде дип, акча алып эчте дә хәзер минем яңакка суга. Судка бирәм мин аны...

Рәкыйп эшнең нидәлегенә төшенеп елмаеп җибәрде һәм, ишетмәмешкә салышып, тиз-тиз китеп барды. Ул кызы, хатыны янына ашыга иде.

Кем белә, кеше характеры бәлки шулай үзгәрәдер. Әгәр шулай икән, мөгаен, алар заводы да киләчәктә алдынгылардан саналыр, алар турында да мактап сөйли башларлар.

Совет властеның 50 еллыгына

*Ә. Таҗетдинов*

# БӨЕК ОКТЯБРЬ ҺӘМ ТАТАРСТАНДА КУЛЬТУРА РЕВОЛЮЦИЯСЕ

Кешелек тарихында яңа эпоха башлап җибәргән Бөек Октябрь социалистик революциясенең илле еллыгына санаулы көннәр генә калды. Совет дәүләтенең ярты гасырлык юбилее — күп милләтле илебез халыкларының зур һәм шатлыклы бәйрәме, марксизм-ленинизм идеяләренең һәм пролетар интернационализмның бөек тантанасы ул. Совет халкы, барлык илләрнең хезмәт ияләре социализм һәм коммунизм төзү процессында ирешелгән тарихи җиңүләр белән хаклы рәвештә горурланалар. Узган ярты гасыр эчендә совет халкы тормышның һәр тармагында моңа кадәр күренмәгән зур уңышларга иреште. Материаль, социаль, политик һәм рухи революцион үзгәрешләр миллионнарча халык массаларының тормыш шартларын бөтен яклап тамырыннан үзгәртте.

КПСС Үзәк Комитетының «Бөек Октябрь социалистик революциясенең 50 еллыгына әзерлек турында»гы карарында һәм партия Үзәк Комитетының «Бөек Октябрь социалистик революциясенең 50 еллыгы» турындагы Тезисларында Октябрь революциясе җиңгәннән соң совет халкы үткән героик юлга йомгак ясала, Ленин партиясенең яңа җәмгыять төзелеше белән идарә итү буенча зур тәҗрибәсе гомумиләштерелә, хәзерге этапта алда торган бурычлар билгеләнә.

Социалистик революцияне тормышка ашыру өчен, политиканы һәм экономиканы революцион үзгәртеп кору, социаль мөнәсәбәтләрне культура революциясе белән тәэмин итү кирәклеген В. И. Ленин аеруча басым ясап әйтте. Наданлык һәм культурасызлык хөкем сөргән илдә социализм төзү мөмкин түгел. Әгәр элек, дип язды В. И. Ленин, безнең эшебез нигездә политик көрәшкә, властьны яулап алу өчен көрәшкә юнәлгән булса, хәзер ул тыныч төзелешкә күчерелә, политик һәм социаль үзгәрешләрдән соң, без культура революциясе алдында торабыз. Шулай итеп, культура революциясе яңа җәмгыять төзүнең законлы процессы булып тора һәм ул социалистик революция процессында хәл ителә торган бурычлар төркеменә керә, җәмгыять тормышының барлык якларын эченә ала.

Шунысын да искәртеп үтәргә кирәк: культура революциясе кыска вакытлы чара гына түгел, җәмгыятьнең рухи тормышын революцион үзгәртүдә өзлексез рәвештә алып барыла торган катлаулы процесс. Безнең илдә культура революциясен тормышка ашыруны яктырткан тарихи әдәбиятта бу процесс ике төп этапка бүлеп карала. Беренче этап — культура революциясенең социалистик этабы. Бу этап хезмәт ияләре политик властьны кулга алгач башлана һәм СССРда социализм тулысынча җиңгәч тәмамлана. Икенче, югары этап — культура төзелешен тагын да киңәйтү һәм тирәнәйтү, коммунизмның материаль-техник базасын тудыру һәм коммунизм төзү

барышында совет халкының культурасын югарырак күтәрү буенча яңа бурычларны хәл итү.

Культура революциясенең беренче этабында хезмәт ияләренең наданлыгын бетерү, феодаль һәм буржуаз идеологияне революция юлы белән кысрыклап чыгару, үткән заманның культура мирасын тәнкыйть күзлеге аша үткәрү һәм үзләштерү, яңа, социалистик культура тудыру, Советлар Союзы халыкларының эчтәлеге буенча социалистик, формасы буенча милли әдәбиятын һәм сәнгатен формалаштыру, иске интеллигенцияне яңача тәрбияләү, эшче һәм крестьяннардан яңа интеллигенция булдыру, акыл хезмәте белән физик хезмәт арасындагы каршылыкны киметү, марксизм-ленинизмны бөтен җәмгыять идеологиясенә әверелдерү бурычлары тора.

Культура революциясенең икенче этабында коммунизм төзү чорында гына тормышка ашырылырга мөмкин булган мәсьәләләр хәл ителә. Ул мәсьәләләр, нигездә, кешеләр аңын дин һәм башка шундый искелек калдыкларыннан арындыру, җәмгыятьнең барлык членнарында коммунистик аң һәм әхлак тәрбияләү, интеллигенциянең, эшче һәм крестьяннарның культура-техник дәрәҗәсен күтәрү, физик хезмәт белән акыл хезмәте арасындагы аермаларны бетерү, җәмгыятьнең барлык членнарында дөньяга марксистик-ленинчыл караш тәрбияләүдән гыйбарәт. Болар дөнья күләм тарихи әһәмияткә ия булган зур сыйфатлы мәсьәләләр. Аларны бары тик социализм казанышлары нигезендә, коммунизмның материаль-техник базасын булдыру һәм коммунистик иҗтимагый мөнәсәбәтләр формалаштыру процессында гына хәл итәргә мөмкин.

Хәзер, югарыда күрсәтелгән ике этапка бәйле рәвештә, культура революциясенең конкрет эчтәлеген күздән кичерик.

Культура революциясенең яңа, социалистик этабын анализлаганда иң элек шуны әйтергә кирәк: революция җиңеп чыкканның беренче көннәреннән үк, пролетариат үзе яулап алган политик властьтан материаль һәм рухи производствоны бөтен җәмгыятьнекенә әверелдерү өчен, илнең экономикасына һәм культурасына хуҗа булу өчен киң һәм хәлиткеч рәвештә файдалана. Җитештерү кораллары һәм җитештерү средстволары белән беррәттән, бу чорда культура байлыклары, шул исәптән культураның бөтен материаль базасы — нәшриятлар, типографияләр, театр биналары, кинотеатрлар, музейлар, китапханәләр һ. б. социалистик дәүләт кулына күчә. Культураның әнә шул җәмәгатьләштерелгән материаль базасына таянып һәм аны бөтен хезмәт ияләре интереслары өчен файдаланып, социалистик дәүләт үзенең беренче адымнарыннан ук моңарчы күрелмәгән дәрәҗәдә зур масштабта халык арасында культура-мәгариф һәм политик тәрбия эшләрен, хезмәт ияләренең культура дәрәҗәсен күтәрү өстендә киеренке эш җәелдереп җибәрә.

Гасырлар буена тудырылган культура байлыклары социалистик төзелеш чорында һәрьяклап өйрәнелә һәм кирәк дәрәҗәдәгесе үзләштерелә, буржуаз идеологиягә каршы көрәш алып барыла, дөньяга марксистик-ленинчыл караш тәрбияләнә.

«Кешелек дөньясының бөтен үсеше белән тудырылган культураны төгәл белү юлы белән генә, — диде В. И. Ленин, — аны яңадан эшләү юлы белән генә пролетариат культурасын төзергә мөмкин икәнен ачык аңлау булмаганда, без бу бурычны чишә алачак түгелбез. Пролетариат культурасы әллә кайдан килеп чыккан нәрсә түгел, үзләрен пролетариат культурасы буенча белгечләр дип атаучы кешеләр уйлап чыгарган нәрсә түгел. Болар барысы да бөтенләй юк сүз. Пролетариат культурасы ул капиталистик җәмгыятьнең, алпавытлар җәмгыятенең, чиновниклар җәмгыятенең изүе астында кешелек дөньясы тарафыннан эшләп чыгарылган белем запасларының законлы үсеше булырга тиеш... Кешелек дөньясы эшләп чыгарган барлык байлыкларны белү белән зиһенеңне баеткanda гына коммунист булырга мөмкин» [1].

Советлар Союзы коммунистлар партиясе, совет сәнгате эшлеклеләре Ленинның бу васыятенә һәрвакыт турылыклы булып килделәр.

Менә шушы принциплардан чыгып караганда, хәзер Кытайда бара торган «культура революциясе» дигән нәрсәнең марксизм-ленинизм белән берничнди дә бәйлә-

---

[1] В. И. Ленин. Полн. собр. соч., изд. 5-ое, М., Госполитиздат, 1963, т. 41, стр. 304—305 (рус телендә).

неше булмавы һәркемгә ачык. Киресенчә, Кытай культурасы тирән кризис хәлендә. Чөнки анда «культура революциясе» кампаниясе масса төсендә интеллигенциягә каршы һөҗүмнән башланды. Укый-яза белмәүче 300 миллион кешесе булган Кытайның югары уку йортларында һәм мәктәпләрендә укулар өзелде. Иҗади союзларның эшчәнлеге туктатылды, күп кенә театрлар, киностудияләр эшләми, әдәби журналлар бөтенләй диярлек басылмый, халыкның тарихи һәм культура байлыклары туздырыла. Кытайдагы «сул» ревизионистлар барлык культураны «феодаль» һәм «буржуаз» культура дип атыйлар һәм аннан баш тартырга чакыралар, хәзерге заман чит ил культурасын сызып ташларга өндиләр, чөнки алар аны «милли» һәм «ревизионистлар» культурасы дип саныйлар. Лев Толстой, Чехов, Шекспир, Бальзак, Роллан һәм дөнья культурасының башка бик күп атаклы эшлекләренең әсәрләре, зарарлы дип саналып, эзәрлекләнә, имеш, ул язучыларның иҗатлары «күңел төшенкелеге, идеализм һәм эгоизм» тәрбияли. Культура мирасына мондый карашның культура белән дә, революция белән дә берниндн уртаклыгы юк. ККП җитәкчеләре бу нигилистик карашны бары тик Мао Цзэ-дун һәм аның якыннарының марксизм-ленинизмны шовинистик һәм бөек державачылык шовинизмы карашлары белән алмаштырырга маташуларын яклау өчен генә алга сөрәләр.

Культура мирасына мөнәсәбәттә марксизм-ленинизм зәгыйфь сул нигилистик юнәлешкә сыйнфый карашны, конкрет-тарихи анализны каршы куя. Феодализм белән көрәшкәндә буржуазиянең дөнья культурасы байлыгына зур өлеш керткәнлеген онытырга ярамый. Буржуаз җәмгыять культурасының буржуаз культура гына булмавын да истә тотарга кирәк. Һәр милли культурада, эксплуататор сыйныф культурасы белән беррәттән, демократик һәм социалистик культура элементлары да азмы-күпме булмый калмый.

Практика шуны күрсәтте: халык борынгыдан калган культура мирасын үзләштермичә һәм аны һәрьяклап өйрәнмичә торып, берниндн дә культура революциясе булмый һәм була да алмый. КПСС программасында язылганча, культура революциясенең төп максаты — дөнья культурасы тудырган иң яхшы үрнәкләрне үзләштереп, кешелек дөньясының культура үсешендә яңа, югары баскычка күтәрелгән коммунизм культурасын булдыру.

Яшь Совет дәүләтенә промышленностьны һәм авыл хуҗалыгын аякка бастырырга, аларны фән һәм техника нигезендә үзгәртеп корырга кирәк иде. Культура ягыннан артталыкның сәбәбе илнең экономик артталыгына бәйләнгән. Ярым крепостнойлык режимы халыкны фәкыйрьлеккә, ә бөтен илне торгынлыкка, артталыкка дучар иткән, аны Европаның капиталистик дәүләтләре кабаласына төшергән иде. В. И. Ленин әйткәнчә, бу хәлдән котылу өчен, я бар көчкә алга омтылырга, техник-экономик мөнәсәбәттә аеруча нык үскән илләрне куып җитәргә, яисә бетәргә кирәк иде.

Илебездә культура төзелеше, аерылгысыз рәвештә, экономик төзелеш базасына, эре индустрия тудырудагы уңышларга, авыл хуҗалыгын социалистик үзгәртеп коруга таянып алып барылды. Хезмәт ияләренең тормыш-көнкүреш хәлләрен туктаусыз яхшырту юлы белән, социалистик дәүләтебез кешенең рухи ихтыяҗларын канәгатьләндерә һәм үстерә барды.

Октябрь революциясеннән соң алда торган беренче чираттагы мәсьәләләрнең берсе — халыкның наданлыгын бетерү булды. Бу җиңел эш түгел иде. Чөнки иске Россиядә кырыктан артык милләтнең үз язуы бөтенләй юк, хәтта Россиянең алдынгы дип саналган халыклары арасында да бары тик дүрт кешенең бере генә укый-яза белә иде.

Шушындый артта калган илдә массаларның наданлыгын бетерү бик җитди мәсьәләгә әйләнде. Укый-яза белү өчен көрәш «РСФСР халыклары арасында грамотасызлыкны бетерү турында»гы 1919 елның 26 декабрендә игълан ителгән Ленин декретыннан соң башланды. Зур Россиянең барлык почмакларында грамотасызлыкны бетерү пунктлары оештырылды һәм анда надан халыкны укырга, язарга өйрәтә башладылар. Укый-яза белгән хезмәт ияләре ун айлык мәктәпләрдә ике класс күләмендә белем алдылар, ә аз грамоталы кешеләргә шул вакыт эчендә башлангыч белем бирелде. 1920 елның җәендә грамотасызлыкны бетерү буенча Гадәттән тыш комиссия төзелде, ә 1923 елда, совет җәмәгатьчелеге инициативасы белән, «Наданлык бет-

сен» оешмасы эшли башлады. Шул ук чорда бердәм дәүләт халык мәгарифе системасы да оештырылды.

Партия тарафыннан башкарылган шушындый мөһим чаралар аркасында, чагыштырмача кыска вакыт эчендә халыкның культура дәрәҗәсен күтәрү буенча зур борылыш ясалды. Мәктәпләрдә түләүсез уку тәртибе кертелде, шуның өстенә, эшче-крестьян балаларына байтак кына льготалар бирелде, ә рус булмаган халыкларга үз телләрендә уку мөмкинлеге тудырылды.

1926 елда Татарстандагы 9 яшьтән алып 49 яшькә кадәр булган кешеләрнең грамоталыгы 57,2 процентка җитте, ә беренче бишьеллык ахырына грамотасызлыкны бетерү буенча бик зур уңышларга ирешелде. ТАССР Үзәк Башкарма Комитетының һәм Халык Комиссарлары Советының 1931 елның 16 сентябрендә игълан ителгән «Грамотасызларның барысын да укыту турында»гы карарында, мәсәлән, Казанда грамотасызлыкның, нигездә, инде бетерелгәнлеге, ә күп кенә предприятиеләрнең, колхозларның һәм совхозларның бу мәсьәләне хәл итү алдында торганлыгы әйтелә.

Әлеге карар буенча Татарстан шәһәрләрендә һәм авылларында 16 яшьтән алып 45 яшькә кадәрге грамотасыз хезмәт ияләренең барысын да укыту гамәлгә кертелә. Һәм, шулай итеп, 1932 елның 1 гыйнварена 16 яшьтән алып 45 яшькә кадәр булган халык арасында грамотасызлыкны тулысынча бетерү бурычы куела.

Шул бурычларны тормышка ашыру нияте белән мәктәпләрне биналар, уку әсбаплары белән тәэмин итү чаралары билгеләнә, культармеецлар әзерләү буенча кыска вакытлы курслар оештыру эше башлана. Грамотасызларны һәм аз грамоталыларны җәмәгать эше тәртибендә яхшы укыткан укытучыларны һәм культармеецларны бүләкләү өчен махсус фондлар булдырыла. Әлеге зур планны тормышка ашыру өчен, ТАССР Үзәк Башкарма Комитеты һәм Халык Комиссарлары Советы барлык эшчеләрне, колхозчыларны, җәмәгатьчелекне, мәгариф хезмәткәрләрен, культармеецларны, җәмәгать, совет һәм партия оешмаларын бу эштә актив катнашырга чакыра.

Беренче бишьеллыкта гомуми башлангыч укыту да тормышка ашырыла. 1920 елда Татарстанда 161049 укучы гына (мәктәп яшендәге барлык балаларның 51 проценты) мәктәпкә йөргән булса, бишьеллык ахырына укучылар саны 354557 кешегә җитә, ягъни мәктәп яшендәге балаларның 99,4 проценты укый башлый[1].

1934 елның февраль-март айларында 16 яшьтән алып 50 яшькә кадәр булган бөтен кешеләрнең грамота дәрәҗәсен тикшерү уздырыла. Тикшерү нәтиҗәсендә 500 меңгә якын грамотасыз һәм 380 мең аз грамоталы кеше барлыгы ачыклана.

Шул уңай белән һәм партиянең кешеләрнең грамотасызлыгын һәм аз грамоталыгын тулысынча бетерү турындагы XVIII съезды карарыннан чыгып, партиянең Татарстан өлкә комитетының 1934 елның декабрендә үткәрелгән пленумы түбәндәге карарны чыгара: 1934—1935 уку елында коммунистлар һәм комсомоллар арасында грамотасызлыкны тулысынча бетерергә. Казан, Зеленодольск, Бондюг шәһәрләрендә, совхозларда, МТС эшчеләре, профсоюз членнары арасында, Әгерҗе, Апас, Арча, Балтач, Биләр, Бөгелмә, Югары Ослан, Алабуга, Чистай, Лаеш, Мәслим, Норлат, Спасс, Чаллы, Ширәмәт районнарында 16 яшьтән алып 50 яшькә кадәр булган кешеләрнең грамотасызлыгын тулысынча бетерергә. Ә калган районнарда 1934—1935 уку елында грамотасызлыкны контингентлар буенча, икенче төрле итеп әйткәндә, конкрет заданиеләр билгеләү юлы белән бетерергә.

Икенче бишьеллык ахырына 16 яшьтән алып 50 яшькә кадәрге кешеләр арасында грамотасызлыкны гына түгел, аз грамоталылыкны да бетерү — бөтен Татарстан партия оешмасының сугышчан бурычы итеп билгеләнә. Моңа ирешү өчен һәр грамотасыз һәм аз грамоталы кешене зурлар мәктәпләрендә катгый программасы, укыту планы, Халык Мәгарифе Комиссариаты тарафыннан расланган эчке тәртип кагыйдәләре булган әзерлек классларында, төп уку классларында һәм чыгарыш классларында укырга тартырга кирәклеге күрсәтелә. Бу карарны тормышка ашыру буенча партия, совет, комсомол оешмалары, республиканың халык мәгарифе органнары бик зур эш башкаралар һәм, шуның нәтиҗәсендә, инде 1939 ел ахырына 9 яшьтән алып 50 яшькә кадәрге кешеләрнең грамоталылыгы 90,4 процентка җитә, республикабыз гомуми

[1] «Красная Татария» газетасы, 1933 ел, 18 февраль саны.

белем мәктәпләре, профессиональ-техник мәктәпләр, эшче һәм авыл яшьләре мәктәпләре челтәре белән каплана.

Югары һәм махсус урта белем бирүне үстерү буенча да Татарстанда бик зур эшләр башкарылды. Октябрь революциясенә кадәр Казан губернасында нибары өч югары һәм ун урта политехник уку йорты гына булып, ул мәктәпләрдә укучы татар һәм башка милләт балалары исә бик аз иде. Ә 1926 елның 1 январена Казандагы уку йортлары саны бишкә җитте. (В. И. Ульянов-Ленин исемендәге дәүләт университеты, татар коммунистик университеты, ветеринария институты, авыл хуҗалыгы һәм урманчылык институы, Көнчыгыш педагогия институты) һәм аларда 4777 студент укый иде инде. Студентларның милли составы да бик нык үзгәрде. Әлеге 4777 студентның 69,1 процентын руслар, 11,1 процентын татарлар, 6,3 процентын еврейләр, 5,3 процентын чувашлар, 1,5 процентын марилар, 1,4 процентын мордвалар, 4 процентка якынын башка милләт вәкилләре тәшкил итә иде [1].

Беренче ике бишьеллыкта Татарстан югары уку йортлары 14634, урта уку йортлары 19574 [2] белгеч әзерләп чыгарды. Бу бишьеллыклар эчендә техник һәм фәнни интеллигенциянең составы да бик нык үзгәрде. Техника һәм фән өлкәсенә бөтен милләтләрдән дә вәкилләр килде.

Сугыш алды елларында исә югары уку йортларында белем алучы студентлар 11 мең кешедән артып китте. Фән һәм техниканың барлык тармакларында эшләрлек белгечләр әзерләнә башлады. Республикада квалификацияле инженерлар, врачлар, укытучылар, талантлы фәнни эшчеләр, әдәбият һәм сәнгать эшлеклеләре үсеп чыкты. 1939 елгы мәгълүмат буенча, республиканың халык хуҗалыгы һәм культура өлкәсендә 2629 инженер, конструктор һәм архитектор, 1157 агроном, 1225 агротехник, 1819 врач, 21935 укытучы, 1261 фәнни хезмәткәр эшли иде инде [3].

Совет власте елларында республикада күп санлы сәнгать интеллигенциясе үсеп чыкты. Революциянең беренче көннәреннән үк пролетариат диктатурасы ягына күчкән Г. Ибраһимов, Г. Камал, Ш. Камал, М. Гафури, Ф. Әмирхан, К. Тинчурин һ. б. күренекле әдипләр белән беррәттән, һ. Такташ, К. Нәҗми, М. Җәлил, Ш. Усманов кебек яшь талантлар күтәрелеп чыкты. Ул язучыларның революцион романтика белән сугарылган әсәрләре заман сынавын уңышлы үтте һәм алар хәзер дә укучылар тарафыннан яратып укылалар. Трибун-шагыйрь һ. Такташ, нык ихтыярлы М. Җәлил әсәрләре, югары гражданлык хисенә ия булган шагыйрьләр Ф. Кәрим һәм Г. Кутуй, прозаик К. Нәҗми, драматург Т. Гыйззәт һ. б. татар әдәбиятын үстерүгә үзләреннән зур өлеш керттеләр.

Революциядән соң профессиональ сәнгатьнең моңарчы булмаган төрләре дә (музыка, рәсем сәнгате һәм скульптура) туды һәм уңышлы рәвештә үсә башлады. Профессиональ татар музыкасын Салих Сәйдәшев башлап җибәргән булса, 1925 ел урталарында композиторлардан С. Габәши, Г. Әлмөхәммәдов һәм В. Виноградовлар халык көйләренә нигезләнеп язылган «Сания» операсын иҗат иттеләр. Шул ук елларда художникларыбыз иҗаты да нык үсеп китте. У. Арсланов, Ф. Таһиров, Ш. Мөхәммәтҗановларның китап графикасы өлкәсендә башкарган хезмәтләре Советлар Союзында гына түгел, хәтта чит илләрдә дә югары бәя алды [4].

Егерменче елларда нәкыш сәнгате өлкәсендә дә уңышлы эш башланды. Бакый Урманче кызыклы гына картиналар һәм портретлар иҗат итте.

Утызынчы елларда исә Татарстан художниклар союзы төзелде һәм тематик әсәрләр тудыру буенча актив эш башлап җибәрелде. Илдә барган зур социалистик үзгәрешләр белән рухланып, художниклар идея-художество эчтәлекләре ягыннан мөһим булган зур полотнолар өстендә эшләргә керештеләр.

Татар сәнгате өчен яңа тармак булган скульптура да шул елларда барлыкка килде. Бу өлкәдә С. Ахун һәм Б. Урманче шактый актив эш алып бара башладылар.

---

[1] «Труд и хозяйство» журналы, 1926 ел, 4 сан, 85—92 битләр.

[2] Х. Гимади, М. Мухарямов. «Советская Татария — детище Октября». Рус телендә. Таткнигоиздат, 1957 ел, 89 бит.

[3] Шунда ук.

[4] «Казан утлары» журналы, 1967 ел, 6—7 саннар.

Совет Татарстаны язучылары, художниклары һәм артистлары бишьеллыклар чорында халкыбызның героик үткән юлын, яңа җәмгыять төзүчеләрнең бөек образын чагылдырган күп кенә яхшы әсәрләр иҗат иттеләр.

Матбугат социалистик төзелеш өчен көрәштә культура революциясенең куәтле коралы булып тора. Октябрь революциясенә кадәр Татарстан территориясендә нибары 13 газета чыгарыла һәм зур булмаган берничә типография эшләп килә иде[1]. Октябрь революциясеннән соң исә Татарстанда матбугат чын-чынлап халык массаларын агарту коралына әверелде. Бу үсеш бигрәк тә беренче ике бишьеллык чорына туры килә. Ул чорда политик әдәбият һәм дәреслекләр бастырып чыгару бик нык артты. Мәсәлән, 1929 елда 87 мең политик әдәбият китабы чыккан булса, 1934 елда 1080 мең данә китап басылып чыкты.

Культура төзелеше бурычларын тормышка ашыруда культура-мәгариф учреждениеләренең дә роле бик зур. Октябрь революциясенә кадәр Казан губернасында бары тик 11 клуб, 9 стационар киноустановка, бер музей һәм бер халык китапханәсе[2] генә булган булса, 1937 елда исә 1691 китапханә, 2531 клуб, ун музей һәм 102 стационар киноустановка эшли иде инде[3]. Бу учреждениеләр чын мәгънәсендә халыкны укыту, агарту үзәкләренә әйләнделәр, шулай итеп, республикабыз хезмәт ияләренә үзләренең культура һәм эстетик таләпләрен канәгатьләндерү өчен реаль мөмкинлекләр тудырылды.

Культура революциясенең бурычлары халыкны укырга-язарга өйрәтүгә, музейлар, кинотеатрлар һәм китапханәләр булдыруга гына кайтып калмады, әлбәттә. Бөтен культура чаралары — китаплар, кинокартиналар, музей экспозицияләре аша совет кешеләренә халыкның культура байлыгын җиткерү, шул байлыкны үзләштерергә, аңларга өйрәтү — культура революциясенең әһәмияте менә шунда иде.

Октябрь революциясеннән соң берничә ай үтүгә үк, РКП(б)ның VIII съездында укыту эше халыкка төрле өлкәдән белем бирүгә генә кайтып калмаска, бәлки кешеләрдә аңлылык һәм дөньяга материалистик караш тәрбияләүгә дә ярдәм итәргә тиешлеге күрсәтелде. Яңа социалистик культура дөньяга фәнни, материалистик караш нигезендә, социализм һәм коммунизм идеяләре нигезендә, марксизм-ленинизм тәгълиматы нигезендә төзелде. Культураның идея нигезен, аның эчтәлеген үзгәртү, кешеләр аңында, аларның идея һәм культура дәрәҗәсендә борылыш ясау — культура төзелешенең нигезен һәм максатын менә шулар тәшкил итте.

Бу хәл милли культура үсеше өчен аеруча әһәмиятле булды. Ленинның милли политикасын тормышка ашырып, Коммунистлар партиясе милли республикаларның аң-белемен арттыру, әдәбиятын, сәнгатен, фәнен үстерү өчен, миллионнарча хезмәт ияләренең аңында чыннан да тамырдан үзгәреш ясау өчен, совет җәмгыятенең бөтен рухи, материаль көчләрен эшкә тартты.

Советлар Союзында киң масштабта алып барылган культура революциясенең социаль нәтиҗәсе чыннан да зур тарихи әһәмияткә ия булды. Чөнки нәкъ менә шул чорда илебездә социализмның тулысынча һәм ахырынача җиңүе өчен кирәк булган бөтен идеологик һәм культура шартлары тудырылды. Әмма культура революциясенең барлык бурычлары да аның беренче этабында хәл ителеп бетмәде. Социализмда хезмәт ияләренең төрле социаль категорияләре арасында материаль һәм рухи байлыкларны бүлешүдә, акыл хезмәте белән физик хезмәт арасында, авыл белән шәһәр арасында кайбер тигезсезлекләр саклана әле.

Ленинның культура революциясе турындагы теориясен яңа тарихи шартларда үстерә барып, коммунизм төзү чорында культура үсешенең практик чараларын билгеләп, КПСС үзенең яңа Программасында «Коммунистик җәмгыять чорында культура үсеше бөек культура революциясенең тәмамлану этабы булачак» дигән мөһим

[1] П. В. Абрамов. «Татарская АССР». Рус телендә. Таткнигоиздат, 1960 ел, 84 бит.

[2] «Татарская АССР за 40 лет». Рус телендә. Таткнигоиздат, 1960 ел, 140—142 битләр.

[3] Х. Гимади, М. Мухарямов. «Советская Татария — детище Октября». Рус телендә. Таткнигоиздат, 1957 ел, 91 бит.

положениене игълан итте. Бу положениенең асылы «коммунизмның җиңүе өчен кирәк булган барлык идеологик һәм культура шартларын» юнәлдерелгән.

Алда әйтелгәнчә, эшче һәм крестьяннарның культура-техник дәрәҗәсен өзлексез рәвештә күтәрә барып, аны интеллигенция дәрәҗәсенә җиткерү, барлык хезмәт ияләрен дә культура байлыкларына тагын да якынрак тарту, бөтен халыкның гомуми урта белемле булуын тормышка ашыру һәм югары белемле кешеләрнең санын бик нык арттыру бу чорның иң мөһим бурычлары булып тора. Аларны тормышка ашыру акыл хезмәте белән физик хезмәт арасындагы аерманың бетүенә китерәчәк.

Димәк, культура революциясенең ахыргы этабы баштагы этаптан үзенең характеры белән дә, үзгәрешләренең тирәнлеге белән дә шактый нык аерылып тора. Беренчедән, бу чорда культураның үсеше беренче мәртәбә тигезләнә, ныгый һәм өзлексез дәвам итә. Икенчедән, культура төзелешендә моңарчы беркайчан да булмаганча, субъектив факторның роле арта. Бу хәл, барыннан да элек, яңа җәмгыять төзүнең бөтен процессында партиянең роле көчәюдә чагыла.

Тормыш чынбарлыгы, җанлы практика бу положениеләрнең дөреслеген бик ачык раслап тора. Культураның материаль базасын үстерү һәм яхшырту, мәктәпләр, югары уку йортлары, фәнни учреждениеләр, клублар, китапханәләр, театрлар төзү һәм аларны тиешенчә тәэмин итү, радио һәм телевидение челтәрләрен туктаусыз киңәйтү турында Советлар Союзы коммунистлар партиясе зур кайгыртучанлык күрсәтә. Мисал өчен республикабыз культурасының материаль базасы үсешенә мөрәҗәгать итик. Татарстанда хәзер 9 театр, бер дәүләт филармониясе, алты йөз мең экспонаты булган сигез музей бар [1].

Республика китап нәшрияты ел саен гомуми тиражы алты миллион данә чамасы булган 450—500 исемдәге тарихи-политик һәм авыл хуҗалыгы әдәбияты, методик һәм матур әдәбият китаплары, дәреслекләр бастырып чыгара. Болардан тыш, Татарстанда 5 республика газетасы, җитмеш өч район газетасы, сигез журнал басылып килә. Аларның гомуми тиражы тугыз йөз мең данәгә якын. Радио һәм телевидение челтәре дә бик киң таралган: хәзер Татарстанда дүрт йөз мең чамасы радио-нокта, өч йөз меңнән артык радиоалгыч һәм йөз утыз меңнән артык телевизор бар. 1827 халык китапханәсе, 2545 клуб [2], 2300 ләп киноустановка республика халкына хезмәт күрсәтә. Кырыктан артык художество, музыка училищелары һәм мәктәпләре, өч меңнән артык гомуми белем мәктәпләре эшләп тора. Алар барысы да республика хезмәт ияләрен коммунистик тәрбияләү, аларның политик, профессиональ һәм гомуми белем дәрәҗәсен күтәрү эшенә хезмәт итә.

Сигезьеллык гомуми укуны тормышка ашыру һәм, быелгы уку елыннан башлап, уньеллык гомуми укуга күчү социализмның бик зур казанышы булып тора. Хәзер республикабызның гомуми белем мәктәпләрендә 600 меңнән артык бала укый. Предприятиеләрдә, колхозларда һәм совхозларда урта мәктәп бетергән яшьләр елдан ел арта бара. Республикабыз халык хуҗалыгында теләсә нинди зур мәсьәләләрне хәл итә алырлык югары квалификацияле кадрлар үсеп чыкты. Татарстан колхозларында һәм совхозларында хәзер 30 меңнән артык тракторчы, 11 меңгә якын комбайнчы һәм күп кенә башка профессия механизаторлары исәпләнә. Авыл хуҗалыгында югары һәм урта белемле 6 меңнән артык агрономнар, зоотехниклар, инженерлар һәм башка төр белгечләр эшли [3].

Урта һәм югары квалификацияле белгечләр әзерләп чыгару елдан ел арта бара. 1000 кешегә туры килә торган студентлар саны буенча Татарстан күптән инде Төркия, Пакистан һәм Иракны гына түгел, хәтта Англия, Франция һәм Швейцария кебек Европадагы алдынгы илләрне дә узып китте. Республика халык хуҗалыгында 1959 елда 94,9 мең белгеч эшләгән булса, 1965 елда аларның саны 137,5 меңгә җитте. 1959 елгы халык санын алу мәгълүматларына караганда, 1000 эшләүче кешегә 30 югары

---

[1] «Народное хозяйство Татарской АССР». Рус телендә. Статистик җыентык, Казан. 1966 ел, 249 бит.

[2] Шунда ук, 247—248 битләр.

[3] «Советская Татария» газетасы, 1967 ел, 16 февраль саны.

белемле, 19 тәмамланмаган югары белемле, 69 махсус урта белемле, 137 гомуми урта һәм тулы булмаган урта белемле кеше туры килә. Соңгы сигез ел эчендә бу сан, әлбәттә, тагын да артты инде.

Советлар Союзы фәнни хезмәткәрләр саны буенча да дөньяда иң алдынгы урыннарның берсен алып тора. Партиябезнең һәм хөкүмәтебезнең кайгыртучанлыгы нәтиҗәсендә, Совет власте елларында Татарстанда да бик күп галимнәр үсеп чыкты. 11 югары уку йортында һәм 53 фәнни тикшеренү учреждениесендә хәзер 6 меңләп фәнни-педагогик хезмәткәр эшли. Алар арасында 2 академик, бер СССР Фәннәр академиясе член-корреспонденты, 190 фән докторы һәм профессор, 1500 ләп доцент һәм фән кандидаты бар [1]. Татарстан галимнәре хәзерге заман фәннәренең барлык өлкәләрендә дә диярлек тикшеренүләр алып баралар. Шуның өстенә, Татарстан галимнәре киләчәк заман техникасының нигезен тәшкил итәчәк тикшеренүләр буенча (мәсәлән, фосфор-органик кушылмаларны, радиоспектроскопия һәм радиоэлементләнең яңа төрләрен өйрәнү буенча) Союзда алдынгы урыннарның берсен тәшкил итеп торалар.

Социализмның зур казанышлары культураны халыкка тагын да якынайтырга бик күп мөмкинлекләр бирә. Совет кешеләре культура казанышлары белән чынчынлап һәм тирәнтен кызыксыналар. Бары тик 1966 елда гына да республикабызның театрларында куелган спектакль һәм концертларны карарга бер миллион 800 меңгә якын тамашачы килде; республиканың һәр кешесе якынча 20 кинофильм карады, һәр укучы 19 китап укыды. Республикадагы үзешчән сәнгать түгәрәкләрендә хәзер 150 меңнән артык кеше катнаша.

Халыкның рухи тормышында кинофильм зур урын алып тора. В. И. Ленин киноны сәнгать төрләренең иң мөһиме дип атады, аның халык массаларын агартуда куәтле рухи чараларның берсе булачагын алдан ук әйтеп куйды. Һәм кино сәнгате хәзер чыннан да массаларны агартучы көчле рухи чарага, кешеләр күңеленә бик зур идея-эстетик тәэсир ясаучы сәнгатькә әйләнде.

Илебез киностудияләре ел саен йөздән артык художестволы тулы метражлы картиналар, меңгә якын фәнни-популяр һәм уку-өйрәнү фильмнары эшләп чыгаралар. Ул кинофильмнарда совет социалистик җәмгыятенең эше, көрәше, кайнап торган зур тормышы чагылдырыла.

Безнең республика кинопрокатында гына да 3500 исемдәге художестволы, документаль, фәнни-хроникаль һәм уку-өйрәнү фильмы бар. Бу фонд һаман саен яңа фильмнар белән тулылана тора.

Бездә кино челтәре дә бик киң таралган. Татарстанда 2300 киноустановка эшли. Һәр колхозга һәм совхозга якынча 2,4 киноустановка туры килә. Шуларның яртысыннан артыгы — 1400 данәсе — киң пленкалы, 38 е киң экранлы установка, өчтән бер өлешенә өзлексез проекция тәэмин итә торган икешәр аппарат куелган.

Кино челтәре соңгы елларда аеруча нык үсеп китте. Әгәр 1952—1958 елларда һәр елны 17 шәр генә киноустановка сафка кергән булса, 1958—1964 елларда якынча 145 әр установка сафка кереп килде. 1965—1966 елларда Татарстандагы киноустановкалар саны тагын 300 данәдән артыкка үсте. Шунысын да искәртеп үтәргә кирәк, республикабыздагы киноаппаратларның барысы да дип әйтерлек яңартылды. Шулай итеп, хезмәт ияләренә фильмнар күрсәтү сыйфаты яхшыртылды, халык та кинофильмнарны күбрәк карый башлады. 1958 елда җан башына кино карау авылда яшәүчеләргә 7, шәһәрдә 15 туры килгән булса, 1966 елда ул сан авылда 14, шәһәрдә 23 кә җитте. Бер капиталистик илдә дә киноға болай еш йөрмиләр. Америкада, мәсәлән, җан башына кино карау елына 11,8, Англиядә 7, Франциядә 6,4 чамасы гына туры килә. Соңгы елларда барлык капиталистик илләрдә дә кинога йөрүчеләр саны һаман кимүгә бара. Бары тик АКШта гына бу хәл бераз стабильләшкән, әмма ул да югары дәрәҗәдә тормый.

Совет фильмнары хезмәт ияләрен партиягә, коммунизмга бирелгәнлек рухында тәрбияләүдә, дөньяга марксистик-ленинчыл караш тудыруда, хезмәткә коммунистлар-

[1] «Советская Татария» газетасы, 1967 ел. 16 февраль саны.

ча мөнәсәбәт һәм яңа, киләчәк заман кешесенә хас сыйфатлар тәрбияләүдә зур роль уйный.

Хезмәт ияләренең художество зәвыгы, культурасы һәм гомумән аң-белеме үсә, аларның әдәбиятка, сәнгатькә карата да таләпләре көннән-көн арта бара. Безнең әдәбиятыбыз һәм сәнгатебез дә Совет власте елларында бик нык үсте, аларның халыкчанлык, большевистик партиялек, коммунистик идеялек һәм пролетар интернационализм рухы тагын да ныгыды. Совет власте елларында Татарстан язучылары иллеләп роман, йөздән артык повесть, биш йөздән артык пьеса иҗат иттеләр. Шул ук вакытта әдәбиятыбызның тематик диапазоны да киңәя, анда халкыбызның үткән героик тормышы да, бүгенге көн вакыйгалары да бик ачык сурәтләнә. Гражданнар сугышы героикасы да, индустриализация һәм авыл хуҗалыгын коллективлаштыру да әдәбиятыбызда киң чагылыш тапты, эшчеләр, колхозчылар, нефтьчеләр һәм галимнәребезнең кабатланмас образлары тудырылды. В. И. Ленин образын иҗат итүне дә әдәбиятыбызның мөһим казанышларыннан берсе дип санарга кирәк.

Татар совет әдәбияты Союз һәм дөнья аренасына күптән чыкты инде. Соңгы унбиш ел эчендә генә дә татар совет язучыларының 65 әсәре русчага тәрҗемә ителде һәм үзәк нәшриятларда басылып чыкты. Г. Әпсәләмов, М. Әмир, Ф. Хөсни, Г. Бәширов романнарын; И. Гази, Г. Гобәй повестьларын; Н. Исәнбәт, Р. Ишморат пьесаларын; Х. Туфан, С. Хәким, М. Садри, З. Нури шигырьләрен һ. б. күп кенә язучыларның әсәрләрен татар укучылары гына түгел, рус һәм башка милләт кешеләре дә яратып укый. Республика китап палатасының бик үк тулы булмаган мәгълүматлары буенча гына да татар язучыларының 75 әсәре СССР халыклары телендә барлыгы 10 миллион 120 мең данә тираж белән 520 тапкыр басылды. 13 язучының китабы 17 чит ил телендә, шул исәптән инглиз, албан, болгар, венгр, кытай, корея, монгол, немец, поляк, румын, словак, төрек, уйгур һәм чех телләрендә, 41 тапкыр чыгарылды. Әлеге 13 язучы арасыннан Г. Бәширов әсәрләре 12, К. Нәҗми әсәрләре 8, Г. Кутуй әсәрләре 7 тапкыр басылган.

Язучыларыбызның күп кенә яхшы әсәрләре киң җәмәгатьчелек һәм халык тарафыннан югары бәя алды. «Моабит дәфтәрләре» исемле шигырьләр циклы өчен, Советлар Союзы Герое шагыйрь Муса Җәлилгә Ленин премиясе, К. Нәҗминең «Язгы җилләр» һәм Г. Бәшировның «Намус» романнарына Дәүләт премияләре бирелде. Ә. Фәйзинең «Тукай», Г. Әпсәләмовның «Сүнмәс утлар» романнары, Х. Вахитның «Беренче мәхәббәт» драмасы, С. Хәкимнең шигырьләр циклы һәм «Ленин фәрманы белән» поэмасы һәм Х. Туфанның шигырьләр җыентыгы Г. Тукай исемендәге республика премияләре белән бүләкләнделәр.

Соңгы елларда язучыларыбыздан Мирсәй Әмир, Габдрахман Әпсәләмов, Фатих Хөсни, Ибраһим Гази, Атилла Расих һ. б. аеруча актив иҗат итеп, зур күләмле әсәрләр тудырдылар. Бөтен совет әдәбияты кебек үк, татар язучылары әсәрләре дә коммунистик төзелеш пафосы, илнең, халык тормышының яхшыруы, чәчәк атуы өчен кайгыртучанлык хисе белән сугарылган. Күп кенә әдипләребез заманыбызның дулкынландыргыч проблемаларын тирәнтен аңлыйлар, совет җәмгыятенең экономик тормышында һәм социаль культура өлкәсендә, халыкның культура дәрәҗәсендә барлыкка килгән үзгәрешләрне дөрес сурәтлиләр.

Күп милләтле совет әдәбияты казанышларына безнең партиябез һәрвакыт югары бәя биреп килде һәм килә. «Партия, халык җәмгыятьнең материаль һәм рухи тормышының барлык өлкәләрендәге гомуми күтәрелешне чагылдыручы совет әдәбиятының уңышларына лаеклы бәя бирәләр, — диелә Советлар Союзы Коммунистлар партиясе Үзәк Комитетының СССР язучылар союзының IV съездына котлавында. — Язучыларның III Бөтенсоюз съездыннан соң узган елларда киң танылган талантлы әсәрләр шактый күп иҗат ителде. Социалистик реализм сәнгате традицияләрен үстерә барып, сүз осталары бездәге чынбарлыкны ачып бирергә, совет кешеләренең эшләрен һәм уйларын дөрес һәм калку чагылдырырга омтылалар. Әдәбият тормыштагы яңа процессларга һәм күренешләргә, коммунистик төзелеш барышында килеп чыга торган проблемаларга һаман күбрәк мөрәҗәгать итә».

Милли культурабызның Совет власте елларында чагыштыргысыз алга киткәнлеге музыка сәнгате өлкәсендә дә бик ачык күренә. Халык көйләрен гади эшкәртүдән,

җырлар һәм зур булмаган музыкаль пьесалар иҗат итүдән башланып киткән музыка сәнгатебездә, чагыштырмача кыска гына вакыт эчендә, гадәттән тыш зур адым ясалды. Бүгенге татар совет музыкасы исә музыкаль культураның барлык жанрлары буенча да гаять зур уңышларга иреште.

С. Сәйдәшев, М. Мозаффаров, А. Ключарев, Җ. Фәйзи, З. Хәбибуллин җыр иҗатын үстерүгә шактый зур өлеш керттеләр. Композиторларыбыз иҗат иткән җырлар тематик яктан да, эчтәлекләре буенча да һаман байый, төрләнә бара. Татар совет җырларының яхшылары көн, заман вакыйгаларына һәрвакыт аваздаш булып килә. Аларда илебезнең социалистик казанышлары, совет кешеләренең уй-хисләре чагыла. А. Ключаревның «Туган ягым — Татарстан» исемле җыры республикабызның үзенчәлекле музыкаль эмблемасына әйләнде. Р. Яхинның «Коммунизм таңы», А. Монасыйповның «Казаным» исемле җырлары да халык күңеленә үтеп керде. Җ. Фәйзинең «Коммунистик бригадалар җыры», А. Ключаревның «Канатлы яшьлек» исемле җырлары да якты, шатлыклы хисләр белән сугарылган. З. Хәбибуллинның «Казакъ дустыма», А. Ключаревның «Казан-Уфа» җырларында халыклар дуслыгы матур чагылыш тапты. Җ. Фәйзи, Х. Вәлиуллин, Ә. Бакиров, Б. Мулюков, С. Садыйкова һ. б. композиторларыбызның моңлы лирик җырларын да халык яратып тыңлый.

Музыкаль культураның дәрәҗәсе, барыннан да элек, опера, балет, симфония, оратория кебек зур күләмле әсәрләр белән билгеләнә. Мәсьәләгә бу яктан килеп караганда да татар музыка сәнгатенең уңышы зур. Халык иҗатының иң яхшы үрнәкләре һәм алдынгы совет музыка мәктәбе нигезендә тәрбияләнгән татар композиторлары Совет власте елларында музыка культурасын зур күләмле әсәрләр белән баеттылар. Беренче татар операсы «Сания» иҗат ителгәннән соң үткән кырык елдан артыграк вакыт эчендә алар 28 зур музыкаль-сәхнә әсәрләре иҗат иттеләр. Аларның кайберләре хәтта бөтен совет культурасы хәзинәсенә кертелде. Н. Җиһановның «Җәлил» операсы һәм Ф. Яруллинның «Шүрәле» балеты исә Советлар Союзында гына түгел, чит ил сәхнәләрендә дә зур уңыш казанды.

Симфоник әсәрләр иҗат итү буенча да композиторларыбыз шактый уңышка ирештеләр. Н. Җиһанов, А. Леман, А. Ключарев, М. Мозаффаров кебек өлкән буын композиторларның симфоник әсәрләре һәркемгә билгеле. Бу өлкәдә урта һәм яшь буын композиторлардан Б. Мулюков, А. Монасыйпов, А. Луппов, М. Яруллин һәм башкалар да актив эшлиләр. Татарстан дәүләт симфоник оркестры төзелү композиторларга бу жанрда эшләү өчен тагын да зур стимул тудырачак.

Республикабызның художниклар коллективы да зур һәм көчле. РСФСРның күп санлы иҗади интеллигенциясе белән иңгә иң торып, җәмгыять тормышында дөрес юнәлештә барып, Татарстан художниклары эшчеләрнең, колхозчыларның, интеллигенция хезмәткәрләренең героик эшләрен, рухи дөньяларын һәм идея омтылышларын чагылдырган күп кенә полотнолар тудырдылар. Дәүләт премиясе лауреатлары Х. А. Якупов, Л. А. Фәттахов картиналары, Тукай премиясе лауреаты, өлкән рәссам һәм скульптор Б. И. Урманче әсәрләре республикабызда гына түгел, бөтен илебездә билгеле. Советлар Союзының төрле художество югары уку йортларында профессиональ белем алган Р. Кильдебеков, В. Маликов, Ә. Тумашев, Т. Хаҗиәхмәтов, И. Рафиков, М. Хәйретдинов, Х. Хәйдәров, Р. Нигъмәтуллина, И. Халиуллов һ. б. талантлы художниклар да бу өлкәдә нәтиҗәле эш алып баралар.

Бүгенге Татарстан художникларының характерлы үзенчәлеге шунда, алар сынлы сәнгатьнең барлык жанрлары буенча да актив эшлиләр. Социалистик реализм позициясендә нык торучы художникларыбыз, бердәм коллектив булып, барлык күргәзмәләрдә дә үз әсәрләре белән катнашып киләләр. Әле күптән түгел генә Совет властеның илле еллыгына багышлап Волгоградта үткәрелгән «Зур Идел» күргәзмәсендә генә дә, мәсәлән, 50 Татарстан художнигының 130 әсәре күрсәтелде.

Культура учреждениеләренең материаль-техник базаларын бик нык яхшырту буенча соңгы вакытларда партия һәм хөкүмәт тарафыннан җитди чаралар күрелде. Бу хәл безнең республикабыз мисалында да бик ачык чагылды. 1966 елда Казанда алты мең урынлы спорт сарае салынды. Политик мәгариф йорты төзелде. Герой шагыйребез Муса Җәлилгә монументаль һәйкәл куелды. Быел Идел буенда халыкара яшьләр лагере эксплуатациягә тапшырылды. Тиздән 2200 тамашачыны сыйдыра

торган цирк бинасы, консерваториянең концерт залы, актерлар йорты төзелеп бетәчәк, сынлы сәнгать музее эксплуатациягә тапшырылачак.

Совет властеның 50 еллыгы һәм В. И. Ленинның тууына 100 ел тулу уңае белән республикабызның авыл хезмәт ияләре культураны тагын да алга җибәрү буенча өч еллык план төзеделәр һәм, культура-көнкүреш учреждениеләре төзү тизлеген арттыру өчен, авылларны яшелләндерү өчен актив эш башладылар. Хәзер һәр авылда диярлек яңа клублар, китапханәләр, мәктәпләр, кибетләр, ясләләр һәм балалар бакчалары, көнкүреш хезмәте комбинатлары, торак йортлар төзелә. Соңгы ике ел эчендә генә дә республикабыз авылларында 250 яңа клуб, 71 китапханә салынып бетеп, халыкка хезмәт күрсәтә башлады. Бик күп культура-агарту учреждениеләре тирәсе төзекләндерелде һәм яшелләндерелде. Күп кенә культура учакларында яңа музыка инструментлары һәм мебель булдырылды. Арча районының «Искра» колхозы, мәсәлән, 1966 елда культура объектлары төзүгә 200 мең сум чамасы акча тотты. Ул колхозда хәзер 5 клуб, 3 китапханә, урта, сигезьеллык һәм башлангыч мәктәпләр, 3 медицина пункты, кунак өе һәм заманча салынган берничә кибет, картлар өчен торак йорты, ике бала тудыру йорты, балалар бакчасы эшли. Быел колхозчылар өчен ял йорты төзү башланды.

Питрәч районындагы «Марс» колхозында да культура төзелеше яхшы бара. Бу колхозда узган ел 320 урынлы культура сарае, кибет, медицина пункты, кунак өе, ашханә төзелде һәм авыл аша су (озынлыгы 5 километр) үткәрелде. Киләчәктә стадион һәм спорт залы төзү күздә тотыла. Колхоз идарәсе хезмәт ияләренең гомуми белем һәм культура-техник дәрәҗәсен күтәрү өчен бөтен мөмкинлекләрне тудыра. Хәзер биредә 50 кеше кичке мәктәпләрдә, 13 кешесе югары һәм урта уку йортларында укый, 170 кешесе төрле түгәрәкләрдә, мәктәпләрдә һәм семинарларда белемнәрен арттыра.

Культура учреждениеләренең материаль базасын ныгыту өчен актив эш алып барулары ягыннан Сарман районы партия һәм совет оешмалары, колхоз һәм совхоз җитәкчеләре дә мактауга лаек. Соңгы ике ел эчендә генә дә Сарман районы авылларында 11 клуб, 7 китапханә салынды. Сарманлылар 1967 ел ахырына һәр бригадага бер клуб, ә 1970 елга һәр колхоз үзәгенә культура сарае яки культура йорты булдырырга планлаштырдылар.

Башка районнар буенча да мондый мисалларны күпләп китерергә мөмкин.

Узган илле ел эчендә Татарстан культура төзелешенең кайбер нәтиҗәләре менә шулар. Алар хезмәт ияләренең социализм һәм коммунизм төзү барышында ирешелгән ифрат дәрәҗәдә зур уңышлыкларны ачык тасвирлый. «Социализм,— диелә КПСС Үзәк Комитетының Бөек Октябрь социалистик революциясенең 50 еллыгына әзерләнү турындагы карарында, — совет кешеләренә белем һәм мәгариф китерде, җәмгыятьнең рухи тормышын бик нык күтәрде һәм баетты. Совет галимнәре үз халкыбызга лаеклы хезмәт итә. Совет фәне хәзерге заман фән һәм техника прогрессының барлык өлкәләрендә дә бик яхшы нәтиҗәләргә иреште. Космосны үзләштерүдә дә аның хезмәте зур. Үткән заманның иң яхшы казанышларын үзләштергән социалистик культура, әдәбият һәм сәнгать гомум пролетариат эшенең аерылгысыз бер өлешенә әверелделәр, коммунистик җәмгыятьнең һәр яклап үскән кешесен тәрбияләүдә актив ярдәм итәләр.

Әйе, узган илле ел эчендә культура төзелешендә безнең республика моңарчы беркайчан да күрелмәгән зур уңышларга иреште. Ләкин без, ирешелгән уңышлар белән канәгатьләнеп калмыйча, тагын да алгарак бару өчен тырышырга, кимчелекләребезне дә күрә белергә тиешбез. КПСС Үзәк Комитеты бөек бәйрәм алдыннан барлык совет кешеләренең дә игътибарын әле хәл ителеп бетмәгән мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтә. Андый мәсьәләләр бездә дә бар. Иҗади оешмалар һәм культура учреждениеләре хезмәт ияләренең туктаусыз үсеп килә торган рухи һәм культура таләпләренә тулысынча җавап бирә алмыйлар әле. Бу яктан караганда язучылар, художниклар һәм композиторлар да замандашлары алдында шактый бурычлы. Революцион чынбарлыгыбыз турында, совет халкының коммунистик җәмгыять төзү өчен героик көрәше турында язылган киң колачлы әсәрләр һаман азрак әле. Авторларыбызның күп кенә әсәрләрендә зур идея тирәнлеге, тормышны киңрәк, колачлырак

масштабта сурәтләү һәм фәлсәфи гомумиләштерү җитеп бетми. Совет кешесенең эчке дөньясы, рухи байлыгы һәм уңай сыйфатлары җитәрлек чагылдырылмый.

Драматургия заман таләпләреннән шактый артта бара. Соңгы елларда Татарстан драматурглары иҗат иткән пьесалар арасында театр коллективлары тормышында этаплы күренеш булырдайлары юк диярлек. Аларда масштаблылык, фәлсәфи гомумиләштерү җитми. Пьесаларның күпчелегендә замандашларыбызны дулкынландырырлык мөһим, зур проблемалар күтәрелми.

Музыкаль культура өлкәсендә дә яңа проблемалар яши. Атап әйткәндә, опера-балет музыкалары иҗат итү буенча композиторларыбызның бик күп эшләселәре бар әле. Заман темасына караган әсәрләрнең аз язылуы да шактый нык сизелә башлады. Бу хәл М. Җәлил исемендәге опера һәм балет театрының эшенә тискәре йогынты ясый, аңа яңа милли музыка әсәрләре җитешми. Республиканың башка театрлары репертуарлары да әдәбият һәм сәнгать эшлеклеләреннән яңа әсәрләр көтәләр. Г. Тукай исемендәге татар дәүләт филармониясенең концертларында да тамашачыларның таләп һәм зәвыкларын канәгатьләндерми торган, идея-художество ягыннан йомшак әсәрләр очрый.

Культура-агарту учреждениеләре эшендә дә җитешсезлекләр күренә. Кайбер культура учреждениеләренең эшендә әле һаман формализм, бертөрлелек бетеп җитми, тормыштан, заман таләпләреннән артта калу сизелә. Китапханә эшендә һәм халыкка кино хезмәте күрсәтү өлкәсендә дә яхшыртуны таләп иткән мәсьәләләр байтак. Үзешчән сәнгать коллективларының идея-художество дәрәҗәсен дә шулай ук тиешле югарылыкка күтәрү таләп ителә.

КПСС Үзәк Комитеты культура фронты хезмәткәрләрен хезмәт нәтиҗәләрен коммунистик тәрбияләү буенча тагын да тырышыбрак эшләргә, культура-агарту эшенең барлык төрләрен тагын да киңрәк җәелдерергә чакыра. Һич шик юк ки, партиянең бу чакыруына җавап итеп, әдәбият һәм сәнгать эшлеклеләре, культура хезмәткәрләре совет кешеләренең хезмәт һәм политик активлыгын күтәрү өчен һәрьяклап ярдәм итәргә тырышачаклар.

— — □ — —

М. Гыйбадуллин

# РЕВОЛЮЦИОНЕР, ХӘРБИ ҖИТӘКЧЕ



Минем алдымда вакыт үтүдән саргая төшкән «Правда» газетасының 1943 елның 8 сентябрендә чыккан саны ята. Анда Кызыл Армиянең Верховный Башкомандующие приказы басылган.

«Оста маневр һәм омтылышлы һөҗүм итү нәтиҗәсендә, көньяк һәм көньяк-көнбатыш фронтлары гаскәрләре Донецк бассейнында немец илбасарлары өстеннән зур җиңүләргә ирештеләр... — диелгән бу приказда. Донбасс өчен сугышларда генерал-лейтенант Цветаев, генерал-лейтенант Лелющенко, генерал-лейтенант Захаров, генерал-майор Щербин, генерал-майор Моховчук, генерал-майор Белов, генерал-майор Рослый... гаскәрләре үзләренең батырлык күрсәтүе белән танылдылар һәм полковник Казарцевның 126 нчы укчы дивизиясе, полковник Крымовның 127 нче укчы дивизиясе... аеруча каһарманлык күрсәттеләр».

Бөек Ватан сугышында 127 нче укчы дивизия белән командалык иткән татар халкының данлы улы Миргазъян Галиулла улы Крымов 1892 елда Минзәлә өязе, Мендеево авылында туа. Миргазъян Крымов бик зур һәм катлаулы тормыш юлы үтә. Ул ике революциядә һәм ике дөнья сугышында катнаша, күренекле революционер һәм полководец булып җитлегә.

* * *

1917 елның март ае. Февраль революциясе дулкыннары бөтен илне чолгап алып, Чиләбе шәһәренә дә барып җитә. Бөтен хезмәт ияләре белән бергә Чиләбе хәрби гарнизоны солдатлары да хәрәкәткә килә.

Патшаның бәреп төшерелүе турында хәбәр алгач, 1917 елның 2 мартында Чиләбе шәһәренең үзәк мәйданында большевиклар җитәкчелегендә зур митинг була. Чиләбе гарнизоны офицерлары патшаны бәреп төшерү турындагы хәбәрне солдатларга белдермәскә тырышалар һәм үзләре генә аерым киңәшмәгә җыелалар. Бу киңәшмәгә офицерларның берсе килми; ул, казармага барып, солдатлар митингысын оештыра.

— Петроград эшчеләре, революцион солдатлар һәм матрослар белән бергә, кораллы восстаниегә күтәрелеп, халыкның иң явыз дошманы

булган патшаны бәреп төшергәннәр. Сезне беренче җиңү белән котлыйм. Яшәсен азатлык! Яшәсен революция! — ди ул офицер.

Көчле «Ура!» тавышлары аның соңгы сүзләрен күмеп китә.

— Иптәшләр, — дип дәвам итә офицер, — патшаны бәреп төшерү революциянең башлануын гына аңлата. Властьны халык кулына алу өчен әле озак көрәшергә туры киләчәк. Бу көрәштә без, солдатлар, барлык хезмәт ияләре белән бергә булырга тиешбез.

Бу офицер Чиләбе хәрби гарнизонындагы 109 нчы полкта рота командиры булып хезмәт итүче прапорщик Миргазъян Крымов иде. Элекке авыл укытучысы, империалистик сугыш чорында прапорщик исемен алган Крымов үзенең революцион рухта булуы һәм солдатларга ягымлы, яхшы каравы белән Чиләбе гарнизонында күптән инде танылган иде.

Гарнизон офицерлары киңәшмә үткәргән чакта, солдатлар массасы, Крымов җитәкчелегендә, шәһәр хезмәт ияләренә килеп кушылалар, большевистик ораторларның ялкынлы речьләрен тыңлыйлар, ә митингтан соң алар офицерларның киңәшмәсен таратуга һәм төрмәдәге революционерларны азат итүгә катнашалар.

1917 елның 8 мартында Миргазъян Крымов эшче һәм солдат депутатларының Чиләбе Советына сайлана. Монда ул карт большевиклардан Е. Д. Васенко, Д. В. Колющенко, С. М. Цвиллинг һәм башкалар белән таныша. Чиләбе Советы председателе һәм РСДРПның Чиләбе комитеты председателе революционер Самуил Моисеевич Цвиллинг белән ул аеруча дуслаша. Крымов Чиләбе Советында һәм аның хәрби секциясендә җиң сызганып эшкә кереша.

РСДРПның Чиләбе комитеты хәрби гарнизон солдатлары арасында, бигрәк тә мөселман солдатлары арасында революцион эш алып баруга зур әһәмият бирә.

С. М. Цвиллинг революция эшенә җаны-тәне белән бирелгән Миргазъян Крымовка мөселман солдатларын оештыру һәм аларны революцион рухта тәрбияләү эшен тапшыра.

1917 елның май аенда Чиләбе хәрби гарнизонында татар-башкорт солдатларының гомуми җыелышы була. Җыелышка җитәкчелек иткән Крымов сүз башлап болай ди:

— Туганнар! Хәзерге көндә хезмәт халкы, большевиклар партиясе җитәкчелегендә, властьны үз кулына алу өчен героик көрәш алып бара. Без, татар һәм башкорт солдатлары, бу көрәшкә актив катнашырга тиешбез. Бу эш белән турыдан-туры җитәкчелек итү өчен безгә революцион комитет оештырырга кирәк булыр.

Җыелыш мөселман солдатларының революцион комитетын төзергә карар чыгара. Комитетка член итеп Миргазъян Крымов, Рамазан Шәрипов, Мөгаллим Назаргулов, Гайса Габбасов, Шакир Динисламов, Хафиз Кушаев һәм башкалар сайланалар.

Башында Миргазъян Крымов торган мөселман комитеты татар һәм башкорт солдатларын революцион рухта тәрбияләү буенча зур эш җәелдереп җибәрә. «Без, татар һәм башкорт солдатлары, — дип яза 1919 елдан КПСС члены Мөгаллим Назаргулов үзенең истәлекләрендә, — гарнизон мөселман комитетында, аның революцион җыелышларында беренче политик мәктәп үттек».

Петроградта булган июль вакыйгаларыннан соң, бигрәк тә генерал Корнилов фетнәсе вакытында, Чиләбе шәһәрендә дә контрреволюция баш күтәрә.

Шул авыр вакытта эшче һәм солдат депутатларының Чиләбе Советы һәм Хәрби Совет председателе С. М. Цвиллинг Миргазъян Крымовны чакыра.

— Сезгә зур һәм җаваплы эш тапшырыла. Бүгенге көннән алып сез шәһәрне саклау начальнигы буласыз. Сез командалык иткән

109 нчы полкның 1 нче ротасы революцион солдатлардан тора. Шул рота тирәсенә революцион көчләрне туплагыз, — ди ул Крымовка.

Миргазъян Крымов, шунда ук үзенең революцион ротасын коралландырып, көтмәгәндә 163 нче полкның казармасын чолгап ала һәм полк командованиесе вәкилен үз янына чыгарга таләп итә. Командование вәкиле чыгып, Крымов алдына баса.

— Эшче һәм солдат депутатларының Чиләбе Советы һәм Хәрби Совет приказы буенча казарма революцион солдатлар белән чолганып алынды. Каршылык күрсәтү файдасыз. Өч минут эчендә фетнәчеләр казарма янына чыгып басмасалар, ут ачам. Бу таләпне хәзер үк полковник Иолишинга тапшырыгыз, — ди аңа Миргазъян Крымов.

Полковник үзенең контрреволюцион группасы белән казарма янына чыгып басарга мәҗбүр була. Крымов солдатларга казармага керергә куша, ә полковникны һәм контрреволюцион офицерларны Чиләбе Советына озата.

Совет председателе С. М. Цвиллинг Крымовның гарнизонда булган фетнәчеләрне оператив рәвештә һәм шау-шусыз гына тар-мар итүен хуплый һәм гарнизонда булган барлык татар һәм башкорт солдатларын Крымов ротасына күчерү турында приказ бирә.

Петроградта Октябрь революциясе җиңеп чыгу турында хәбәр булгач та, 1917 елның октябрендә эшче һәм солдат депутатларының Чиләбе Советы бөтен властьны үз кулына ала. Хәрби гарнизондагы контрреволюцион офицерлар һәм гарнизон начальнигы кулга алына. Шәһәрне саклау начальнигы, 109 нчы полкның татар һәм башкорт солдатлары ротасы командиры Миргазъян Крымов, заводларда һәм тимер юлда оештырылган Кызыл Гвардия отрядларын һәм революцион солдатларны туплый. Шәһәрнең контрреволюцион көчләренә баш күтәрергә мөмкинлек бирми, бөтен шәһәрне революцион тәртиптә тота. Миргазъян Крымов Чиләбе Советы тарафыннан гарнизон начальнигы итеп тә билгеләнә.

Чиләбедә революция җиңә. Ләкин андагы буржуазия дә йоклап ятмый. Аңа ярдәмгә Троицк шәһәреннән есаул Титов командалыгында казаклар килә. Аларның саны унбер меңгә җитә. Титов Чиләбедән ерак булмаган җирдә туктап, шәһәр Советын таратуны, Кызыл Гвардия отрядларын коралсызландыруны һәм властьны шәһәр думасына бирүне таләп итә.

Шул гадәттән тыш авыр моментта большевиклар җитәкчелегендәге хәрби гарнизон һәм 600 кешедән генә торган Кызыл Гвардия отряды шәһәрне саклап, дошманга каршы көрәшкә ташлана. Ләкин меньшевикларның, эсерларның һәм төрле оппортунистларның хыянәте нәтиҗәсендә, 1917 елның ноябрендә Чиләбе Советы властьны шәһәр думасына бирергә дип карар чыгарырга мәҗбүр була.

Чиләбе большевиклары Совет хөкүмәтеннән ярдәм сорап Екатеринбург, Уфа, Самара һәм башка шәһәрләргә мөрәҗәгать итәләр. 1917 елның ноябрь ае урталарында Уфадан, Самарадан, Сызраньнан һәм башка шәһәрләрдән Чиләбегә Кызыл Гвардия отрядлары килә. Самара отрядының командиры В. К. Блюхер була.

1917 елның 20 ноябрендә эшче һәм солдат депутатларының Чиләбе Советы утырышы була. Монда Миргазъян Крымов беренче тапкыр В. К. Блюхер белән таныша.

— Мин ун меңнән артык контрреволюцион казакларны шәһәргә кертми тотып торган яшь герой белән танышуыма шатмын, — ди В. К. Блюхер, Миргазъян Крымовка кулын биреп.

— Бу минем геройлык түгел, Василий Константинович, ә эшчеләрнең һәм революцион солдатларның геройлыгы, — ди аңа Миргазъян.

Бу утырышта Чиләбедә һәм Чиләбе өязендә бөтен властьны Советлар кулына алу турында карар чыгарыла һәм Хәрби Революцион Ко-

митет төзелә. Комитетка карт большевиклар һәм В. К. Блюхер сайлана һәм ул Комитетның председателе итеп билгеләнә. Үзен революция көрәшчесе итеп таныткан Миргазъян Крымов та Хәрби Революцион Комитетның члены була. Шул көннәрдә Уфа Советы һәм Ревкомы, татар һәм башкорт революционерларын Уфага җибәрүне сорап, Чиләбе Советына һәм Ревкомына мөрәҗәгать итә. Чөнки анда Уфа гарнизонындагы Мөселман хәрби Советына эсерлар һәм элекке офицерлар кереп тула башлаган була. Буржуаз милләтчеләр, дин вәкилләре, эсерлар һәм элекке офицерлар, Мөселман хәрби Советында оялап, милләт һәм дин исеменнән гарнизондагы 6 меңнән артык татар һәм башкорт солдатларын үзләренең таянычына әйләндерү өчен агитация җәелдереп җибәрәләр. Уфадагы татар һәм башкорт большевиклары гарнизондагы мөселман солдатларын буржуазия тәэсиреннән арындыру һәм буржуаз милләтчеләрне фаш итү буенча җиң сызганып эшкә керешәләр. Аларның мөрәҗәгатен алу белән Чиләбе Ревкомының утырышы була. Ревком председателе В. К. Блюхер берничә татар һәм башкорт революционерларын Крымов җитәкчелегендә Уфага җибәрергә тәкъдим итә.

Уфага килгәч тә, Миргазъян Крымов хәрби гарнизондагы буржуаз милләтчеләргә, эсерларга һәм элекке офицерларга каршы көрәш ача. «Көрәш» газетасының 1918 елның 16 февралендә чыккан санында аның зур мәкаләсе басыла.

«Октябрь революциясе сыйнфый көрәш өчен тагын да киңрәк юл ачты, — дип яза ул. — Власть эшче, солдат һәм крестьян депутатлары Советлары кулына күчкәч кенә «Милләтләрнең үз язмышын үзләре хәл итүе» лозунгысы гамәлгә аша башлады. Шуның белән бер вакытта Октябрь революциясе капитализмга җимергеч удар ясады. Бу хәл вак милләтләрнең хакимлек итүче байлар сыйныфын хәрәкәткә китерде. Хәрам юллар белән җыелган малларына «газраил»ның якынлашканын күргәч, байлар, аларның ялчылары — хәзрәтләр, зыялылар, офицерлар «башта милләт, аннан соң гына сыйнфый көрәш» дигән лозунг чыгардылар. Алар үзләренең сыйнфый мәнфәгатьләрен яклау юлында милли байрак астына яшеренделәр... Кыскасы, радаларның, башкорт шурасының һәм башка шундый оешмаларның Советларга каршы ачкан сугышлары милли хокукны яклау өчен түгел, ә милли буржуазияне яклау өчен ул. Авыл халкы, эшчеләр һәм солдатлар шуны яхшы аңларга тиешләр: байларга ияреп «иң башта милләт, аннан соң гына сыйнфый көрәш» лозунгысы күтәреп Советларга каршы сугыш ачу — ул, беренчедән, үзеңне байларга кол итү, һәм, икенчедән, революциядән соң алынган милли хокукларны кабергә күмү булачак. Капитал богавыннан азат булу, ирекле милләт булып яшәү фәкать Советлар хөкүмәте яшәгән, ныгыган чакта гына мөмкин булачак. Моны онытмагыз, иптәшләр!»

Крымовның мәкаләсе гарнизондагы башкорт һәм татар солдатларына партиянең һәм Совет властеның милли политикасын аңлатуда зур роль уйный. Тиздән Уфа губерна Ревкомы утырышы чакырыла. Монда татар һәм башкорт большевикларыннан Фәтхи Әхмәдуллин һәм революцион солдатлардан Миргазъян Крымов, Әхмәт Үтәшев, Муса Йосыпов, Гомәр Әльмөхәмәтов, Сәгыйть Үләмәев, Галимьян Әминев, А. Әсәдуллин, Шаһит Ходайбердин, Мәхмүт Шаһиәхмәтов, Нәҗип Әбдрәшитов һәм башкалар катнашалар. Ревком утырышы гарнизондагы Мөселман хәрби Советын бетерү, мөселман солдатларын армиядән азат итү һәм үзләре теләүче солдатларны Кызыл Гвардия отрядларына язу турында карар кабул итә.

Бу зур һәм мөһим эш белән җитәкчелек итү өчен шул ук утырышта комиссия төзелә. Комиссиягә Уфа губерна хәрби комиссары А. К. Евлампьев, Уфа губерна Ревкомы члены Б. М. Эльцин һәм Миргазъян

Крымов сайлана. Тиздән Крымов Уфа губернасындагы гадәттән тыш комиссия һәм губерна хәрби оешмаларының Советы члены булып та сайлана.

Ревком карарын гамәлгә ашыру буенча кызу эш башлана. Ялкынлы пропагандист, сәләтле оештыручы Миргазъян Крымов, урындагы революцион солдатлар белән бергә, мөселман полклары арасында зур аңлату эше җәелдереп җибәрә. Роталарга татар һәм башкорт революцион солдатларыннан агитаторлар җибәрелә һәм алар солдатлар массасына партиянең һәм Совет властеның милли политикасын аңлату буенча зур эш башкаралар.

Миргазъян Крымовның буржуаз милләтчеләргә һәм элекке офицерларга каршы көрәшүе һәм Кызыл Гвардия отрядлары төзү буенча эшчәнлеге турында шул вакытта Уфа гарнизонында революцион эш алып баручыларның берсе, 1918 елдан партия члены А. Әсәдуллин үзенең истәлекләрендә болай дип яза:

«Миргазъян Крымов катнашлыгында үткән Уфа Мөселман хәрби Советының беренче киңәйтелгән утырышы турында берничә сүз әйтеп китәргә кирәк. Бу утырышта беренче булып Крымов чыгыш ясады. Ул, Уфа солдатларын Чиләбе гарнизоны солдатлары исеменнән тәбрикләгәннән соң, болай диде: «Солдат иптәшләр! Элекке офицерлар сезне Уфа миллионерлары Хәкимовларның, Назировларның һәм башка байларның капиталын саклап калу өчен файдаланырга тырышалар. Шул максатта алар Уфа Мөселман хәрби Советына һәм Совет властена каршы агитация алып баралар. Без, һич кичекмәстән, күбесенчә элекке офицерлардан торган хәрби Советны бетерергә, ә башкорт һәм татар солдатларын таратырга, өйләренә кайтарырга тиешбез. Шул ук вакытта үзләре теләгән башкорт һәм татар солдатларыннан Кызыл Гвардия отрядлары оештыру һәм аларны дошманга каршы сугышка әзерләү безнең төп бурычыбыз.»

Крымовның тәкъдимен хуплап Мөселман хәрби Советы члennарыннан Муса Йосыпов, Шаһит Ходайбердин, Абдулла Башмаковлар чыгыш ясады. Элекке офицерлар арасында шау-шу башланды. Алар революцион солдатларны, большевикларны казармаларга якын җибәрмәскә, ә Крымовны кулга алырга кирәк, дип шауладылар. Без Крымов белән бергә, хәрби Совет утырышын ташлап, казармаларга, солдатлар арасына таралдык һәм агитация эшен җәелдереп җибәрдек. Солдатлар безне алкышлап каршы алдылар».

1918 елның 6 мартында Уфа гарнизонындагы Мөселман хәрби Советы бетерелә һәм мөселман полклары таратыла. Шул ук вакытта үзләре теләгән башкорт һәм татар солдатларыннан Кызыл Гвардия отрядлары төзү башлана. Соңыннан татар һәм башкорт солдатларыннан төзелгән бу Кызыл Гвардия отрядлары Совет власте дошманнарына каршы сугышларда зур каһарманлык күрсәтәләр.

1918 елның январь аенда Оренбург янында тар-мар ителгән ак казаклар атаманы Дутов Верхне-Уральскига килә һәм көньяк Урал заводларына, Чиләбе, Троицк шәһәрләренә куркыныч тудыра. Контрреволюцион казаклар Троицк шәһәрен төрле яклап камап алалар.

1918 елның 18 мартында Екатеринбург (хәзерге Свердловск), Пермь һәм Чиләбе Кызыл Гвардия отрядлары бердәм зур отрядка берләшә, аның командующие итеп В. К. Блюхер билгеләнә. Чиләбе Ревкомы Миргазъян Крымовның да Чиләбегә кайтуын таләп итә. Март азагында Крымов Чиләбегә килә һәм шунда ук Блюхер белән очраша.

— Яхшы, бик яхшы. Вакытында кайттыгыз, Миргазъян Галиуллович, — ди Блюхер, — хәзерге моментта Дутов гаскәрләрен тар-мар итү безнең төп бурычыбызның берсе. Безгә хәрби белгечләр һәм кызыл командирлар бик кирәк.

Миргазъян Крымов шунда ук В. К. Блюхер командалык иткән Кызыл Гвардия отрядының штабында эшкә керешә. Крымов тарафыннан төзелгән оператив планны Блюхер хуплый. Тиздән ике мең кызылгвардеецлардан торган отряд дошманның Троицк районындагы бандасына каршы һөҗүм башлый. Ике арада каты сугыш китә. Бу сугышта Октябрь революциясе чорында Крымов тарафыннан оештырылган революцион татар-башкорт солдатлары отряды элеккеге прапорщик Байбурин командалыгында батырларча сугыша.

1918 елның 2 апрелендә Троицк шәһәрен камап алган Дутов гаскәрләре тар-мар ителә. Шунда ук Миргазъян Крымов Троицк шәһәренең хәрби коменданты итеп билгеләнә. Ул монда совет органнарын ныгыту һәм хезмәт халкын Кызыл Гвардия отрядларына җәлеп итү буенча зур эш җәелдереп җибәрә.

Бу чорда Дутов, үзенең гаскәрләрен Чиләбе белән Верхне-Уральск арасында туплап, Кызыл Гвардия отрядларына каршы яңадан һөҗүмгә әзерләнә. В. К. Блюхер дошманның төп көченә җимергеч удар ясарга була һәм ул штаб утырышын чакыра.

— Безнең отрядлар Троицк ягыннан, ә Михаил Кадомцев командалык иткән берләшкән көньяк Урал отрядлары Верхне-Уральск ягыннан һөҗүм башлап, дошманны боҗрага алырга һәм бөтенләйгә тар-мар итәргә тиеш, — ди Блюхер. — Шуның өчен дә безгә, һич кичекмәстән, Кадомцев штабы белән бәйләнеш урнаштырырга кирәк. Я, әйтегез әле, кемне җибәрәбез?

— Әгәр дә штаб рөхсәт итсә, якташыбыз янына үзем барыр идем. Михаил Самуилович тәҗрибәле большевик бит һәм аннан күп нәрсәгә өйрәнеп була, — ди Крымов.

Миргазъян Крымов көньяк Урал отрядлары штабына килә һәм Михаил Кадомцевны Чиләбе отрядларының оператив планы белән таныштыра. Шунда ук һөҗүмгә әзерлек башлана.

Озак та үтми, Михаил Кадомцев һәм Миргазъян Крымов исеменә В. К. Блюхерның түбәндәге яшерен телеграммасы килә:

*«Искә алу өчен безнең отрядларның хәрәкәте турында белдерәм. Цыркунов командалыгында беренче группа гаскәрләр... 15 апрельдә Степнойга керә. Отрядларның икенче группасы Гренгрос командалыгында Орск тимер юлындагы Карталы-Черниговскийга таба... бара. Отрядларның өченче группасы, Байбурин командалыгында, Бородинск-Березинскийга таба хәрәкәт итә.*

*Беренче һәм икенче группа отрядлар белән кушылу турында Каширин отрядына боерык бирергә кушам.*

*Дошманның төп көче Касселиядә тупланган.*

*Штаб председателе Блюхер».*

В. К. Блюхер командалык иткән берләшкән отрядлар һәм Михаил Кадомцевның көньяк Урал отрядлары көчле һөҗүм башлыйлар. Миргазъян Крымов оператив план төзү белән генә чикләнми, ә корал тотып турыдан-туры сугышта катнаша, үзенең кыюлыгы белән сугышчыларны рухландыра. Тиздән дошман гаскәрләре тар-мар ителә. Дутов үзенең офицерлары белән Тургай далаларына кача.

1918 елның 26 апрелендә Чиләбе округ хәрби комиссариаты төзелә. Бу турыда шул көндә чыккан «Урал өлкә советы хәбәрләре» газетасы болай дип яза: «Урал өлкәсендә... Чиләбе, Троицк, Златоуст һәм Кустанай өязләрен берләштергән Чиләбе округ хәрби комиссариаты төзелде... Комиссариатның башкарма комитетына Блюхер, Садлуцкий һәм Крымов иптәшләр сайланды».

Шул чорда Дутов контрреволюцион көчләр җыеп, Оренбург янында тагын сугыш башлый. В. К. Блюхер кызыл гаскәрләрнең командующие итеп билгеләнә һәм Дутовка каршы сугышка китә.

Миргазъян Крымов Чиләбе хәрби округы комиссары булып билгеләнә, шәһәрдә һәм өяздә Совет властен ныгыту, эшчеләрдән сугышчан отрядлар оештыру эшенә керешә...

1918 елның 27 маенда Чиләбе шәһәрендә тупланган чехословаклар Совет властена каршы фетнә куптаралар һәм Чиләбене биләп алалар.

М. Крымов зур булмаган отряд төзеп, дошман фронтын ерып чыгарга ташлана.

— Алга, иптәшләр! Алга! Без дошман боҗрасын өзеп чыгып, үзебезнең кызыл гаскәрләргә кушылырга һәм Совет власте өчен актык тамчы каныбыз калганчы сугышырга тиешбез, — дип, ул үзенең сугышчыларын атакага алып китә.

Кызылгвардеецлар «Ура» кычкырып, Крымов артыннан атакага баралар. Крымов Шадрин шәһәренә таба омтыла. «Шадринга таба барган чакта, — дип яза ул, — төрле урыннарда кузгалган кулак восстаниеләрен тар-мар итеп, дошман кулына эләккән совет работникларын коткара бардык».

Үзенең отрядын Шадрин гарнизонына тапшырып, 1918 елның июнь башында Миргазъян Крымов Уфага кайта һәм шунда ук Уфа губерна Ревкомына бара.

— Хәзерге көндә Уфа куркыныч астында, — дип каршы ала аны Ревком председателе Б. Н. Нимвицкий, — Чиләбе һәм Самара ягыннан чехословаклар һәм акгвардеецлар Уфага таба омтылалар. Сезне Ревком губерна хәрби комиссары итеп билгелим. Сезгә һич кичекмәстән кораллы көчләрне оештыру һәм дошманга каршы сугышка әзерләү тапшырыла.

«16 июньдә кичке сәгать биштә мөселман эшчеләре союзы йортында, — дип яза партиянең Уфа комитеты органы «Вперед» газетасы 1918 елның июнь аенда чыккан санында, — башкорт һәм татар пролетариатының митингысы үткәрелде. Чехословакларның контрреволюцион чыгышына бәйләнгән вакыйгалар турында Нуриманов, Крымов иптәшләр чыгыш ясадылар. Ораторларның речьләрен, бигрәк тә аларның контрреволюциягә... каршы аяусыз көрәшкә чакыруларын җыелыш бер тавыштан хуплады».

Уфада башкорт һәм татар солдатларыннан, шулай ук шәһәр хезмәт ияләреннән Кызыл Гвардия отрядларын төзүдә актив катнашкан карт революционер, 1919 елдан партия члены Мәхмүт Шәһиәхмәтов үзенең истәлекләрендә болай дип язды:

«Бик авыр һәм катлаулы чор иде. Чехословаклар һәм акгвардеецлар Самараны алып, Уфага таба омтылдылар. Шул җаваплы моментта башкорт һәм татар халыкларының күренекле революционерлары Баһау Нуриманов, Фәтхи Әхмәдуллин, Миргазъян Крымов, Шаһит Ходайбердин, Әхмәт Үтәшев, Солтангәрәй Арслангәрәев, Сәгыйть Үләмәев, Нәҗип Әбдрәшитов, Закир Биктимеров һәм башкалар Кызыл Гвардия отрядларын оештыруда һәм гомумән шәһәр хезмәт ияләрен дошманга каршы сугышка әзерләүдә бик зур эш башкардылар... Без, империалистик сугышта катнашкан һәм сугыш тәҗрибәсенә ия булган революцион солдатлар, хәрби комиссар Крымов җитәкчелегендә кызылгвардеецларны сугышка әзерләү эшен җәелдереп җибәрдек».

Ләкин меньшевикларның һәм эсерларның хыянәте нәтиҗәсендә, Уфа губерна Советы, үзенең кораллы көчләре белән, 1918 елның 5 июлендә Уфаны калдырырга һәм Агыйдел буйлап чигенергә мәҗбүр була.

Уфа губерна хәрби комиссариаты бетерелә, ә Миргазъян Крымов, хәрби оешмаларның Уфа губерна Советы вәкиле итеп, Көнчыгыш фронтның 2 нче армия командованиесенә җибәрелә. 2 нче армия ике группага — уң һәм сул группага бүленгәч, ул сул группаның оператив

бүлек начальнигы, ә инде бу группа 5 нче Урал дивизиясенә әйләнгәч, шул дивизиянең командиры итеп билгеләнә.

Үзен чын революционер, көрәшче итеп таныткан Миргазъян Крымов 1918 елның көзендә большевиклар партиясенә керә һәм үзенең бөтен гомерен партия эшенә, халык бәхете өчен көрәшкә багышлый.

1918 елның ноябренда Крымов Мәскәүгә чакыртыла, һәм аңа партия тарафыннан зур һәм җаваплы эш тапшырыла: Хәрби диңгез Халык Комиссариатының мөселман бүлеге мөдире итеп билгеләнә. Сугышчан командир фронтка, дошманга каршы сугышка омтыла. Тиздән ул Хәрби диңгез Халык Комиссарына мөрәҗәгать итә.

— Мин бит революцияне кулга корал тотып, турыдан-туры дошманга каршы сугыш белән каршыладым, хәзерге көндә дә, үзем монда булсам да, күңелем фронтта. Фронтка китәргә рөхсәт итегез, — ди ул.

1918 елның декабрендә Крымов Казанга килә. Монда кызыл гаскәрләрнең командованиесе аңа командный курслар оештыру эшен тапшыра. Тиз вакыт эчендә командный курслар оештырылганнан соң, ул, 1919 елның мартына кадәр, татар-башкорт егетләреннән күп кенә командирлар әзерләүгә катнаша һәм аларны фронтка озата. Соңыннан ул үзе дә Колчак бандаларына каршы фронтка китә.

...Менә Чиләбе хәрби Советы тарафыннан 1919 елның сентябрендә Миргазъян Крымовка бирелгән мандат. Анда болай дип язылган:

*«Бу мандат Чиләбе хәрби Советы тарафыннан Чиләбе хәрби ныгытылган районының штаб начальнигы Миргазъян Галиуллович Крымовка бирелде. Көнчыгыш фронтының ныгытылган районнары идарәсе турындагы вакытлы Положение нигезендә, Крымовка үзенең эшен үтәү буенча телефоннар, телеграфлар, бөтен пассажирский поездлар, санитарный, почтовый, хәрби, товарный, балласт һәм резерв поездлар һәм су бассейннарын кисеп чыгу средстволары белән һич комачаулыксыз файдалану хокукы бирелә.*

*Югарыда күрсәтелгән Положение нигезендә ныгытылган районадагы бөтен учреждениеләр һәм халыклар Крымов иптәшнең бөтен таләпләрен һәм боерыкларын һичбер сүзсез үтәргә тиешләр».*

Колчак бандасы тар-мар ителә. Миргазъян Крымов Кызыл Армия сафында, сугышчан поста кала. Хәзер инде ул уку, үзенең хәрби белемен арттыру турында уйлый башлый.

Ләкин тәҗрибәле хәрби белгечне әле тагын ерак юллар, каты сугышлар көтә.

1921 елның февраль ае. Акгвардеецлар генералы, барон Унгерн, Япония ярдәмендә, контрреволюцион көчләр туплап, безнең күрше Монголиядә сугыш хәрәкәте җәелдереп җибәрә, аның башкаласы Урганы басып ала һәм Совет иленә ыргыла. Март аенда төзелгән һәм башында Сухэ-Батыр торган Монголия Халык Революцион хөкүмәте ярдәм сорап Совет хөкүмәтенә мөрәҗәгать итә. Совет хөкүмәте барон Унгерн бандасын тар-мар итү өчен экспедицион корпус җибәрергә карар итә.

Миргазъян Крымов экспедицион корпусның штаб начальнигы урынбасары итеп билгеләнә. Кызыл Армиянең оператив планы белән танышу өчен экспедицион корпус штабына Сухэ-Батыр килә. Монда ул экспедицион корпус командирлары, шул исәптән Миргазъян Крымов белән дә таныша.

Кызыл Армия частьлары, Монголия революцион армиясе белән бергә, барон Унгерн бандасына каршы көчле һөҗүм башлый. Ике арада каты сугыш башлана. Крымов турыдан-туры бу сугышларга катнаша, шәхси батырлык үрнәге белән кызылармеецларны рухландыра.

Барон Унгерн бандасы тар-мар ителә һәм Монголия җире дошманнан тазартыла. Монголия халкы Кызыл Армия частьларын зур шатлык белән каршылый.

Миргазъян Крымов 1921 елның сентябрендә Мәскәүгә килә һәм В. М. Фрунзе исемендәге хәрби академиягә укырга керә. 1926 елда ул академияне уңышлы тәмамлый. Озак та үтми, Миргазъян Крымов Төркиягә хәрби атташе итеп җибәрелә. 1931—1932 елларда Кавказ армиясендә эшли. Һәм 1933 елда, М. В. Фрунзе исемендәге хәрби академиянең оператив факультетын тәмамлаганнан соң, 1 нче Казан укчы дивизиясендә эшли. 1935 елда аны Фрунзе исемендәге академиягә укытучы итеп чакыралар. Армиядән запаска күчкәч тә Крымов тик ятмый: башта И. В. Сталин исемендәге Мәскәү институтында, соңыннан Кызыл Армиянең югары хәрби гидро-метеорология институтында өлкән укытучы булып эшли.

* * *

Бөек Ватан сугышы... Запастагы полковник Миргазъян Крымовны 1943 елның башында дивизия командиры итеп билгелиләр. Немец илбасарларына каршы сугышларда 127 нче укчы дивизия полковник Миргазъян Крымов командалыгында зур героик юл үтә һәм гвардия дивизиясе исемен ала.

Донбасс өчен сугыш... Немецлар Донец суының уң як ярын — Белгород калкулыкларыннан алып Ворошиловград районына кадәр — бик нык ныгытылган рубежга әйләндерәләр, аны «Украин җирен биклә торган Харьков йозагы һәм Украинаның Белгород бастионы» дип исемлиләр. Бу рубежны саклау өчен немецларның сайланма частьлары туплана.

Кызыл Армия частьлары «Белгород бастионы»н җимереп үтәләр һәм Донбассны азат итәләр. Гвардия полковнигы Крымов дивизиясе Чистякова шәһәре районында геройларча сугыша. Югарыда китерелгән Верховный Башкомандованиесе приказында 127 нче укчы дивизиясенә «Чистяков дивизиясе» исеме бирелә.

Донбасс сугышыннан соң, гвардия полковнигы Миргазъян Крымов дивизиясе Кызыл Армиянең башка частьлары белән бергә, Совет илен немец илбасарларыннан азат итеп, Румыния һәм Венгрия территориясен фашистлардан тазарту сугышларында катнаша һәм Чехословакия җиренә бәреп керә.

Дошманга каршы сугышларда аеруча геройлык күрсәткәне өчен Миргазъян Крымов Ленин ордены, өч Кызыл Байрак ордены һәм күп кенә медальләр белән бүләкләнә.

Ләкин полководец Миргазъян Крымовка җиңү бәйрәмен күрергә туры килми. 1945 елның 15 апрелендә Чехословакиянең Самбор шәһәрендә фашистларга каршы каты сугышта гвардия полковнигы Крымов геройларча һәлак була.

Сугыш рәхимсез. Үзенең Ватанын чын күңелдән яраткан һәм аны дошманнан саклау өчен бөтен гомерен биргән Миргазъян Крымов илебездән ерак җирдә, Самбор шәһәрендә мәңгегә ятып кала.

Геройлар исеме үлемсез! Совет халкы үзенең данлы улы, революционер, галим, батыр командир Миргазъян Галиулла улы Крымовның исемен һәрвакытта йөрәгендә саклаячак.

——□——

# ТАТАР МӘДӘНИЯТЫНЫҢ КӨНДӘЛЕК ДӘФТӘРЕННӘН

## 1921

7 январьга кадәр. Татарстан Халык мәгариф комиссариаты галимнәрнең иң яхшы фәнни хезмәтләрен бүләкләү турында карар кабул итте. Бүләкләнгән хезмәтләр арасында Г. Шәрәфнең «Татар әдәбиятының русча тәрҗемәдәге үрнәкләре» исемле китабы да бар.

14 январь. «Эшче» газетасында шундый белдерү басылды:

«Бүген... сәгать 1 дә... эшчеләр клубында Россия яшь коммунистлар Союзының Татарстан өлкә комитеты тарафыннан пролетариат театры маузугында бәхәс мәҗлесе ясалачак. Иптәш Фатих Сәйфи тарафыннан доклад ясалачак».

Январь. ПУР каршындагы Шәрык бүлеге «Кызыл дәфтәр» исемле журнал чыгара башлады. Редакторы Ф. Бурнаш. Аның битләрендә Ф. Әмирхан, М. Гали, Ф. Бурнаш, К. Әмири, Б. Рәхмәт, Г. Харис, Г. Сөләйман, С. Җәлал һ. б. актив язышты.

11 февраль. «Ревизор» комедиясенең премьерасы булды. Әсәрне татарчага Г. Камал тәрҗемә иткән.

25 февраль. Казанда Югары партия мәктәбе ачылды. Анда мөселман, мари һәм чуваш бүлекләре бар.

Февраль. «Кызыл шәрык» журналының 8—9 саннарында С. Кудашның «Авылда» исемле поэмасы һәм Г. Нигъмәтинең «Октябрь һәм әдәбият» дигән мәкаләсе басылды.

31 март. «Коммунист» газетасында, Шәехзадә Бабичның үтерелүенә 4 ел тулуга багышланып, «Дүрт ел» дигән мәкалә басылды.

Анда шундый юллар бар: «Бабич үзенә-үзе нык ышанган вә көннән-көн алга бара торган истигъдадлы яшь шагыйрь иде. Ул шигырьне халыкның үз тормышыннан, халык кичергән хадисәләрдән алып яза иде. Шуңа күрә аны чын халык шагыйре дип атарга туры килә».

15 апрель. «Отелло» трагедиясенең премьерасы булды. Әсәрне татарчага М. Мутин тәрҗемә иткән.

Шул ук көнне Томскида татар артистлары «Мәкер һәм мәхәббәт» трагедиясен күрсәттеләр. Спектакльнең режиссеры Н. Сакаев.

13 майга кадәр. Г. Тукайның «Шүрәле» поэмасы русча басылып чыкты. Тәрҗемәчесе П. Радимов.

5 июнь. Уфада Г. Тукай исемендә клуб эшли башлады. Клуб каршында әдәбият, драма һәм музыка түгәрәкләре бар.

25 июнь. Татарстан чикләрендә татар телен гамәлгә кую турында декрет игълан ителде.

«Известия ТатЦИКа» газетасы, 25 июнь.

27 июнь. Татарстанның берьеллыгы уңае белән, университетның Актлар залында татар халык поэзиясе һәм әдәбияты кичәсе үткәрелде. Кичәдә Г. Тукай, С. Рәмиев, Ф. Бурнаш, Гыйффәт туташ, Г. Рәхим әсәрләре укылды.

28 июль. Ачыгучыларга ярдәм итү буенча республика комиссиясе оештырылды.

5 август. «Известия ТатЦИКа» газетасында түбәндәге белдерү басылды:
«Татарстан Мәгариф Халык Комиссариатының Әдәбият бүлеге (Лито) татар әдәбияты буенча лекцияләр оештыра. Темалар: 1. Татар беллетристлары сурәтләвендә Идел буе татарлары арасында мещанлык; 2. Революцион хәрәкәтнең татар язучыларында чагылуы һәм 1917 елдан соң татар әдәбияты; 3. Татар әдәбиятында консерватизмга һәм дини хорафатларга каршы көрәш; 4. 1905 елга кадәр Идел буе татарлары арасында аң үсеше һәм иҗтимагый хәрәкәт (шул чорның әдәбияты буенча); 5. Татар халык авыз иҗаты әсәрләрендә татар халкының рухы һәм азатлыкка омтылышлары чагылу.
Лекцияләр укуга Ф. Әмирхан, Г. Ибраһимов, Г. Рәхим, Г. Гобәйдуллин, Х. Бәдыйги һ. б. тартылды».

Октябрь. Г. Тукай әсәрләре рус телендә аерым китап булып басылып чыкты. Тәрҗемәчесе П. Радимов.

Ноябрь башы. Татарстан Үзәк Башкарма комитеты «Ачлык» исемле әдәби җыентык чыгарырга карар бирде.

1922 елда, шушы карар нигезендә, «Ачларга әдәби ярдәм мәҗмугасы» исемле ике китап чыгарылды. Редакторлары Г. Ибраһимов һәм Ф. Бурнаш.

30 ноябрь. Орск шәһәрендә тиф авыруыннан шагыйрь Дәрдмәнд (Закир Рәмиев) үлде.

## 1922 ел.

17 январь. «Татарстан хәбәрләре» газетасында Г. Ибраһимовның «Яңа әсәрләр» исемле мәкаләсе басылды.

26 январьга кадәр. Башкорт дәүләт нәшрияты ачыгучылар файдасына Мирзановның «Кызыл чәчәкләр», «Кечкенә революционер» һәм «Ак патша» дигән хикәя җыентыкларын бастырып чыгарды.

27 январь. Зур театр бинасында Афзал Таһировның «Янгура» драмасы буенча эшләнгән спектакльнең премьерасы булды.

Январь. «Кызыл шәрык яшьләре» журналының беренче санында Мәхмүт Максудның «Оҗмах сезгә, дөнья безгә» исемле нәсере басылды.

4 февраль. Г. Ибраһимов «Татар әдәбияты» исемле мәкаләсен язып тәмамлады. Мәкалә «Татарстан хәбәрләре»нең 7 февраль санында басылды.

17 февраль. «Татарстан хәбәрләре» газетасы идарәсендә язучылар, шагыйрьләр, редакторлар һәм нәшрият эшчеләренең җыелышы уздырылды. Җыелыш ачыгучы балалар файдасына «Ярдәм» җыентыгының икенче китабын бастырырга карар чыгарды. Язучылар бу җыентыкка үзләренең иң яхшы әсәрләрен бүләк итәргә булдылар.

1 март. «Татарстан хәбәрләре» газетасында Г. Ибраһимовның «Тарихи кыңгыравык өзелде» исемле мәкаләсе басылды.

7 апрель. Зур театр бинасында Г. Камалның «Хафизалам иркәм» комедиясе буенча эшләнгән спектакльнең премьерасы булды.

14 апрель. Г. Тукайның үлүенә 9 ел тулу уңае белән, «Урал» газетасында «Габдулла Мөхәммәтгариф улы Тукаев» исемле мәкалә басылды.
«Татарстан хәбәрләре» газетасының 17 апрель санында Ф. Бурнашның «Тукай шигырьләрендә иҗтимагый моңнар» исемле зур мәкаләсе басылып чыкты.

21 апрель. Зур театр бинасында «Гамлет» трагедиясе буенча эшләнгән спектакль күрсәтелде. Баш рольдә М. Мутин уйнады.

19 май. «Татарстан» газетасында Г. Ибраһимов «Каюм Насыйриның вафатына 20 ел тула» исемле мәкалә белән чыкты.

Татарстан Халык Мәгариф комиссариаты каршындагы Гыйльми Үзәк, К. Насыйри бәйрәмен уздыру өчен, Г. Ибраһимов, С. Атнагулов, Г. Гобәйдуллиннар составында юбилей комиссиясе төзеде.

22 майга кадәр. Татарстан дәүләт нәшрияты «Бабич шигырьләре» исемле мәҗмуга чыгарды. Җыентыкны төзүче һәм сүз башы язучы — Г. Ибраһимов.

Май. «Безнең юл» журналының беренче саны чыкты.

Июньнең беренче яртысы. Г. Ибраһимовның «Кызыл чәчәкләр» хикәясе һәм М. Фәйзинең «Галиябану» драмасы аерым китаплар булып басылып чыкты.

Июнь — август. «Кызыл шәрык яшьләре»нең 6—8 саннарында Нәкый Исәнбәтнең «Уракчы кыз» исемле шигыре басылды.

Июль — август. Һ. Такташ Ташкенттан Мәскәүгә күчеп килде.

25 август. Ф. Әмирханның «Фәтхулла хәзрәт» әсәре буенча эшләнгән спектакльнең премьерасы булды.

Сентябрь башы. Татарстан дәүләт нәшрияты «Каюм Насыйри мәҗмугасы» дигән китап бастырып чыгарды. Китапта төрле авторларның бөек мәгърифәтче турындагы мәкаләләре тупланган.

7 сентябрь. Оренбургта яшь татар язучылары түгәрәге Әхмәт Фәйзинең «Матурлык дөньясында» исемле комедиясен сәхнәгә куйды. Уенда татар язучыларыннан Ә. Фәйзи, Т. Ченәкәй һәм Муса Җәлил катнашты.

19 сентябрь. Казан коммунистлар университетының гыйльми советы расланды. 19 кешедән торган бу советка язучылардан Г. Ибраһимов һәм Г. Ходаяров кертелде.

Сентябрь. Татар-башкорт коммунистларының Бөтенроссия конференциясе карары буенча, Мәскәүдә «Нәшрият кооперативы» төзелде.

18 октябрь. «Безнең байрак» газетасының беренче саны чыкты. Редакторлары Ф. Бурнаш һәм Г. Мансуров. Газетада актив язышучылар: Г. Ибраһимов, Ш. Усманов, Ф. Сәйфи-Казанлы, Ф. Әмирхан, Г. Камал, Ш. Рәмзи, М. Гали, К. Эмири, К. Нәҗми һ. б.

Газета 1924 елның мартында чыгудан туктый.

14 ноябрь. Ш. Усмановның «Бай кызы» әсәре буенча эшләнгән спектакльнең премьерасы булды.

Ноябрь. РКСМ Үзәк Комитеты янындагы татар-башкорт бюросы «Яшь эшче» исемле журнал чыгара башлады.

Ноябрь. Һ. Такташ Мәскәүдән Казанга килде.

22 ноябрьдә Гыйльми Үзәкнең редакцион коллегиясе утырышында Такташның «Җир уллары» трагедиясе буенча фикер алышу уздырылды. Трагедияне Татарстан китап нәшриятында басып чыгарырга дигән карар кабул ителде.

6 декабрь. «Эшче» газетасы эшчеләр тормышын чагылдырган әсәрләргә конкурс игълан итте.

Декабрь. «Безнең юл» журналының 5 санында Һ. Такташның «Ил трагедиясе» исемле әсәреннән «Нәләт» дигән пролог басылды.

## 1923 ел.

1 январь. Дәүләт татар театры бинасында театр техникумы ачуга багышланган тантаналы җыелыш уздырылды.

25 январьга кадәр. «Чаян» журналының 1 саны чыкты.

31 январь. Мәскәү татар артистлары труппасы К. Тинчуринның «Иосыф-Зөләйха» комедиясе буенча эшләнгән спектакль күрсәтте. Спектакльнең режиссеры М. Мәһдиев.

Январь. «Мәгариф» журналында Ш. Усмановның «Югалган иман» исемле хикәясе басылды.

6 февральгә кадәр. Г. Газиз һәм Г. Рәхимнәрнең «Татар әдәбияты тарихы» дигән китабы басылып чыкты.

Февраль. Татарстан Мәгариф Халык Комиссариаты иң яхшы сәхнә әсәрләренә конкурс игълан итте.

Мартка кадәр. С. Габәши һәм Г. Әлмөхәммәтов беренче татар операсы «Сания»не язу эшенә керештеләр. Соңрак аларга композитор Ю. Виноградов та кушылды.

28 март. «Безнең юл» журналының 8—9 саннарында Г. Сәгъдинең «Татар шагыйрьләре арасында Тукай» исемле мәкаләсе басылды.

Март. Ж. Вәлидинең «Очерк истории образованности и литературы волжских татар» исемле китабы Мәскәү нәшриятында басылып чыкты.

7 апрель. Язучы Фатих Халиди үлде (туган елы 1850).



*«Татарстан» газетасы редакциясендә.*

10 апрель. «Нәшрият кооперативы»нда дингә һәм динчеләргә каршы юнәлдерелгән «Комсомол бәйрәме» исемле китап басылып чыкты.

12 апрель. Татар дәүләт театры «Җир уллары» исемле спектакль күрсәтте. Идея ролендә әсәрнең авторы һ. Такташ үзе уйнады.

15 апрель. Татар матбугаты һәм җәмәгатьчелек Г. Тукайның үлүенә 10 ел тулуны киң рәвештә билгеләп үтте.

15 апрельдә Буада, 16 апрельдә Казанда Г. Тукайны искә алу кичәләре уздырылды. 27 апрельдә Уфада оештырылган Г. Тукай кичәсендә шагыйрьнең тормыш юлы турында доклад белән М. Гафури чыкты.

Апрель — июнь. «Кызыл шәрык яшьләре» журналының 4—6 саннарыннан Ш. Усмановның «Кызыл байрак астында» исемле әсәре басыла башлады.

14 май. һ. Такташ «Нота» шигырен язды. Әсәр, «Алтын сарайларга» исеме белән, башлап аерым листовка итеп басыла һәм СССР илчесе Воровскийның хыянәтчел тәстә үтерелүе уңае белән оештырылган демонстрациядә халыкка таратыла.

Г. Гали «һади Такташ» исемле мәкаләсендә бу хакта болай яза:

«Әнә тыгыз колонналар арасында... берәү ниндидер кәгазь таратып йөри. Тузган озын көлсу чәчле, зур зәңгәр күзле, өстенә соры пальто кигән әнә шушы егет турында... «Һади Такташ! Һади Такташ!» дигән сүзләр таралды. Әле ул чагында 22 генә яшендә булган Тамбов егете кичен иптәш Воровский үтерелү хәбәрен ишеткән дә төн буе утырып шигырь язган. Иртә белән «Шәрык матбагасы»на барып, шундагы наборщиклардан җыйдыртып... бастырып та өлгергән. Хәзер шул шигырьне култык астына кыстырып, икенче кулы белән өләшеп йөри икән».

«Совет әдәбияты» журналы. 1935 ел. 12 сан.

20 майга кадәр. Чиләбедәге татар-башкорт мәктәбенә Г. Ибраһимов,ә китапханәгә Ш. Бабич исемнәре бирелде.

31 май. Гыйльми Үзәк, Болгарны өйрәнү өчен, Г. Максуди, профессор Бороздин, Фирсов, Смолиннар составында махсус комиссия төзеде.

Май. Нәкый Исәнбәтнең «Һиҗрәт» комедиясе Златоуст өязе Мәсгут авылы үзешчәннәре тарафыннан сәхнәгә куелды.

3 июнь. М. Гафуриның иҗат эшчәнлегенә 20 ел тулу көнен Татарстан һәм Башкортстан җәмәгатьчелеге киң рәвештә билгеләп узды.

7 август. «Татарстан» газетасында К. Тинчуринның «Татар театры нинди юл белән барырга тиеш?» исемле мәкаләсе чыкты. Шушы мәкалә белән татар театры турында фикер алышу башланып китте. Газетаның 13 август санында Ә. Гомәровның «Татар театры турында фикерләр», 17 август санында Ш. Усмановның «Үткән кышкы сезонда татар театры», 11 ноябрь санында К. Тинчуринның «Хәзерге театрның рәвешен, формасын үзгәртергә кирәк» дигән мәкаләләре басылды.

Августның беренче яртысы. Г. Ибраһимов, «Безнең көннәр» романының икенче бүлеген язып бетереп, Шәрык нәшриятына (Мәскәү) тапшырды.

27 сентябь. Татар коммунистлары университетында «Эшче» газетасының чыга башлавына биш ел тулуга багышланган кичә уздырылды.

30 сентябрьдә шушы юбилейга багышлап Мәскәүдә уздырылган тантаналы утырышта Г. Ибраһимов, М. Гафури һәм С. Сәетгалиевләргә «Эшче хәбәрчеләр», М. Крымовка «Кызылармеец хәбәрче» дигән мактаулы исемнәр бирелде.

Сентябрь. Г. Ибраһимов «Казакъ кызы» романының яңа вариантын эшләп бетерде.

Сентябрь — октябрь. Иң яхшы сәхнә әсәрләренә уздырылган конкурсның йомгаклары игълан ителде. Беренче премияләр Афзал Таһировның «Күчү чорында», М. Фәйзинең «Адашкан күңел», К. Әмиринең «Пайтәхет җәлладе» әсәрләренә бирелде.

25 ноябрь. Университетның татар әдәбият түгәрәге һәм Татарстан журналистлар Союзы әдәби кичә оештырдылар. Анда Г. Ибраһимов «Марксизм карашыннан чыгып татар әдәбиятын өйрәнү» дигән темага доклад ясады, Ш. Усманов «Памирдан радио» исемле фантастик повестен укыды.

30 ноябрь. Университетта уздырылган әдәби кичәдә Ш. Усманов һәм М. Җәлил яңа хикәяләрен, Һ. Такташ һәм К. Нәҗми яңа шигырьләрен укыдылар.

1 декабрь. Мәскәүдә «Яшь эшче» журналының чыга башлавына бер ел тулуга багышланган җыелыш булды. Почетлы президиумга В. И. Ленин, С. Сәетгалиев, Г. Ибраһимов һ. б. сайланды. Журналның эше турында доклад белән М. Парсин чыкты.

5 декабрь. К. Нәҗми матбугатта «Татар әдәбиятындагы «имажинизм» вакытлы рәвештә бетә» дигән белдерү белән чыкты.

Декабрь. «Безнең юл» журналының 1924 елгы 3 санында Г. Сәгъдинең «Яңа әдәби агымнардан футуризм» исемле мәкаләсе басылды.

## 1924 ел.

2—5 февраль. Һ. Такташ «Гасырлар һәм минутлар» исемле поэмасын тәмамлады.

7 февраль. Бер төркем татар язучылары «Октябрь» исемле оешма («кҮмәк») төзеделәр. Күмәкнең секретаре К. Нәҗми, членнары Ш. Усманов, Г. Кутуй, членлыкка кандидатлар Хуҗа Рәфиков, Ф. Бурнаш.

10 февральдә Ф. Бурнаш, Ш. Усманов, К. Нәҗми, Ф. Әсгать, Г. Кутуй барлык язучыларга, шагыйрьләргә һәм журналистларга мөрәҗәгать хаты яздылар. Ул «Безнең байрак» газетасының 15 февраль санында «Татар инкыйлаби эшче-крестьян язучыларының «Октябрь» күмәгеннән урыннардагы шагыйрь, әдип, мөхәррирләргә, әдәбият мөхипләренә, түгәрәк һәм башка әдәби оешмаларга ачык хат» исеме белән басылды.

7 мартка кадәр. Татарстан нәшрият комбинаты «Ленин һәм яшьләр» исемле җыентык бастырып чыгарды. Редакторы Шакир Рәмзи.

31 март. Татар дәүләт театрында Г. Кариевка багышланган кичә уздырылды. Соңыннан К. Нәҗминең «Яңа печән базары» дип аталган сатирасы сәхнәгә куелды.

Март — апрель. «Мәгариф» журналының 3—4 санында «Татар сәхнә әсәрләренә яңа конкурс» игълан ителде. Татарстан халык мәгарифе комиссариаты ачкан бу конкурсның шартлары «Кызыл Татарстан» газетасының 27 май санында да басылды.

18 апрель. «Сулф» күмәге үзәк коммунистлар клубында татар театры хакында диспут оештырды.

20 апрель. Г. Ибраһимов үзәк коммунистлар клубында «Ак әдәбиятлар (төрек-татар эмигрантларының матбугаты)» хакында доклад укыды.

27 апрель. «Сулф» күмәге Һ. Такташ иҗатына багышланган диспут оештырды. Футурист Ризванов шагыйрьнең иҗаты турында доклад ясады. Шул уңай белән «Татарстан» газетасы түбәндәгечә язды:

«Доклад, гадәттәгечә, демагогия нигезенә корылганлыктан, бик кытыршы, тупас булып чыкты. ...эшче-крестьян яшьләреннән җыелган аудитория ул фикерләргә кушылмады.

...Һади Такташ зур аудитория тарафыннан давыллы алкышлар белән каршыланды. ...Диспуттагы фикерләрнең күпчелеге Һ. Такташның пролетариат идеологиясенә якынлаша баруын, бу көнге эшче-крестьян тормышыннан тирән мәгънәле, инкыйлаби әсәрләр бирә башлавын исбат иттеләр. Һадины кат-кат алкышлагач, резолюциясез-нисез генә диспут ябылды».

18 май. С. Фәхри, Мохтасаров, Г. Хәбиб «Октябрь» күмәгенә кабул ителделәр. Шул ук җыелышта, «Октябрь»ның декларациясен яңадан төзү өчен, К. Нәҗми, Ш. Усманов, Г. Гали, Ф. Әсгать, Мохтасаровлар составында комиссия сайланды. Декларациягә нигез итеп К. Нәҗми язган тезислар кабул ителде.

Май. Рус телендә «Татар халык авыз иҗаты истәлекләре» («Памятники татарской народной словесности») исемле җыентык басылып чыкты. Төзүчесе Васильев.

Май — июнь. «Кызыл шәрык яшьләре» урынына Казанда Россия яшь коммунистлар Союзы Татарстан өлкә комитеты органы «Октябрь яшьләре» журналы чыга башлады.

3 июнь. «Октябрь» күмәге татар әдәбияты турында диспут оештырды.

Июнь уртасы. Казанда Ш. Усманов җитәкчелегендәге урам театрлары булып узды.

21 сентябрь. «Сулф» белән «Октябрь»дагы партия һәм комсомол членнарының фракция җыелышы булды. Анда ике оешманы бергә кушу мәсьәләсе каралды. Фикер алышканнан соң, «идеология фронтында бер юлдан баручы пролетар оешмалар булганга» бу оешмалар «бүгеннән үк юк саналалар. Алар урынына яңа оештыру комиссиясе төзелә» дигән карар кабул ителде.

Сентябрь. Газеталарда татар алфавитын латин графикасы нигезендә үзгәртеп кору хакында иҗади бәхәс барды.

1 октябрь. Казанга А. В. Луначарский килде. Ул 2 октябрьда опера театрында «Тормышның мәгънәсе һәм бәхет нәрсәдә» дигән темага лекция сөйләде, 3 октябрьда шәһәр Советы пленумында халыкара хәл турында доклад белән чыкты.

1 октябрь. «Кызыл Татарстан» газетасында Хәсән Туфанның «СССРны таныйлар» исемле шигыре басылды.

Октябрь уртасы. Мәскәүдә партия Үзәк Комитеты янында татар-башкорт матбугаты турында киңәшмә булды. Татар-башкорт матбугатының торышы һәм бурычлары хакындагы доклад белән Г. Нигъмәти чыкты.

Октябрь уртасы. «Нәшрият кооперативы»нда «Ленин» исемле альбом басылып чыкты. Төзүчесе Габдулла Мохтар.

Октябрь. «Октябрь» түмәге тарафыннан хәзерләнгән «Ленин мәҗмугасы» исемле китап «Матбугат һәм нәшрият комбинаты»нда (Казан) басылып чыкты.

21 ноябрь. «Кызыл яшьләр» газетасында Әхмәт Исхакның «КИМ — паровоз» исемле шигыре басылып чыкты.

5 декабрь. «Кызыл яшьләр» газетасында Нур Баянның «Черек бүрәнәләр» исемле шигыре басылды.

Декабрь. һ. Такташ «Сыркыды авылы» исемле поэмасын тәмамлады.

1924 ел. Ш. Усмановның «Югалган грамота» исемле хикәяләр җыентыгы, Г. Ибраһимовның «Пролетариат әдәбияты турында» дигән китабы басылып чыкты.

——□——

*Рөстәм Башкуров*

# ҮТКӘН ЕЛНЫҢ ШИГЪРИ ТАВЫШЫ

*Рөстәм Шакир улы Башкуров танылган әдәбият галиме, талантлы тәнкыйтьче ид иде. Ул әдәбият фәнен үстерүгә лаеклы өлеш кертте, татар совет поэзиясенең актуаль мә мәсьәләләренә багышланган монографияләр, тирән эчтәлекле мәкаләләр язып калды дырды.*

*Рөстәм зур иҗат планнары белән яши иде. Әмма рәхимсез үлем аны безнең арада дан тартып алды. Каләмдәш дустыбызның инде тәгәлләнеп килә торган зур-зур хезмә мәтләре, күп санлы мәкалә-рецензияләре калды...*

*Әле февраль аенда гына — әдәби ел йомгакларына багышланган җыелышта — Рө Рөстәм Башкуров 1966 елгы поэзия турында доклад ясаган иде. Журналыбызның бу са санында укучыларга аның шул докладын тәкъдим итәбез.*

Тагын бер ел үтеп китте. Поэзиябез күп кенә әсәрләр, яңа исемнәр белән баеды. Газета-журнал битләрендә йөзләрчә шигырьләр дөнья күрде, егермегә якын шигъри җыентык басылып чыкты.

1966 елда басылып чыккан шигъри әсәрләргә караш ташлаганда, бер әйбер күзгә нык чалына: аларның авторлары — нигездә яшь һәм урта буын шагыйрьләр. Бу хәл хәзерге поэзиябезгә зур җаваплылык өсти һәм аның киләчәгенә дөрес, җитди карауны таләп итә. Эпик планлы шагыйрь С. Баттал, лирик җылылык бөркеп торучы С. Хәким, тормышны кайнап торган бәрелешләрдә чагылдыручы Ә. Давыдов, патетик моңсулык белән өртелгән Г. Хуҗиев әсәрләре һәм З. Нуриның шигъри публицистикасы белән беррәттән, монда романтик И. Юзеев, лирик М. Шабаев, тормыш табигыйлеген яратучан Г. Афзал, сатирик Ш. Галиев, самими С. Сөләйманова, драматик хисләр җырчысы Х. Камалов, һәр гади нәрсәдә югары кешелек күрүчән Р. Фәйзуллин, киңлекләргә омтылучан Р. Гатауллин, хикмәт сөючән Ш. Мәхмүдов, мәхәббәткә ашкынучан Ә. Баян кебек бик күпләрнең үзенчәлекле тавышларын ишетергә мөмкин. Поэзия өлкәсендә актив эшләп килүче шагыйрьләр саны, әлбәттә, моның белән генә чикләнми. Бу исемлеккә «Казан утлары»нда һәм газета-журнал битләрендә күренгән уннарча яшь шагыйрьләрне өстәргә мөмкин булыр иде.

Коммунистлар партиясенең XX съездыннан соңгы чор интеллектуаль лириканың,



уй-фикер шигыренең үсеп китүенә киң юл ачты, әдәбиятны киң карашлы, олы фикерле образлар галлереясы белән тулыландырды. Совет кешесенең рухи дөнья-

сындагы кичерешләрне, үзгәрешләрне, шәхес белән җәмгыять интереслары бердәмлеген үзендә туплаган әлеге герой — иҗади эш, кыю хыял, әхлакый янарыш һәм гуманистик омтылышлар герое ул. Ул герой бөтен җир йөзендә барган бәрелешләр, вакыйгалар үзәгендә тора, алар өчен үзен җаваплы сизә. Бу җаваплылыкны аңа Ватаны үти торган бөек эшләр йөкли, аның аңы, рухи дөньясы шушы эшләргә бәйләнештә байый, үсә. Элеккеге колонияләргә ярдәм кулын сузган Татарстан белән бергә, ул герой үз Ватаны, туган җире өчен «барлык-барлык парламентларда» (С. Хәким) сөйли алырлык горурлык белән яна.

1966 ел поэзиясен дә, гомумән, соңгы еллардагы татар поэзиясе кебек үк, тормышның катлаулы вакыйгаларын ачуга юнәлтелгән һәм максатлы фикер белән сугарылган колачлы лирик-философик шигырьләр бизи. Литва тәнкыйтьчесе Э. Кубилюс әйтмешли, аларга фикер энергиясе, ялкынлы ышаныч, барлык рухи көчләрнең югары накалыннан туган эмоциональлек хас. Бүгенге татар шагыйрьләренең күп кенә әсәрләре геройның тормышны оптимистик сиземләвен, аның бу тынгысыз дөньяда үз көчен, үз ролен нык аңлап эш итүен, тормышта барган бөтен вакыйгаларга мөнәсәбәте, бәйләнеше барлыгын чагылдыралар. Бу мөнәсәбәт һәм бәйләнешләр нигездә образлы ассоциацияләр аша биреләләр һәм үз нәүбәтендә бер хис, бер фикер, бер вакыйгага корылган поэзияне һич тә инкарь итмиләр. Алай гына да түгел, поэзиядәге бу агымнар бер-берсен тулыландыра, баета, киңәйтә киләләр.

Әдәбиятыбызның барометры булган «Казан утлары» журналының уңышлы шигъри сәхифәләрендә Ватан, кеше, шәхес һәм халык турында уйлану-борчылуларга нигезләнгән, заманның әһәмиятле әхлакый мәсьәләләрен яктыртырга омтылган лирик-философик әсәрләр матурлый. Мәсәлән, Г. Афзалның «Идел ага», «Язмышлар», «Бөтен дөнья каршында», Ә. Маликовның «Яндырылган хатлар», «Алда өр-яңа язлар» кебек әсәрләреннән тормышның гуманистик пульсы тибеп тора, тормышка, иҗат кешесенә кайнар мәхәббәт аңкый.

Шундый ук гыйбрәтле әсәрләр рәтенә яшь шагыйрьләрдән интеллектуаль поэзия тармагында иҗат итүче Р. Гатауллин, Р. Фәйзуллин шигырьләрен дә кертергә кирәк. Таушалган сурәтләрдән котылуны күздә тотып, алар үз иҗатларында милли-әдәби традицияләр белән хәзерге поэзия укышларын берләштерергә омтылалар, хәзерге яшь геройның әхлакый матурлыгын җырлыйлар. Ләкин шул ук вакытта аерым шигырьләрнең чиксез авырлаштырылуын, рационалистик характерда булуын да әйтеп үтәргә кирәк. Кайчак авторлар үз шигъри сукмакларында үзләре үк югалып та калалар. Ирекле шигырь фикернең үстерелешендәге искиткеч тыгызлыкны, киеренкелекне сораса да, вакыты белән поэзия урынына прозаизмга бирелү сизелә. Урыны белән ван, игътибарсыз фикерләр зур фәлсәфәгә дәгъва кылалар яки, киресенчә, гади бер фәлсәфә һәм гуманистик фикер ребус сыман катлаулы поэтик сурәт астына яшерелә. Әмма үзләренең уңышлы әсәрләрендә бу авторлар заманның сәнгатьчә зәвыкларын, рухын тоя алучы шагыйрьләр булып күз алдына киләләр. Тормыш детальләре һәм хисләр мондый шигырьләрдә сәнгатьчә ачыш булып яңгырыйлар һәм заманның олы идеяләрен гомумиләштерәләр. Тормыш, яшәү формаларын күзәткәндә, Р. Фәйзуллин микроскоп белән эш итсә, Р. Гатауллин телескопны ярата төшә. Һәр икесе дә, һичшиксез, кирәк нәрсә.

Совет кешесенең бай рухи дөньясын күп яклы итеп сурәтләүгә, аны героик тарих, заман һәм киләчәк белән бәйләнештә чагылдырырга омтылу узган елда татар поэзиясенең характерлы сыйфаты иде, дисәк — ялгыш булмас шикелле.

Бүгенге шигъри әсәрләрнең күпчелеге бик күп төрле тойгы һәм фикер борылышларын эченә ала. Аларда дөньякүләм кискен сыйнфый һәм әхлакый бәрелешләр дә, матурлык һәм караңгылык, яшәү һәм үлем антитезасы да, гуманизм белән кешелексезлек каршылыгы да, елмаю һәм каш җыеру да, тантана һәм сагыш та урын ала. Совет кешесенең бай акыл-хис дөньясын дөрес чагылдыру үзе шуны таләп итә. Күп очракта бер үк әсәрдә патетика белән реализм, драма белән романтика, лирика белән яхшы мәгънәсендәге риторика кушыла. Моның әйбәт мисалы, Һади Такташның «Киләчәккә хатлар»ыннан соң, Гали Хуҗиның сугыш елларында язылган «Россия» поэмасында күренеп үткән иде. Шушы кушылу, синтезлашу тенденциясе бүгенге татар поэзиясендә тагын да көчәйде. Моны поэмаларда аеруча нык сизәсең. Бу яктан Сибгат Хәкимнең «Үрләр аша» поэмасының 1966 елда басыл-

ган яңа варианты аеруча отышлы. Татарстан, Ватан, чор язмышы турында тирән фәлсәфи уйлануларга нигезләнеп язылган бу лирик поэма бик күп төрле эмоциональ-стилистик башлангычларны аерылгысыз итеп берләштерә алган. Сугышта ирен югалтып, хәзер ул үткән авыр юл аша Европага нефтепровод салучы Халидә кичерешләре сагышлы драматизм һәм җылы романтика белән сугарылган. «Европаның үзәгенә тикле зур эштә» катнашучы совет кешеләренең бөек бурычы турындагы фикер һәм хисләре җылы һәм шул вакытта киеренке лирик дулкында ага. Әсәрнең күтәренке публицистик рухы Карпат таулары аша еракларга сузылган дуслык, туганлык җепләренең какшамаслыгын җырлаганда көчле яңгыраш ала. Боларның һәммәсен әсәрнең тормышчан материалга һәм шул материал тудырган конкрет хис һәм фикерләргә бай булуы белән аңлатырга мөмкин. Һәм күп тавышлы, ягъни полифоник планда язылган әсәрләр өчен бу аеруча әһәмиятле. Поэмага чын мәгънәсендә тарихилык тойгысы хас. Бөек Ватан сугышы елларының тирән драматизмны бүгенге чор тормышының тынгысыз рухы белән аерылгысыз бәйләнгән һәм кешелекнең киләчәк язмышына килеп тоташкан. Бөек дуслык юлын салып, татар хатыны Халидә бара, Халидә белән бергә Татарстан бара. Шул рәвешчә, алар планетада барган тормышның, тарихның үзәгендә торалар. Татарстаннан сузылган нефть юлы Польшаның киләчәгенә кушыла, азат Германия дә аны үзенең тормыш тамыры итеп тоя. Халидәнең уй-хисләре поэманың яңа вариантында тагын да колачлырак төс ала, һәм шуңа нисбәтән герой үзе дә дөнья белән тирәнрәк бәйләнешкә керә.

Әсәрдәге поэтик детальләрнең подтексты һәм мәгънә сыешлыгы гаять тирән. Шунлыктан аларда конкрет хис белән фикер бердәмлеге аеруча күзгә ташлана. С. Хәким гади көнкүреш детальләре аша чорның зур фәлсәфәсен чагылдыруга ирешә. Җисемсез купшылыктан арына барып, көндәлек тормышны романтик күтәренке буяуларда сурәтләргә омтылуны Сибгат Хәкимдә генә түгел, поэзиябезгә җир җылылыгы алып килүче Г. Афзал һәм Ш. Галиев, тормыш ямена таң калучы С. Сөләйманова, романтик И. Юзеев, гадилектә поэзия күрүче Р. Гәрәй, яхшы мәгънәсендә патетикага тартым М. Шабаев, җир матурлыгыннан аерылгысыз гуманизмны байрак иткән Р. Гатауллин һәм Р. Фәйзуллин шигырьләрендә дә, кешe борчылуын тирән сизенләүче Х. Камалов әсәрләрендә дә, К. Булатова, Рәшит Әхмәтҗанов һәм Р. Мингалимовның кайбер психологик портретларында да тоеп була. Һичшиксез, бу момент поэзиябезнең күп төрле индивидуаль-стилистик тармакларында чагыла, дип әйтә алабыз.

Бу уңайдан Гали Хуҗиевның «Таныш күзләр, таныш карашлар» исемендәге шигырьләр циклын һәм М. Шабаевның Такташ иҗатындагы романтик сызыкка килеп тоташкан «Сине эзлим» поэмасын аерым искә алып үтәсе килә. Гали Хуҗиев лирик герой кичерешләре аша сугышта һәлак булганнарга мөраҗәгать итеп, бүгенге тормыш героикасының эчке мәгънәсен тыгыз итеп тасвирлауга ирешә. Бу — Гали Хуҗиевның яңа бер иҗади күтәрелеше дә иде. Марс Шабаевның лирик герое киеренке рух белән бүгенге тормыш матурлыгын раслап кына калмый, бәлки чорыбызның әле тарих булырга өлгермәгән драматик көннәр белән тирән бәйләнешен ача, героик традицияләрнең яшәүчәнлеген җырлый. Ватан сугышы чорында булып үткән трагик вакыйгалар аркылы герой бүгенге олы дөньяга чыга, шушы нигездә кешелек белән кыргыйлыкның, яшәү белән үлемнең, яктылык белән караңгылыкның килешмәүчәнлеген гәүдәләндерә. «Сине эзлим» поэмасындагы һәр шигъри детальнең, метафораның конкрет мәгънәсе, зур идеясе бар:

> Үләннәрдән чыклар күптән кипкән,
> Күзләрдән дә чыклар кипкәннәр.
> Кайда,
> Нинди үлән булып шыткан икән
> Кырык бердә чыгып китkәннәр? —

кебек, поэмада бик еш очрый торган мондый метафораларның тирән мәгънәгә ия булулары турында артык сөйләп торасы юк шикелле.

Яңа чор яңа эстетик таләпләр куя. Идеаллар, өметләр берсе артыннан берсе тормышка аша барган заманда исә шәхес белән җәмгыятьнең, субъектив һәм объектив факторларның бердәмлеге тагын да ныгый һәм тирәнәя. Болар поэзиянең тегe яки бу юнәлешенә дә үзгәреш кертми калмыйлар. Бу үзгәреш поэтик герой характерын гына түгел, сәнгать традицияләренең чикләрен дә киңәйтә һәм яңарта. Монда, мәсәлән, узган ел басылып чыккан кайбер уңышлы поэмаларга мөраҗәгать итү урынлы булыр иде. Хәзерге поэма, гомумән,

вакыйгаларны һәм кеше кичерешләрен иңасеннән җебенә кадәр сөйләп чыгу нигезендә түгел, ә карар күзгә аерым-аерым торган, бер-берсенә бәйләнмәгән местәкыйль шигъри әсәр булырдай кисәкләрне бергә ныгытучы идея җирлегендә формалаша. А. Твардовскийның «Ерактан ераккa», Э. Межелайтисның «Кеше», Р. Рождественскийның «XXX гасырга хат», Б. Ахмадуллинаның «Минем шәҗәрәм», Е. Евтушенконың «Братск ГЭСы» әнә шундый поэмалар рәтенә керәләр. Бу процесс соңгы еллардагы татар поэмасында да ачык күренә. С. Хәкимнең «Язгыз, җир уллары», Ә. Давыдовның «Чорлар чатында», «Себер трактында квартал», Ш. Галиевнең «Әткәйгә хат», М. Шабаев һәм И. Юзеев поэмалары әнә шундыйлар.

Илдар Юзеевның 1966 елда басылып чыккан поэмаларын алып карыйк. Боларда вакыйгалар тудырган хисләр күтәрелешенең иң киеренке, иң югары һәм бик күп төрле (лирик, эпик, драматик, патетик, юмористик һ. б.) агымнары берләшә һәм ирекле, әмма фикер белән оештырылган дулкыннары күзгә бәрелә. И. Юзеев поэмаларында әчпошыргыч, төссез сюжетлылык яки факт, конкрет күренеш колы булып калу юк диярлек, шагыйрьне беренче нәүбәттә геройның — совет чынбарлыгы тәрбияләп үстергән шәхеснең эчке, рухи үсеше һәм ныгуы кызыксындыра. «Миләүшә», «Таймас», «Өчәү чыктык ерак юлга» поэмалары вакыйгаларның, сюжет сызыкларының бик аз, әмма тегәл сайланып алынулары, кыскалык һәм шул ук вакытта панорамлылык белән аерылып торалар. Аларга геройларның рухи деньясын, кичерешләрен тирән һәм киң планда, төрле яссылыкта (лирик-интим, романтик-героик, драматик, патетик һ. б.) сурәтләүгә юнәлтелгән колачлылык һәм кыскалык хас. Дөрес, шагыйрьнең, боларны табигый итеп берләштерә алмыйча, прозаизмга, коры информациягә бирелеп киткән урыннары да юк түгел. «Миләүшә»дә романтик һәм комик башлангычларны берләштерә алмаган моментлар, «Таймас»та драма элементларын поэзиягә механик рәвештә китереп кушудан килеп туган риторик диалоглар, «Өчәү чыктык ерак юлга»да реалистик сызыкларның артык планга күчерелүе кебек фактлар әнә шуны күрсәтәләр. Әмма алар да шагыйрьнең уңышлы эзләнүләрен кимстә алмыйлар.

«Миләүшә» һәм аеруча «Таймас» поэмаларына драма элементлары, диалог килеп керә, аларны лирик чигенешләр, җырлар яки шигырьләр алмаштыра. Фикер һәм хиснең эзлекле үстерелеше беренче карашка эзлексез булып тоелган, әмма эчке логика белән берләштерелгән сурәтләргә, истәлекләргә, тарихка мөрәҗәгать итәргә киң юл ача, геройлар характерын төрле яклап чагылдырырга зур мөмкинлек тудыра. Болар барысы да, поэтик кинокадрларны хәтерләтеп, т о р м ы ш н ы, уйхисләр деньясын колачлап алырга ярдәм итеп кенә калмыйлар, әсәргә киң сулыш, киеренкелек өстиләр, шагыйрьгә вакыт һәм урын белән иркен эш итәргә юл ачалар. Моның калейдоскоп белән берниндиуртаклыгы юк. Чөнки әсәрнең һәр кисәге, һәр детале аңлы идея белән, бер үк эстетик җирлектә берләштерелгән.

Узган елгы татар поэзиясендә чагылып үткән мондый яңалыкны милли әдәбиятның һәм фольклорның яшәүчән традицияләрен уңышлы дәвам итү рәвешендә аңлаталар. Шул ук вакытта бу яңалыкны традицияләргә каршы куярга ярамый, әлбәттә. Монда тик поэзиянең төрле уңай традицияләр җирлегендә жанр һәм стиль ягыннан баюы гына күз алдында тотыла. Салих Батталның «Чирмешән буйларында» исемле романы — Октябрьга чаклы татар авылында сыйнфый бүленешнең кискенләшүен һәм крестьян массаларының революциягә килүен тасвирлаган киң эпик полотно. Шагыйрь иҗтимагый катлауларның көчәлгә сеңеп калырлык шигъри образларын тудырган. Халык поэзиясенә тартым итеп язылган бу әсәр җиңел һәм кызыксынып укыла. Ул чын мәгънәсендә канатлы, афористик гыйбарәләргә бай. Халык иҗатына хас детальләр ярдәмендә автор гади күренешләргә сәнгатьчә күп планлылык (юмор, сатира, драма) өсти торган юнәлеш бирә һәм ул детальләрнең яңа мөмкинлекләрен таба. Әмма халык юморын С. Баттал урыны белән поэтик материалдан чыгып файдаланмый. Шунлыктан халык массаларының, аерым геройларның революциягә барудагы авыр, драматик юллары кайчак җиңелчәрәк хәл ителә. Моңа әсәрнең икенче яртысында прозаизм, вакыйгаларны коры рифмага салып бару белән мавыгуны да өстәргә кирәк.

Ш. Галиевнең «Сөзгәк үгез маҗаралары» исемендәге сатирик поэмасын да 1966 елның шигъри казанышларыннан санарга кирәк. Әсәр халыкчан сатирага, юморга бай. Халык әкиятләре стилендәге сюжет шагыйрьгә сатирик гротеск туды-

руга бик нык ярдәм иткән. Поэмадагы озынга сузылган аерым картиналар һәм отмый торган строфалар гына аның гомуми әһәмиятен, билгеле, киметә алмыйлар.

Узган елгы поэзиянең зур гына уңышлары булган кебек, кимчелекле, йомшак яклары да бар, әлбәттә. Олы гражданлык хисләре, романтик күтәренкелек һәм тирән уйлану белән сугарылган поэзиянең киресе буларак, күңелгә шом салырлык тенденцияләр дә күзгә ташлана. Шуларның берсе — тар мәгънәсендәге субъективизм чире. Бу исә әсәрнең эчтәлегенә, идея юнәлешенә генә кагылып калмый, әдәби формалар дөньясына да үтеп керә. Бәлки, шагыйрьләргә киң иҗади эзләнү мөмкинлекләре ачылу белән бергә, аларда талапчәнлекнең кимүе нәтиҗәсендә туган бер чирдер бу. Поэзиягә яңалык алып килү я булмаса кеше күңелен җентекләп тикшерү урынына бары тик шигъри ялтырлыгы гына булган әсәрләр дә басылып чыкты. Мондый шигырьләр башлап язучылар иҗатында гына очраса, бер хәл иде. Алар формалашып җиткән талантлы шагыйрьләрдә дә күренә башлады. Узган ел «Бәхетне үзем табам» җыентыгында С. Сөләйманованың «Язылмаган җырлар» исемле поэмасы басылып чыкты. Бу әсәр мәхәббәт турындагы лирик монолог, уйлану һәм җырларны эченә алган шигырьләр циклын хәтерләтә. Ләкин алар барысы да тар интим, субъектив планда язылып, бер-берсен кабатлыйлар гына. Әсәрдә бөтен шигъри кисәкләрне берләштерүче идея-художество үзәге булмаган кебек, гуманистик югарылыкка күтәрелгән олы мәхәббәт тә юк. Кызганычка каршы, шагыйрәнең китап нәшриятына тапшырган яңа җыентыгында бу момент тагын да күпертелеп, шигъри табышмаклар формасына төреп бирелгән. Ә бит шул ук «Бәхетне үзем табам» җыентыгында «Машинада атлар», «Кыш үтмәгән әле», «Күзләреңдә», «Юлда», «Диңгез ярында» кебек, гади тормышның күп төрле чагылышларын нечкә шигъри сиземләү нәтиҗәсендә, аларның тирән мәгънәгә ия булуларын күрсәткән лирик-психологик шигырьләр дә аз түгел.

Әхсән Баяновның «Казан утлары» журналында һәм «Мәңге зәңгәр күгебез» җыентыгындагы шигырьләре арасында да җитлекмәгән мисалларны очратып була. Көчле риторик яңгырашлы, уңышлы әсәрләре («Зәңгәр күгебез», «Дөнья тәсле», «Язмыш ишек кага» һ. б.) белән бергә, бу шагыйрьнең артык сай фикерле, купшы, тар мәгънәле поэзиягә генә хас әсәрләре дә бар. Андыйлар шагыйрьнең бары тик үзе өчен генә язылганнар шикелле («Күпме йөрерсең син җилгә ташлап» һ. б.). «Сез аңларсыз мине» поэмасында Ә. Баянов артык бай булмаган тормыш тәҗрибәсенә фәлсәфи колачлылык бирергә омтыла. Әсәрнең лирик герое исә пьедесталга басып хөкем итүче оратор ролен алырга тели. Ләкин мондый герой яңа түгел инде. Ул тик 20 еллар поэзиясендәге шартлы, романтик гыйсьянчы геройның күләгәсе булып кына күз алдына килә.

Барлы-юклы тормыш тәҗрибәсенә, аеруча интим мәхәббәткә шигъри һәйкәл куярга омтылу белән мавыгу бездә еш очрый башлады. Клара Булатованың яхшы ук озынга сузылган аерым шигырьләре нигезсез өзгәләнү читлегеннән читкә чыкмыйлар. Шунлыктан, ахры, вак һәм тормыштан аерылган фәлсәфәгә акыллы тес бирү өчен, хәзер модага кергән ирекле шигырьдән табышмак ясау юлын тоталар. Моннан М. Шабаев, Р. Файзуллин, Р. Гатауллин кебек, үзләрен танытып өлгергән шагыйрьләр дә өстен тормыйлар әле.

Үткән ел поэзиясенең икенче кире тәэсире — торгынлык. Гади бер хәлне, күренешне сөйләп чыгудан ары узмаган, фикерсез һәм купшы сүзләрдән торган шигырьләр узган ел да күп урын алды. Мондый әсәрләр арасында Г. Афзал, С. Сөләйманова тәҗрибәләре генә («Өянкеләр моңы», «Бәхетне үзем табам» җыентыклары) яхшы яктан аерылып тордылар диярлек. К. Фәсаховның «Тамчылар» һәм «Ай кызы Зөһрә» кебек, колониаль илләрнең бәйсезлегенә һәм космосны яулап алуга багышланган легендаларында абстракт романтика, күп сүзлелек чире шулай ук үзенә законсыз хокук даулый башлады. Ә мондый ясалма легендаларның хокукы 30 нчы елларда ук беткән иде. Бу авыру Марс Шабаевның «Таш гасыр кыйссасы» дигән легендасына да йогып куйган. Традицион образлар шаукымына кайбер шагыйрьләр үзләре дә абайламастан бирелеп китәләр. Илдар Юзеевның хәзерге чор идеалларын символлаштырган яшь геройлары Такташның «Таң кызы» һ. б. шундый әсәрләрендәге шигъри пәрдәгә төренеп алалар, мелодраматизмга бирелеп куялар. Лирик аккордлар итеп алынган җилләр, таңнар һ. б. поэтик образлар белән дә шундый ук хәл. Халык җырлары мотивларын файдаланганда, әдәбиятта ачылган бер үк төрле мәгънәне шул килеш

кабатлаулар да аз түгел. Моннан берничә ел элек тормыш мәгънәсе, кеше язмышы, аның әхлакый йөзе турында киң таралган шигъри миниатюраларның, дүрт яки ике юллык хикмәтләрнең узган елда шактый сыеклана баруы күренә.

Ә. Ерикәйнең уйлану, тормыш тәҗрибәсен уртаклашу планында язылган парчалары да авторның үзе тирәсендә әйләнә. Ә. Давыдов, З. Нури һ. б. шагыйрьләрнең шигъри парча һәм эпиграммалары күп очракта «көлми дә, елмаймый да». Мондый шигырьләрнең, һаман-һаман диярлек, 12 шәр иҗекле традицион шигырь белән язылуы да чамадан ашты бугай. Бу уңайдан мәрхүм З. Мансурның «Этаплар китабы»нда тупланган бай мирасына күз ташлаганда да зыян итмәс иде. Г. Хәйямның дүрт юллык хикмәтләрен ул юкка гына тәрҗемә итмәгән. «Казан утлары» аларны бастырып чыгарып бик дөрес эшләгән.

Поэзиябезнең үсүенә комачаулый торган яклар турында сөйләгәндә, иҗади фикерләүнең пассивлыгына, поэтик культураның җитмәвенә дә игътибар итмичә булмый. Шушы сәбәптәндер, күрәсең, күп кенә шигъри детальләр шигырьдән шигырьгә яки шагыйрьдән шагыйрьгә күчеп йөри башладылар. К. Фәсәхов белән Ә. Сәлахетдинов «нур учмасы»на артык мәхәббәт белдерәләр. Ә. Давыдов һәм Ә. Баянов бер үк сюжет буенча бер үк эчтәлекле һәм бер үк характердагы шигырь язалар. Тик Ә. Баяновның героена 19 яшь, Ә. Давыдовныкына — 18 («Унтугыз яшь», «Сиңа ничә яшь? — дип сорыйсың син»). Э. Мөэминова, С. Шакир, К. Латыйпов һ. б. кайберәүләр, шигырь күләмен тутырыр өчен генә булса да, «һәм», «һәр көн», «һәр иртә», «һәр ел саен» кебек чөйләрне, русча әйткәндә, втычкаларны кирәкмәгән урынга кадаклап куялар. С. Шакир «йөрәктә — бигрәк тә» шинелле рифмаларны да аеруча хуп күрә бугай.

Китапчылык, әдәбичелек, үтелгән традицияләргә ябышып яту хәзер иң актуаль булган темаларны яңача үзләштерүдә дә үзен ачык сиздерә. Сүз монда беренче нәүбәттә рус һәм чит ил темаларына багышланган шигъри әсәрләр турында бара. Аларның күпчелеге 30 елларның икенче яртысында күп таралган шигырьләрдән аерылмыйлар. Самат Шакирның «Монда ул Байронның эзләре», «Бер мең торна», хәзерге Париж турында язылган «Тәрәзәдәге сүз», Маркс кызы Лаурага багышланган «Бөтен дөнья җырлар» кебек әсәрләре, Кави Латыйповның Джордано Бруно турындагы «Йолдызлар», «Овидий» кебек шигырьләре я коры информациягә, я булмаса китап аша кергән ярты-йорты мәгълүматка корылганнар. Аларда канатлы фикерне дә, конкрет геройны да табуы читен, бары тик купшылык кына бар. Бу шигырьләрдә заман рухына тапкыр килгән тирән гомумиләштерү юк. Алай гына да түгел, хәтта ул шигырьләрнең кайберләре турыдан-туры карикатура төсен алганнар:

Самат Шакирның «Есенин Тукайны укый» шигырендә исә тарихи дөреслеккә туры килми торган гына түгел, шарж дәрәҗәсендәге уйдырма булырлык сәер юллар да очрый:

Ул Тукайны укый. Тәрәзәдә
Урак ай да инде югалды.
Шагыйрь торды һәм шатланып әйтте,
Йолдызларга карап югары:
— Нинди зур һәм бөек шагыйрь Тукай!
Менә шулай кирәк язарга!

С. Есенинның, башка укучылар кебек үк, Тукайга булган олы мәхәббәтен шик астына алырга уйламыйбыз, әлбәттә. Ләкин икесе ике җирлектә туган һәм ике төрле бөеклектә торган ике талантны болай чагыштыру әдәби культураның җитмәвен күрсәтмиме икән? Бәлки алар, Кави Латыйповның «Женьшень эзлим»... шигырендәгечә, балаларга гына гафу итәргә мөмкин булган уй-хисләрдер:

Бала шикелле елыйм мин,
Шигырьләр язылмаса,
Атналар буе эзләгән
Сүз әгәр табылмаса.
Ял итим дип сүз бирсәм дә,
Көчем җитми түзәргә.
Женьшень эзләгәндәй чыгам
Кырга сүзләр эзләргә.

Поэзия үзе шаяруны ярата, әмма аның белән шаярганны гафу итә алмый. Чөнки ул — җитди эш. Примитивизм — аның дошманы. Кызганычка каршы, без аны һаман да шигырь бакчасыннан куып чыгара алганыбыз юк әле. Дөнья һәм кеше турында укучы белән көлепме, җитди итепме, ничек кенә булмасын, акыллы һәм гыйбрәтле итеп сөйләшә торган поэзия өчен керәшкән тәртибендә кала.

1966 елгы поэзия моның өчен җирлек тә бирә һәм бу турыда нык кына уйланырга урын да калдыра.

Без Бишенче елны бер кенне уяндык таң белән...
*Габдулла Тукай.*

# «ҖИЛКӘНСЕЗЛӘР» ҺӘМ АНЫҢ СӘХНӘ ТАРИХЫ

Беренче рус революциясенең шифалы җилләре тәэсирендә татар мәдәният дөньясына күп талант ияләре килде. Драматург, Татарстанның атказанган артисты Кәрим Гали улы Тинчурин шул талант ияләренең берсе һәм күренеклесе иде.

Башка замандашлары кебек үк, Кәрим Тинчурин да иҗат көчен төрле тармакларга бүлгәләргә мәҗбүр булды. Әмма мәдәниятның бер өлкәсендә ул аеруча яратып, күңел биреп эшләде. Бу — театр сәнгате. Ул сәләтле артист, булдыклы һәм эшлекле режиссер, тормыштагы мөһим, актуаль мәсьәләләрне күтәрә белүче, чор, заман сулышын тоеп иҗат итүче талантлы драматург иде.

Ул бик яхшы эшләнгән дистәләрчә образлар тудырды, татар драматургиясенең алтын фондына керерлек әсәрләр язып калдырды. Алай гына да түгел, ул татар драматургиясен яңа сыйфатлар белән баеткан, театр сәнгатен үстерүгә зур өлеш керткән классик әдип иде.

* * *

Татар буржуазиясенең, ул тәрбияләп үстергән интеллигенция һәм милләтчеләрнең чын йөзен ачу, иске татар тормышындагы һәртөрле бозыклыкны фашлау — Кәрим Тинчурин драматургиясендәге төп темаларның берсе, дияргә була. Аның бу темага багышланган дистәгә якын пьесасы бар. Шулар арасында иң уңышлысы, һичшиксез, «Җилкәнсезләр» комедиясе. «Җилкәнсезләр» бер Тинчурин иҗатында гына түгел, бөтен татар драматургиясендәге иң күренекле әсәрләр рәтеннән саналырга хаклы. Һәм 1925 елларда ук иҗат ителгән бу комедиянең бай сәхнә тарихы бар.

Комедиянең сигез пәрдәлек тәүге варианты беренче тапкыр 1926—27 елгы театр сезонында уйнала. Әсәрне сәхнәгә Тинчурин үзе куя. «Аумакайлар һәм җилкәнсезләр» исемле бу спектакль, кичке сигездә башланып, төнге икегә кадәр бара торган була. Шуңа да карамастан, тамашачы әсәрне яратып каршылый, спектакль уңыш казана. Мондый зур уңышка ирешүдә, драматург белән бергә, төп рольләрне башкаручы артистларның да өлеше аз булмый, билгеле. Спектакльдә татар сәхнәсенең танылган мастерлары катнаша. Мисбах хаҗины З. Солтанов, Нуретдин байны Н. Сакаев, Рокыяны Н. Арапова, Дилбәрне Ф. Ильская уйный. Әсәрдә сурәтләнгән тормыш, үзләре башкарырга тиешле геройларның чынбарлыктагы прототиплары белән якыннан таныш булган татар артистлары хәтердә калырлык һәм тамашачыны ышандырырлык образлар тудыралар. Спектакльне күргән кешеләр бу артистларның уены турында әле бүген дә сокланып сөйлиләр.

Тагын ике елдан спектакльнең яңа варианты эшләнә. Пәрдәләр саны дүрткә калдырыла, төп рольләрне башкаручы артистлар составы бөтенләй үзгәртелә. Ләкин Г. Девишев куйган бу спектакль уңыш казана алмый. Образлар күп тапкыр төссез чыга, әсәр салкын каршы алына, озакламый сәхнәдән бөтенләй төшеп үк кала.

1933 елда театр коллективы яңадан «Җилкәнсезләр»гә әйләнеп кайта. Сәхнәгә чыгарганда, әсәр кыскартыла, аңа күп кенә үзгәрешләр кертелә, соңгы пәрдә исә әр-яңадан кабат эшләнә. Беренче вариантында әсәр Батырханның акылдан язуы,

Давытның сәгать төзәтү мастерскоенда эшкә урнашуы белән тәмамлана иде. Бу юлы инде, советка каршы яшерен эш алып бару нияте белән, алар икесе дә идән астына күчәләр. Күп төрле төзәтмәләр һәм үзгәртүләр кертелүгә дә карамастан, «Җилкәнсезләр»нең өченче варианты да әллә ни зур уңыш казанмый.

* * *

РСФСРның һәм ТАССРның атказанган сәнгать эшлеклесе Ш. Сарымсаков куйган спектакль хакында күбрәк сөйләргә кирәктер, мөгаен. Тамашачыга әсәрнең төп рухын җиткерә алу ноктасыннан караганда да, драматургның иҗат үзенчәлекләрен ачу ягыннан да 1958 елгы спектакль арада иң уңышлысы шикелле.

Соңгы, дүртенче мәртәбә куйганда да әсәр шактый үзгәртелә. Комедиядә тасвирланган вакыйгаларның киеренкелеген, табигый агышын тагын да көчәйтү нияте белән режиссер өченче һәм дүртенче картиналарны берләштереп куя, финалга да байтак төзәтүләр кертә. Әсәр белән ныклап танышканнан соң, Ш. Сарымсаков шундый карарга килә: әсәрдәге вакыйгаларның үз логикасы буенча ук Батырхан үлемгә хөкем ителергә, Давыт исә, киресенчә, тагын да әшәкерәк, тагын да мәкерлерәк дошманга әйләнә барырга тиеш; менә шуның өчен дә соңгы күренештә Батырхан акылдан яза, Давыт идән астына күчә...

Билгеле булганча, әсәрдә беренче бөтендөнья сугышы елларыннан башлап Бөек Октябрь революциясе җиңгән көннәргә кадәрге чордагы тарихи вакыйгалар сурәтләнә. Иске Россияне нигездән үзгәрткән әлеге вакыйгалар фонында, һәр күренеш, һәр картина саен, татар буржуазиясенең, «милләт», «халык» дип лаф оручы интеллигентларның теләк-омтылышлары, планнары, чын йөзе ачыла бара. Юк, үзләрен милләт хадимнәре дип йөрүче бу мөгтәбәр кешеләр халык турында да, милләт турында да кайгыртмыйлар икән. Аларның кайгылары башкада: һәммәсе дә байлык артыннан куа, кесә калынайту юлларын эзли.

Менә беренче күренеш. Нуретдин байның кунак бүлмәсе. Стеналарда кыйммәтле рәсемнәр. Бүлмә гөлләргә, пальма агачларына күмелгән. Күпме җиһаз, күпме байлык бирелә. Әмма бу тормыш тышкы яктан гына шулай ипле, бөтен күренә. Йорт үзе дә, андагы тәртипләр дә эчтән инде җимерелеп, таркалып килә. Һавалы һәм үз-үзен бик акыллыга санап йөрүче тәкәббер Нуретдин бай, зур өметләр баглап, үз өенә Батырханны алып кайткан. Батырханга исә байның акчасы кирәк тә, чибәр кызы кирәк. Акча өчен заманында ул хәтта бөкре, гарип Рокыяга да өйләнергә риза булган.



*А. Хәйруллина Рокыя ролендә.*

Рокыя да шул ук изүчеләр сыйныфыннан, өстен катлауның бер вәкиле. Ләкин кимсетелгән, читкә кагылган вәкил. Нуретдин бай йортында аны кем дә якын итми, барысы да аннан көләләр, аны мыскыллыйлар. Чөнки ул гарип, ул бөкре. Шуңа да аның күңелендә үз кешеләренә карата бетмәс нәфрәт, тирән ачу хисләре туган. Бары тик акча, дәрәҗә артыннан гына куучы сатлык җаннарны, һәртөрле «ландрин тартмаларын» аның җене сөйми. Комедиядә Рокыя башкарган вазифа, бу образга автор тарафыннан йөкләнгән «бурыч»та шактый үзенчәлекле һәм кызыклы.

«Җилкәнсезләр» спектаклендә тамашачыны ышандырырлык, хәтердә калырлык уңай типлар юк диярлек. Ул чагында иске тормыш вәкилләре нинди чаралар, нинди алымнар ярдәмендә фаш ителә соң? Күп кенә башка чаралар белән беррәттән, бу эшне изүче сыйныфның үз вәкилләре: Мисбах хаҗилар, Рокыялар башкара. Татар



Х. Әбҗәлилов Мисбах хаҗи ролендә.



Г. Шамуков Нуретдин ролендә.

буржуазиясенең эшкә ашмас планнарыннан надан һәм саран Мисбах хаҗи да килә. Батырханнарны, Дилбәрләрне үзе бозыклык юлында йөрүче Мисбах та камчылый.

Шулай да йөкнең зурысы Рокыя образына салынган. Үз кешеләрен нәкъ менә Рокыя пран-заран китерә, ахырга кадәр нәкъ менә ул фаш итешә. Инде үз сыйныфы кешеләре дә шулай күрә алмый икән, димәк, советка каршы төрле мәкерле планнар корып азапланучы бу бәндәләр, чыннан да, җилкәнсезләр, аларның киләчәге, җирдә яшәргә хаклары юк.

Вакытында А. Хәйруллина Рокыя ролен искиткеч зур осталык белән башкарган иде. Шикләнми әйтергә мөмкин: ул тудырган образ тамашачы күңелендә әле озак вакытлар онытылмый сакланыр. Хәер, бу спектакльдә катнашкан башка артистлар үзе турында да шул ук сүзләрне әйтергә мөмкин.

СССРның халык артисты Хәлил ага Әбҗәлиловның Мисбах хаҗиын без әле бер генә тапкыр сагынып искә төшермәбез.

1958 елдан бирле Ф. Кульбарисов академия театры сәхнәсендә төрлесе төрле характердагы дистәләрчә уңышлы образлар тудырды. Ә менә «Җилкәнсезләр»дәге Батырхан образы исә, бу талантлы һәм үзенчәлекле артистның зур иҗат уңышы булып, театр тарихына кереп калды.

Шамуковның Нуретдин баен, Сәлимҗановның Зәйнетдинен, я булмаса Ш. Әсфәндиярованың Дилбәрен алыгыз! Аларның һәркайсы никадәр тормышчан, барысы да бүгенгә кадәр хәтердә сакланган.

Үзеннән-үзе аңлашылса кирәк, 1958 елгы спектакльне җәмәгатьчелек гаять җылы каршылады. «Җилкәнсезләр»нең яңадан сәхнәгә куелуы уңае белән, газета-журнал битләрендә күп санлы рецензияләр, мәкаләләр басылды. Ул мәкалә-рецензияләрдә режиссер хезмәтенә, артистлар уенына югары бәя бирелде. «Җилкәнсезләр» спектакле өчен Ш. Сарымсаков, художник Ә. Тумашев, артистлардан Х. Әбҗәлилов, Ф. Кульбарисов һәм А. Хәйруллина Тукай премиясенә лаек булдылар.

Шулай, күренекле драматургның классик әсәре татар сәхнәсендә тулы көченә яңгырый алды. «Казан сөлгесе», «Зәңгәр шәл», «Җилкәнсезләр» кебек үлмәс әсәрләр язган атаклы драматург Кәрим Тинчурин үзе исә безнең чордашыбыз, замандашыбыз булып яши башлады.

Х. КУМЫСНИКОВ,
сәнгать фәннәре кандидаты.

—□—

# УЙГУР ӘДӘБИЯТЫ СӘХИФӘЛӘРЕ

Уйгурлар — бай культуралы төрки халыкларның берсе. Борынгылыкта аларның бер өлеше Көньяк Себер, Алтай тирәләрендә яши һәм шунда көчле генә дәүләт булып оеша. Аннары (IX гасырда), көньяккарак елышып, алар хәзерге Торфан, Кочар, Хами, Яркэнд, Аксу, Кашгар тирәләрендәге (Көнбатыш Кытайда Шенҗан, ягъни Синцзян провинциясе) мөстәкыйль дәүләтле кардәшләренә кушылалар.

Культура, халыкара сәүдә мөнәсәбәтләре көчәю нәтиҗәсендә, уйгурлар тора-бара башка мәдәни халыклар белән тыгыз мөнәсәбәткә керәләр: берсеннән дин, икенчесеннән яңа һөнәр алалар һәм, алганнарын иҗади үзләштерсп, тагы да үстереп, нәүбәте белән, башка халыкларга да уңай тәэсир ясый башлыйлар. Безнең бабаларыбыз — болгар төркиләре һәм кыпчаклар да уйгур культурасының бәрәкәтле тәэсирен татыган халыклардан исәпләнә. Кайбер тарихи чыганаклар күрсәтүенчә, Идел буена килгән төрки кавемнәр арасында уйгур ыруглары да булган.

Шенҗан провинциясендә уйгурларның борынгы бабаларына караган гаҗәеп архитектура истәлекләре сакланган. Көнчыгыш Казагыстанда Җидесу өлкәсендә дә уйгурларга нисбәт ителә торган борынгы шәһәрлекләр[1] шактый табыла.

Язма хатирәләр өлкәсенә килсәк, биредә инде башка төрки халыкларның берсе дә уйгурлар белән ярыша алмый. Юридик документлар, дини, философик китаплар, әдәби әсәрләр, тирән эчтәлекле фәнни трактатлар — барсы да бар аларда. Менә шундый истәлекләрнең бер мисалы рәвешендә, Иосыф Хас Хаҗиб исемле мәшһүр әдипнең XI йөздә иҗат иткән «Котадгу билик» дигән зур күләмле поэтик әсәрен күрсәтергә мөмкин. Шундый ук мактаулы истәлекләрнең икенчесе — атаклы лингвист Мәхмүт Кашгариның «Диваны лөгать-әт-төрек» (XI гасыр) исемле энциклопедик хезмәте Урта гасырлардагы төрки телләрне, халык авыз иҗатының торышын өйрәнүчеләр өчен бу сүзлек — бетмәс-төкәнмәс хәзинә чыганагы. Хезмәттә ул чордагы барлык төрки телләр турында фактик мәгълүматлар тупланган.

Итил суы ака торур,
Кыя төби кака торур...—

дип башланган иң борынгы мәгълүм болгар җыры да Мәхмүт Кашгари хезмәтендә теркәлгән. «Диваны лөгать-әт-төрек», гәрчә ул, нигездә, сүзлек-грамматика булса да, андый искиткеч җырлар, хикмәтле мәкальләргә гаҗәп бай.

«Уйгур язуы» дип аталган әлифба да кешелек тарихында зур урын тота. Уйгурлар ул язуны борынгы согдлардан алалар, һәм, төрки телләргә бераз яраклаштыргач, башка кардәш кавемнәргә дә бирәләр. Ул язуны, тагын бераз үзләштереп, уйгурлардан монголлар һәм манҗурлар ала. Монгол империясе дәверендә исә уйгур язуының сферасы тагы да киңәя. Уйгур теле үзе дә халыкара дипломатик һәм рәсми телләрнең берсенә әверелә. Ул язу Алтын Урда дәүләтендә дә, аңар хәтле дә Идел буенда киң тарала. Алтын Урда язма истәлекләренең безгә килеп җиткән бер өлеше шул әлифба нигезендә язылган. Димәк, хәзерге татар әдәби теленең нигезе саналган Идел буе төркисенең формалашуында да уйгур культурасы һәм уйгур теленең роле бик зур. Мондый халыкның бай культурага һәм үзенчәлекле әдәбиятка ия булуы, әлбәттә, бик табигый.

Борынгы уйгурлар турында бик күп сөйләп булыр иде. Ләкин бурычыбыз — журнал укучыларын хәзерге көн уйгур әдәбияты үрнәкләре белән таныштыру. Шуңа күрә, бер сикереш ясап, максатка якынрак киләбез.

XVIII—XIX гасырлар уйгур халкының озын тарихында иң авыр, иң караңгы дәверләрнең берсе булды. Манҗур-кытай колонизаторларының шәфкатьсез изүләренә, илен сатып кәсеп итүче «милли» феодал бәкләрнең авантюралары өстәлеп торды. Дини фанатизм да халык рухының бугазына ябышты. Әмма гасырларга сузылган бу авыр сынаулардан уйгур халкы башын югары тотып үтте. Рухи ныклык, бай традицияле

[1] Борынгы заман шәһәрләренең урыннары.

культура һәм киләчәккә ышану, золым богауларын өзеп, яктыга, бәхетле тормышка таба омтылырга көч-куәт, ышаныч бирде. Билал Назыйм, Сәетмөхәммәт Кашый, Садыр-пәһлеван кебек узган гасыр талант ияләренең тормыш һәм иҗат эшчәнлекләре моны тулысынча раслады.

Соңгы шагыйрьнең, Салават Юлай шикелле, милли һәм социаль азатлык көрәшенә җитәкчелек итүе аерым игътибарга лаек. Ничә мәртәбә кулга төшеп, ничә мәртәбә төрмәдән качкан, тагын көрәш юлына баскан Садыр-батыр көр, горур тавыш белән җырлады:

...Зинданда озак ятып,
Башым бер кочак булды,
Мин зинданны тишкәндә
Кабыргам пычак булды...

Ат мендем көрән кашка,
Сикерттем таштан-ташка,
Гаскәрләр атар ташка,
Ә Садыр атар башка...

Бала-чагам ерак калды,
Кычкырсам да, тавыш җитмәс;
Курку белмәс гайрәтем бар, —
Башым юкка әрәм китмәс.

Бу инде — феодализм чорының мистик язма әдәбиятына каршы куелган халыкчан әдәбият, көрәш поэзиясе. Һәм иске әдәбиятка каршы көрәшендә Садыр ялгыз түгел иде. Ул халык иҗатына, аның көчле рухына таянды.

Үз нәүбәтендә, Садыр кебек ирләр тәэсирендә, халык җырчылары да социаль мотивларны күтәреп чыгалар. Хезмәт ияләре үзләренең авыр хәлен, алда торган киртәләрне, социаль тигезсезлекне яхшы күрәләр. Җырларда халыкның үз көченә ышанычы да ачык әйтелә:

Кара болытлар өстемдә,
Дошман йөридер артымда;
Үз-үземә тугры булсам, —
Дошман аяк астында.

Әгәр реакцион шагыйрьләр «алла гыйшкы», хур кызлары турында авыз суы корытып, мәгънәсез хыял сазлыгына батсалар, гади уйгур дөньяви мәхәббәт, реаль «кара каш» турында җырлады; аны мактады, аңа упкәләде. Инде вакыты җитеп, сабыр савыты тулса, кайнар канлы уйгур йөрәге ут булып кабынып китте:

Аһ орырмын, аһ орырмын,
Аһларым тотсын сине,
Күз яшьләрем дәрья булып,
Балыкларын йотсын сине!

Шушы дүрт кенә юллык бер җырда купме дәрт һәм хис, никадәрле шигъри камиллек! Андый энҗеләр уйгур халык әдәбиятында санап бетергесез...

Уйгур әдәбияты безнең дәвергә менә шушындый тирән эчтәлекле, камил формалы бай әдәби мирас белән килде. Октябрь сулышы белән борынгы халык яңадан яшәрде, аның олы традицияле бай әдәбияты да икенче яшьлек дәверенә күчте. Илле ел эчендә уйгур совет әдәбияты һәм уйгур совет культурасы танымаслык булып үзгәрде [1].

Без уйгур совет әдәбиятының бүгенге хәле турында озаклап сөйләп тормыйбыз. Сүз шул әдәбиятның үз вәкилләренә бирелә. Тик шуны искәртәсе килә: түбәндә китерелгән үрнәкләр генә бөтен бер әдәбиятны тулы рәвештә күз алдына бастыра алмаслар, билгеле. Шулай итеп, сезнең алда, кадерле укучылар, күл-дәрьядан тамчылар, бакчаларыннан бөртекләр генә.

**М. ГОСМАНОВ.**

——□——

[1] Биредә сүз бары СССРда яшәүче уйгурлар турында бара. Ә аларның төп һәм зур өлеше, югарыда әйтелгәнчә, Кытай дәүләте составына керә. Андагы уйгур әдәбиятының узгандагы бер вәкиле Л. Моталлиб иҗатыннан үрнәкләр «Совет әдәбияты» журналының 1961 ел 1 санында бирелгән иде. Ләкин Шенҗаңда яшәүче уйгурларның бу көнге әдәбияты, культурасы турында, кызганычка каршы, яңа мәгълүматлар тәкъдим итә алмыйбыз. Чөнки соңгы елларда Кытайда хөкем сөреп торган башбаштаклык, шовинизм политикасы нәтиҗәсендә, башка аз санлы милләтләр белән бергә, уйгурлар да тышкы дөньядан изоляцияләнде.

*С. Моллаудов, Г. Сәгъдеваккасов*
филология фәннәре кандидаты.

# Татар һәм уйгурлар арасында культура мөнәсәбәтләре тарихыннан

...Узган кырык биш ел эчендә[1] Татарстан АССР экономика һәм культура өлкәләрендә тарихта мисалы күренмәгән уңышларга иреште. Коммунистлар партиясе, Совет хөкүмәтенең җитәкчелеге һәм кайгыртучанлыгы нәтиҗәсендә, татар халкы, кыска гына вакыт эчендә гасырлар буе хөкем сөреп килгән торгынлыкны җиңеп, чәчәк аткан республика төзеде.

Соңгы елларда Татарстан промышленносте бик нык күтәрелде, Лениногорск, Әлмәт, Зеленодольск, Баулы, Урыссу, Азнакай һ. б. кебек яңа типтагы шәһәрләр, шулай ук эшче поселоклары үсеп чыкты...

Рус һәм башка тугандаш халыкларныкы кебек үк, татар халкының да формасы белән милли, эчтәлеге буенча социалистик культурасы төрле яктан камилләшеп, элек бер дә күрелмәгән биеклекләргә күтәрелде...

Татарстандагы дистәләгән гыйльми-тикшеренү институтлары дәүләт өчен файдалы фәнни проблемалар өстендә эшлиләр.

Республикада театрлар, китапханәләр, культура сарайлары, музейлар, кинотеатрлар, радиоузеллар һәм башка шуның кебек культура учакларының саннары елдан-ел арта бара.

Совет чорында татар халкы арасыннан күпләгән галимнәр, язучышагыйрьләр, драматурглар, композиторлар, рәссамнар җитлегеп чыкты. Татар халкының талантлы каһарман улы Муса Җәлил иҗат иткән әсәрләр бөек ватаныбыздагы һәм демократик илләрдәге күпләгән милләтләр теленә тәрҗемә ителде. Композиторлардан Нәҗип Җиһанов әсәрләре һәм Фәрит Яруллинның «Шүрәле» балеты бөтен дөньяга мәшһүр.

Бер мәсьәләгә биредә махсус тукталып үтәргә кирәк. Уйгур халкының тарихы белән этнографиясен, теле белән язма әдәбиятын һәм халык авыз иҗатын өйрәнүдә Татарстан башкаласы Казан шәһәренең роле аерата зур булды. 1804 елда ачылган Казан университеты галимнәренең шәрыкны өйрәнү өлкәсендәге гыйльми хезмәтләре, Россиядә генә түгел, бөтен алдынгы Европага танылып, тарихи әһәмияткә ия булдылар. Казан университеты профессорларыннан А. Казим-бекнең уйгурлар хакында язган китап һәм мәкаләләре, XIX йөзнең беренче яртысыннан башлап, даими рәвештә, бер-бер артлы татар халкының үзәк шәһәрендә басылып килде.

Рус ориенталистларыннан В. Григорьев, Н. Катанов, Н. Пантусов һәм башка танылган галимнәрнең уйгурларны өйрәнүгә багышланган хезмәтләре дә шул ук Казанда дөньяга чыктылар. Уйгур классик әдәбиятының мәшһүр вәкиле Билал Назыймның «Газат дәр мөлке Чин»

---

[1] ТАССР төзелүгә 45 ел тулу мөнәсәбәте белән язылган бу мәкалә «Коммунизм тугы» (Коммунизм байрагы) газетасының 1965 елгы 28 май санында басылган иде. Без аны әз генә кыскартып бирәбез. (Бу һәм башка искәрмәләр безнеке — М. Г.).

(Кытай илендә изге сугыш) исемле китабы, «Чанмуза Йосыфхан» дигән дастаны һәм «Нәзугум» повесте, патриот уйгур шагыйре Сәетмөхәммәт Кашыйның «Шәрхе шикәстә» (Кайгы-хәсрәт бәяны) дастаны, уйгур тарихчысы Муса Сәйраминың «Тарихы әмания» исемле зур хезмәте һәм Корбангали Халидинең «Тарихы җаридәи җәдидә» (Яңа тарих сәхифәләре), «Тәварихы хәмсәи шәркыя» (Биш шәрык иленең тарихы) кебек китаплары шул ук Казанда нәшер ителеп, Россиядәге халыклар арасында киң таралдылар [1]. Билал һәм Кашыйларның күп кенә әсәрләре, рус теленә тәрҗемә ителеп, шунда ук дөньяга чыктылар.

Октябрь революциясенә кадәр татар телендә чыгып килгән газета-журналларда да уйгурлар тормышына караган материаллар шактый күп басыла иде. Бигрәк тә татар сәяхәтчеләренең Шәркый Төркестанга ясаган сәфәрләреннән алган тәэсиратларына багышланган материаллар күп була иде. Сүз уңаенда «Шура» журналының бу өлкәдә күрсәткән зур хезмәтен махсус тәкъдир итеп узарга кирәк. Бу журнал сәхифәләрендә татар ориенталисты Нәүширван Яушевның эчтәлекле һәм әһәмиятләрен бүген дә югалтмаган мәкаләләренә киң урын бирелде. Н. Яушев революциягә хәтле Шәркый Төркестанга сәяхәт ясап, уйгур фольклоры һәм этнографиясе буенча гаҗәп бай материал җыеп кайтты. Шул материаллар нигезендә «Шура» битләрендә мәкаләләр сериясе бастырды. Ләкин, кызганычка каршы, бу яшь галим тарафыннан җыелган материалларның зур өлеше дөньяга чыкмый калдылар: Н. Яушев Октябрь революциясе алдыннан вафат булды [2].

«Шура» журналы уйгур укымышлыларының хезмәтләренә дә урын бирен торды. Уйгур шагыйре Назархуҗа Габдесаматов шул журнал битләре аша үз иленең культурасы белән башка тугандаш халыкларны таныштырып килде.

Бөек Октябрь социалистик революциясе булгач, халыклар тормышында бөтенләй яңа дәвер башланды. Бу олы үзгәрештән соң ватаныбыз халыклары арасында культура мөнәсәбәтләре тагын да тыгызланып, янә дә нәтиҗәлерәк булды.

Татар һәм уйгурлар арасында культура бәйләнешләре революциядән соң нигездә өч өлкә: мәгариф, матбугат һәм әдәбият буенча үстеләр.

XX гасыр башларында, билгеле тарихи шартлар нәтиҗәсендә, татар культурасы үсеше, башка төрки халыкларныкына караганда, күзгә күренерлек дәрәҗәдә югары иде. Шуңа күрә дә күпләгән татар мөгаллимнәре, Урта Азия һәм Казагыстандагы халыклар арасына килеп, мәктәпләр ачтылар, балалар укытып, гасырлар буе хөкем сөреп килгән наданлыкны җуюга күп көч куйдылар. Авылларда башлангыч белем күргән уйгур яшьләре Алма-Ата һәм Ташкент шәһәрләренә килеп, татарлар тарафыннан оештырылган уку йортларында тәгълим-тәрбия алдылар.

---

[1] Татар тарихчысы Корбангали Халиди Казагыстанда Аягуз шәһәрендә сәүдәгәр гаиләсендә туган (елы хәзергә билгесез). Аның атасы Халид Казан өязе Орнабаш авылы кешесе була. Семипалатинск шәһәрендә мәдрәсә тәмамлагач, Корбангали Чүгәчәк шәһәрендә уйгурлар арасында яши һәм 1913 елда шунда вафат була. Аның шәрык халыклары тарихына багышланган хезмәтләре үзе тарафыннан җыелган сирәк материалларга — беренче кул чыганакларга бай булуы белән фәнни әһәмиятләрен бүген дә югалтмаганнар.

[2] Нәүширван Яушев Уфа губернасы, Бәләбәй өязе, Ментал авылында ярлы дворян — «чабаталы морза» семьясында туа; авылда башлангыч белем алгач, Уфада «Галия» мәдрәсәсендә укый. 1913—17 елларда үз инициативасы белән Урта һәм Үзәк Азия илләренә сәяхәткә китә, Ташкент, Сәмәрканд, Бохара, Андижан һәм Кытайдагы Кашгар, Яркәнд, Хутан кебек шәһәрләрдә була. Һиндстанга да җыена, ләкин Февраль революциясе җилләре аны ватанына чакыра. Туган иленә кайтышлый 1917 елның 10 ноябрендә Ташкент шәһәрендә үпкә авыруыннан үлә. «Шура», «Вакыт»лардан тыш, «Сәмәрканд», «Аўинә», «Сәдаи Төркестан», «Сәдаи Фәргана» газеталарында да аның күп сандагы мәкаләләре басыла.

Татар халкының уллары уйгур матбугатының үсешенә дә шактый зур өлеш кертте. 1918 елны Алма-Атада чыга башлаган «Сәдаи таранчы» (таранчы тавышы) исемле газетаның редакторы Зариф Бәшири иде. Ул Алма-Ата һәм Яркәнт шәһәрләрендә озак вакытлар яшәп, уйгурлар арасында эшләде...

Егерменче еллардан алып, уйгур язучыларының иҗади үсүләренә Г. Тукай, М. Гафури, Һ. Такташ, Г. Ибраһимов һәм башка татар әдипләренең әсәрләре сизелерлек дәрәҗәдә тәэсир кыла башлады. Уйгур язучыларыннан А. Мөхәммәди, Г. Мөхәммәди, Һ. Искәндәров, Н. Исраиловлар татар мәктәпләрендә укыдылар, аларның иҗатларына Тукай һәм Такташ поэзияләренең тәэсире аеруча зур булды. Бу шагыйрьләрнең шигърият трибунасына күтәрелә алу юллары хакында сөйләгән чакта, татар поэзиясе ролен тәкъдир белән телгә алу бик урынлы булыр.

28 яшендә вафат булган талантлы шагыйребез Исмәгыйл Саттаров Г. Тукай, Һ. Такташлардан өйрәнде. Соңгы вакытларда шагыйрь архивында Һ. Такташның «Киләчәккә хатлар» поэмасының тәрҗемәсе табылган иде. Ул 1962 елда «Коммунизм туглы» газетасында басылып чыкты.

Татар әдипләренең күпләгән әсәрләре, уйгур теленә тәрҗемә ителеп, киң җәмәгатьчелегебезгә ирешеп өлгерде инде. Г. Ибраһимовның «Кызыл чәчәкләр» әсәре 1935 елда аерым китап булып басылды; «Тирән тамырлар» романының күп кенә бүлекләре 30 елларда ук уйгур әдәбияты дәреслекләренә кертелгән иде. Габдулла Тукайның «Шигырьләр һәм дастаннар», М. Гафуриның «Шигырьләр» дигән китаплары, Г. Бәшировның «Намус» романы һәм башка татар язучылары әсәрләре уйгур телендә үз укучыларын тапты. Шулай ук «Коммунизм тугы» газетасы битләрендә Гадел Кутуйның «Тапшырылмаган хатлар» әсәре, Муса Җәлилнең күпләгән шигырьләре басылды.

Бөек Ватан сугышы елларында вафат булган Советлар Союзы Герое, Ленин премиясе лауреаты Муса Җәлил, шулай ук Фатих Кәрим һәм Гадел Кутуй, Нур Баян һәм Х. Мөҗәй кебек батырларның татарлар өчен зур мактаныч булуын уйгур халкы яхшы белә.

Хәзерге уйгур тел белеме мәсьәләләренең фәнни хәл кылынуларында татар галимнәре актив катнашалар. Ф. Г. Исхаков, Әмир Нәҗип, Э. Р. Тенишев, Ү. Байчура һәм башкаларның гыйльми эзләнүләре уйгур филологиясенең үсешенә зур өлеш кертте.

Совет дәверендә чын мәгънәсендәге прогресс юлына баскан татар халкына, аның данлы бәйрәме мөнәсәбәте белән, уйгур туганнары ялкынлы сәлам юллый һәм татар хезмәт ияләренә аның коммунизм төзү эшендәге фидакарьлек хезмәтләре мул нәтиҗәле булуына чын күңелдән теләктәшлек белдерә.

—□—

*Һәзим Искәндәров*

## Ак каеннар

Кемне болай көттегез, ак каеннар,
Тезелешеп мин кайтасы юлларда?
Теләдегез кемне каршы алырга
Туңып, сыкрап кышкы салкын буранда.

Әллә мине көттегезме яд итеп,
«Бу юллардан элек бик күп үткән», дип,
Кырау төшеп үзәкләргә тигәндә
Әйттегезме «Шагыйрь кая киткән», дип?

Дус-ишләрнең кулын кыстым тагын да,
Җиһан гизеп кире кайткач бу якка;
Ана кочагына кергән сабыйдай,
Сыендым мин тагын сезнең кочакка.

## Китмәнем

Чокыр-чакыр кырларны
Тигезлидер китмәнем,
Тау-ташларны актарып
Җир эзлидер китмәнем.

Армыйм-талмыйм — без бергә,
Юлдашым син, китмәнем.
Сине авыр эшемдә
Таянычым иткәнмен.

Син кулымда булганга
Уңыш бирә иккәнем.
Дала, чүлләр сугарам
Синең белән, китмәнем.

*Илья Бәхтия*

## Бакчачы

Бакчачының кулында
Буламыни энәсе?
Энә алып такмый ул
Өзелсә дә төймәсе.

Ертылса да күлмәге
Аптырашта калмый ул...
Китмән аның энәсе, —
Җир ертыгын ямый ул.

●

Бәлки,
Бәхетле итү кулымнан килмәс.
Ләкин
Бәхетле булсаң, мин каршы түгел.
Бәлки,
Бәхет дигәнең һавадан иңмәс,
Ләкин
Бәхетсез үлү ир эше түгел!

*Хәлил Һәмраев*

## Көтүче кыз

Тау итәгендә көтү —
Күктән болыт төшкәндәй;
Кузгалып китсә көтү —
Күктә болыт күчкәндәй.

Кыя ташның өстендә
Кызыл гөл тора көлеп,
Гөл түгел, көтүче кыз,
Басып тора гөл кебек.

Кулларында курае,
Кураенда моңнары,
Моңнарыннан җанлана
Таулар, үзән буйлары...

Шул кыз белән дуслашып
Тауларда куйлар баксаң,
Эх, йоклаган чагында
Курай чалып уятсаң...

## Мәхәббәт һәм җырларым

Кояш җирдән ерак булса да бик
Нурларыннан җылына бар хәят.
Буыннардан күчеп буыннарга
Шул кояштай яши мәхәббәт.

Шуның кебек туган илгә булган
Сөю хисе җылыта күңелне.
Ләззәт тапса халкым җырларымнан
Шигырьләрем булыр гомерле.

*Насыйр Хәсән*

## Үз анамсың...

Үз анамсың,
Исемең йөртәм йөрәгемдә,
һәр сүземдә, һәр җырлаган җырымда син.
Мәрхәмәтле, мәхәббәтле газиз анам,
һәр адымым, һәрбер сулышым — тынымда
син.

Үз анамсың —
Кадерләүчем, кайгыртучым,
Кочагыңда күзем ачып дөнья күрдем.
Үз анамсың — күз карам син, таянычым —
Ярдәмеңдә бәхет, ирек тәмен белдем.

Үз анамсың,
«Балам», диеп зур тормышка
Өмет белән юллаганың чыкмый истән.
Синең өчен сулар, утлар кичсәм дә мин,
Белмим, сиңа бурычым төшәр микән
өстән?!

# *Мәзәкләр*

*Хуҗа Насретдинны һәр халык үз кешесе дип саный. Шул бер Хуҗаны үзбәк — үзбәккә, таҗик — таҗикка, татар исә татарга тарта. Төрек белән кыргыз да, каракалпак белән төркмән дә читтә калучылардан түгел. Ә безнеңчә, Хуҗа — чеп-чи уйгур кешесе. Уйгурлар аны, бер сүз белән генә, хөрмәтләп, «Әфәндем» дип йөртәләр. Урдә һәм кырда, мәчет-базарда, үлем һәм туйда аңар төрдән урын бирәләр. Ышанмасагыз, түбәндәге мәзәкләрне укыгыз!*

## Уңган сәтраш

Бер сәтраш, Әфәнденең чәчен алган чакта, аның башын кискәләп бетерә дә җәрәхәтләренә мамык ябыштырып чыга. Әфәндем, көзгегә карагач, сөенеп әйтә:

— Һи, остам, кулың алтын икән, ярты башыма мамык үстереп бирдең бит! Калган өлешенә үзем борчак сибәрмен инде!

## Йокы качыру

Ахшам намазыннан соң, имам вәгазен тыңлап утырган чакта, Әфәнде хырылдап йоклап китә. Күршесе, бөеренә төртеп, ачулана башлый:

— Хырылдап йокларга оялмыйсыңмыни?

Әфәнде, күзләрен уып:

— Йокламыйм, хырылдап йокы качырам, — ди.

## Акылсыз кәвеш

Әфәнде, бер елга буена килеп, тәһарәт алырга керешә. Шунда бер кәвеше суга төшеп агып китә. Әлеге хәлгә кәефсезләнеп торганда, бер кеше килеп:

— Һи тәкъсир, өр-яңа кәвешегезнең берсе әрәм булган икән, ярар кайгырмагыз инде, — ди.

— Юк ла, нинди кайгыру, — ди Әфәнде кулын селтәп, — әгәр аның акылы булса, үзенең кадерле юлдашын ташлап китмәс иде бит!

## Ашыгыч хат

Бер туйга Әфәндене чакырмыйлар. Ләкин ул аптырап калмый. Бер кисәк ак кәгазьне дүрткә бөкләп конвертка сала да, туй ясаучы кешегә илтеп: «Моны сезгә казый хәзрәтләре җибәрде», — ди. Теге сөенеп Әфәндене түргә утырта, Әфәнде исә шунда ук табынга житешә башлый.

Туй хуҗасы тышка чыгып конвертны ача да, аптырап Әфәнде янына килә:

— Әфәндем, конвертта ак кәгазьдән гайри бер нәрсә дә юк бит!

— Дөрес, дөрес, — ди Әфәнде, — бик ашыгыч булгач, казый хәзрәтләре хатны язып өлгертмәде шул.

## Куркып әйттем...

Бер көнне Әфәнде мәхәллә имамын кунакка чакыра. Тege, табынга утыру белән, «моны ашау сөннәт, бусы да сөннәт» дип, әдәп-фәлән саклап тормыйча, ура башлый. Имамның нәкәслегеннән кәефе кырылып утырган чакта, өйгә Әфәндене улы килеп керә.

— Бу улыңмы, Әфәндем? — дип сорый имам.

— Әйе, тәкъсир, улым, — ди Әфәнде.

— Исеме ничек?

— Фарыз.

Имам гаҗәпләнә:

— «Фарыз» дигән исем буламыни?

— Дөрес, тәкъсир, — ди Әфәнде. — Аның чын исеме Сөннәт иде, ләкин сез ашап куймасын дип куркып, «Фарыз» дип әйттем.

## Уйгур халык мәкальләре

Алга барган чакта артыңа да кара.
Ат урнына ишәк бәйләмиләр.
Ахмакның олысы-кечесе юк.
Бодай ипиең булмаса, бодай телең юкмыни.
Дошман нәрсә димәс, төшкә ниләр кермәс.
Заман төзәлсә, яман да төзәлер.
Ил кузгалса, тәхет селкенер.
Илдә абруең булса, чүлдә йөгең калмас.
Карарсыз инсан — вафасыз буран.
Нәсихәт ачы, җимеше татлы.
Син бүрене аясаң, бүре сине талар.
Тәмугка күнеккән җәннәткә түзмәс.
Утыз тештән чыккан сүз утыз илгә тарала.
Уразаны мин тоттым, гаетен байлар йотты.
Юлбарысны җиңгән батыр түгел, ачуны җиңгән батыр.
Яхшы илнең баласы һәлак булыр, кол булмас.
Яхшы эт үләксәсен күрсәтмәс.
Үзе өчен йоклаган, кеше өчен төш күрмәс.

*И. Катиев*

*Бу әсәрне Бөек Октябрь революциясенең 50 еллыгына, революция елларында авыл кулаклары тарафыннан, вәхшиләрчә үтерелгән апам К. Х. га багышлыйм.*

# ЯЛКЫН

## Драма бер пәрдәдә

**КАТНАШАЛАР:**

Җ а м а л — яшь укытучы.
К ә б и р — кызыл командир.
С а ф а — авыл кулагы.
Х ө р м и — аның улы.
Г ы й м а й — Сафаның хезмәтчесе.
Ә с м а — аның хатыны.
Х и с а м и — ялланган кулак.
Кызылармеец.

Вакыйга 1919 елның көз айларында Зәй елгасы буена урнашкан авылларның берсендә бара.

Урам. Таш келәтнең бер өлеше күренеп тора. Төн. Багана башындагы фонарьда ут яна. Көзге салкын җил сызгыра. Суыктан бөрешкән Гыймай, шакылдыгын шакылдатып, аксый-аксый үтеп китә. Як-ягына карана-карана Хөрми керә. Тәмәке кабыза. Бер-ике суыра да төкереп ташлый.

Х ө р м и *(әкрен)*. Гыймай бабай! Гыймай бабай, дим! Ай, саңгырау чучка. *(Кычкырып.)* Гыймай...

Г ы й м а й *(керә)*. Әү, әү, ишетәм. Нәрсә бар, энем?

Х ө р м и. Бер аягыңны атлаганчы икенчесен эт ашый, кәкре сыйрак.

Г ы й м а й *(кимсенеп)*. Әйе шул, кәкре. Атаң...

Х ө р м и *(кискен)*. Җитте! Һаман бер балык башын чәйнәмиләр. Күп сөйләсәң, мин икенчесен сындырырмын.

Г ы й м а й. Анысын күтәргә була синнән.

Х ө р м и. Җитәр диләр сиңа. Тыңла!

Г ы й м а й. Тыңлыйм, энем, тыңлыйм.

Х ө р м и *(каранып)*. Үтүче-сүтүче булмадымы?

Г ы й м а й. Хәзергә юк, энем.

Х ө р м и. Кара аны, Гыймай бабай, бик уяу бул. Бүген осубый төн.

Г ы й м а й *(шикләнеп)*. Нәрсә, әллә тагын килергә тиешләрме?

Хөрми. Килеп нәрсә? Аласын алып бетерделәр инде. Кичә теге кыска чәч командасы килеп актык ярмаларны да тазартып китте. Хәзер безгә нәрсә, фәкать үч, үч алырга гына калды. Ыштансыз калдырды бу комун халкы. Җитмәсә, кәнтәй эттәй, комсомол булып алып, аларга яшьләр иярә. *(Ачулы.)* Кыска чәч, сасык... Ничево, безнең урамда да бәйрәм булыр әле. Кичә Кодашта арт сабакларын укыттылар бит инде. *(Китә, кире килеп.)* Кара аны, уяу бул!

Гыймай. Ярый, ярый, энем Хөрми.

Хөрми. Хөрми түгел. Хөрмәтулла. Җыен ыштансыз, Хөрми — эшең хөрти дип, көлә башлады. Кара аны, кем үтсә дә белеп кал. Бигрәк тә хатын-кызлар затын. Ишеттеңме? *(Чыга.)*

Гыймай. Ишеттем, ишеттем, энем. *(Карап кала.)* Сезнең урамның бәйрәме бетеп бара шул, энем Хөрми. Чыннан да, сезнең эшләр хөрти. Бер көн тормас идем каһәр сукканнарда. Баш төртер урының булмагач, кая барасың соң. Ярлы көнең ялыныч шул. Теленне аркылы тешләп булса да түзәсең. *(Авыр сулап.)* Һи, һи, һи. *(Уйланып.)* Тукта әле, нәрсә болар бүген бик сырланалар әле. Үтүче юкмы, уяу бул, теге дә бу. Урам булгач, үтүче дә булыр, китүче дә булыр. Урам кин сыярлар. *(Шакылдатып китмәкче була, туктап кала.)* Әй, кем бар анда?

Җамал *(арттан).* Мин, кеше.

Гыймай. Кеше икәнеңне күрәм, кем дим?

Җамал *(кергә, ул җылы киенгән, шәл ябынган).* Мин ул, Гыймай бабай. Әллә шүрләдеңме?

Гыймай. Шүрләвен шүрләмәдем, ни... Эшең булгач, ни эшлисең?

Җамал. Сафа байның бу таш келәтен күтәреп китмәсләр әле.

Гыймай. Кушкач ни эшләмәк кирәк. Ә син болай бик соң кая җыендың? Җитмәсә, салкын. Елгада сулар туңган.

Җамал. Ә кар күренми әле.

Гыймай. Коры суыклар. Синең урында булсам, Шәмсенисаның мич башыннан төшмәс идем. Ә син...

Җамал. Эш күп, бабай.

Гыймай. Беләм, беләм. Төнлә сагалыйбыз, көндез талыйбыз диген.

Җамал. Дөрес түгел, Гыймай бабай, таламыйбыз, ә конфисковать итәбез. Армиягә озатабыз, ятимнәргә бирәбез.

Гыймай. Сезнеңчә кәнфис, безнеңчә талау... Оялырга кирәк, кайсы кыз бала шулай йөри.

Җамал. Нигә тузынасың, Гыймай бабай?

Гыймай. Юк эшләргә катнашып йөрисең, кызым. Шул мәктәп дигәннәрендә мөгаллимлегеңне кылсаң, сиңа шул җиткән. Нигә ул сиңа кәмсәмул, нигә ул сиңа...

Җамал. Нәрсә, Гыймай бабай, баеңны кызганасыңмы әллә?

Гыймай. Сине кызганам. Күпләрне харап иттеләр бит мәлгуньнәр.

Җамал. Бүредән курыксаң, урманга барма, диләрме әле.

Гыймай. Болар бит бүредән дә хәтәр ерткычлар. Күрәсең, тиз генә бирешәселәре килми мөртәтләрнең. Сәнәк булса да күтәрәләр. Харап итүләре бар. Үзең өчен әйтүем.

Җамал. Борчылма, Гыймай бабай, теләсә нинди ерткычны авызлыкларбыз, тешен сындырырбыз.

Гыймай. Кичә Кодашта сындырдылар инде, кырдылар. Буең җитмәсә, үрелмә диләр. Көчең җитмәгәч, нигә тотынырга. Бу Чәйков әтерәтен әйтәм. Күпме кеше харап булды, мәсхәрәләнде. Я, хода...

Җамал. Кичә алар өстенлек алган икән, бүген безнекеләр... Чуйков аларга күрсәтер әле. Арт сабакларын укытыр. *(Китә башлый.)* Хуш...

Г ы й м а й *(Жамалга якын килә, як-ягына карана).* Нәрсә, әллә бүген килергә тиешләрме? *(Жамал эндәшми.)* Курыкма, мин сатлык жан түгел.

Ж а м а л. Бүген булмаса, иртәгә килерләр. Барыбер килерләр.

Г ы й м а й. Әйтәм бит, тикмәгә төнлә йөрмисең син. *(Ымлап.)* Монда да нәрсәгәдер ыгы-зыгы киләләр. Әллә мин әйтәм...

Ж а м а л. Безгә дә йокларга ярамый.

Г ы й м а й. Анысы шулай. Тик бу кәкре сыйрак белән ерак китеп булмый шул.

Ж а м а л. Әй, Гыймай бабай, йөрәк кирәк, йөрәк. Аягың, тумыштанмы?

Г ы й м а й. Юк, язмыштан. Утыз елга якын намуслы хезмәтем өчен Сафа бай бүләге.

Ж а м а л. Ни өчен?

Г ы й м а й. Әй, кызым, сөйләсәң, бер гомер дигәндәй... Жир тырмалаганда бер тырма теше сындырган өчен. Вәлүк белән китереп сукты. Күрәсең, кәкре ялганды. Мин күргәнне эт тә күрмәс. Слабуда дидек, рәвәлутсия дидек... Мин һаман да элекке Гыймай булып калдым. Бер көн тормас идем каһәр суккырында.

Ж а м а л. Китәргә кирәк.

Г ы й м а й. Кая? Шул сасы мал өеннән куып чыгармаса, шөкер ит инде.

Әсма керә. Кулында төргәк.

Ә с м а. Һи, мин сине ашарга керер дип көтәм тагы... Ә син бирердә маржалар белән сөйләшеп...

Г ы й м а й *(катгый).* Карчык!..

Ә с м а. Нигә? Барысы да чәчен кистергән, имансыз урыс маржасы диләр бит.

Г ы й м а й *(ачуланып).* Ә син кеше сүзен сөйләмә. *(Жамалга.)* Син үпкәли күрмә, кызым, аның бераз житми...

Ә с м а. Синеке бик житә. Синең кебек ирләр таш пулатта торалар. Син гомерең буе шушы Сафа байның сасы мал өен сакладың.

Г ы й м а й. Ни эшлим соң, карчык. Бәхетем шулайдыр инде.

Ә с м а *(табын әзерли).* Бәхет, бәхет... Юк, булмады шул. Кил, карткаем, капкалап ал. Ходай шушы чикмәнле ризыктан аермасын.

Г ы й м а й. Кил, кызым, безнең белән...

Ж а м а л. Юк, юк! Рәхмәт сезгә. Хушыгыз.

Г ы й м а й. Хәерле юл, кызым. Бигайбә алайса.

Ж а м а л. Нинди гаеп, ди ул. *(Пауза.)* Ә син, Гыймай бабай, иртәгә безнең ячейкага кереп чык әле. Шунда сөйләшербез.

Ә с м а. Йөресен мона. Сафа икенче аягын сугып сындырыр.

Ж а м а л. Кулы кыска... Көтәрмен.

Г ы й м а й. Һи, кызым, миннән нәрсә? Бер тарыдан бутка булмый дигәндәй...

Ж а м а л. Ә очкыннан ялкын була. *(Китә.)*

Г ы й м а й. Һай, һай, чая кыз. Ничек сөйләшә.

Ә с м а. Аның теле тегермән тартыр, ул шуның өчен укыган. Фатир карчыгы Шәмсениса әйтә: «Бик уңган, бик булган», ди. Мактап сөйли. *(Караныл.)* Кайбер төннәрдә янына бер кызыл кәмәндир килгәли икән. Пышын-пышын бик озак сөйләшәләр, ди.

Г ы й м а й. Тсс... карчык, кешегә сөйләнә күрмә.

Ә с м а. Шәмсениса да кешегә әйтмә дип, сер итеп кенә сөйләде. Юк, юк, аллам сакласын.

Г ы й м а й. Ә менә мина сөйләдең.

Ә с м а. Әй, син кешемени, картым ич.

Г ы й м а й. Бәлки, мин кунтырдыр...

Э с м а. Авызыңнан җил алсын. Юкларны такылдама. *(Пауза.)* Карт, дим, сиңа әйтәм, әллә мин әйтәм, берәр уйнашы-фәлән микән, дим.

Г ы й м а й *(ачуланып)*. Юкны сөйләмә. Андый балага охшамаган. *(Уйланып.)* Нәрсә диде әле ул? Очкыннан ялкын була, диме? Очкыннан — ялкын. Һе, хикмәтле сүз әйтте бит әле бу бала, карчык.

Э с м а. Я, я, юк белән башыңны ватма. Синең белән минем башка менә шушы бәрәңге... Кил, утыр!

Г ы й м а й. Иртәгә янына кергәч, сорашырмын әле. *(Агач төбенә әзерләнгән табынга килеп утыра.)* Бисмиллаирахманирахим... *(Бәрәңге алып каба.)*

Ашыгып Хөрми керә.

Х ө р м и. Үгүче-сутүче юкмы?

Г ы й м а й *(сүзен әйтә алмый тора)*. Һо-һо, һо...

Х ө р м и. Тапкансың тыгынып утырыр вакыт. *(Савыт белән бәрәңгене тибеп җибәрә.)* Бирән корсак.

Г ы й м а й *(каушап)*. Ни... ни... Э... юк, юк. Күрмәдем, энем.

Х ө р м и. Аягыңны сындырганчы, күзеңне чыгарыр идем мин синең. Әле яңа гына кем үтеп китте?

Г ы й м а й. Билләһи...

Э с м а. Ант итмә, карт, гөнаһлы...

Г ы й м а й *(ачулы)*. Ирләр сүзенә катышма. Бәрәңгеңне җый. Ни... эттер ул, энем, эттер. Бая Шарик үтеп киткән иде.

Х ө р м и. Тфү... син үзең эт! Сукыр тавык. *(Җамал киткән якка чыга.)*

Э с м а. Ай, затсыз, ризыкка типкән өчен аягың корсыры. Юньле кеше балалары солдатта. Олакмый да, ичмасам. *(Бәрәңгеләрне алъяпкычы белән сөрткәли.)* Кил, карт, капкалап ал. Пичтә тәгәрәтеп пешергән бәрәңгегә бернәрсә дә булмый аңа.

Г ы й м а й *(борчулы)*. Бар, карчык, син китеп тор әле. Әнә тегендә кемнәрдер күзгә чалынды. Болар юньле хәл белән йөрмиләр.

Э с м а. Карт, нигә бая алдаштың? Үтте бит.

Г ы й м а й. Бар, бар, ычкын. Кемнәрдер йөри. *(Шакылдатып, Эсма белән икәү чыгып китәләр.)*

Келәт буеннан ышыкланып, бик саклык белән Сафа һәм Хисами керә.

С а ф а. Әкрен, Хисами. Хәзер теге тыкрыкка чыгабыз...

Х и с а м и. Әллә нигә, Сафа абзый, күңелем тартмый.

С а ф а. Чыпчык йөрәк булма. Капчык белән бауны миңа бир. *(Пычак бирә.)* Мә! Һөҗүм була-нитә калса, каушап калма, айка.

Х и с а м и. Гомеремдә кеше суйганым юк.

С а ф а. Өйрәнерсең. *(Ашыгып Хөрми керә.)* Я, нәрсә?

Х ө р м и. Ячәйкә бүлмәсендә ут бар. Тәрәзәдән карадым. Кәгазьләр актарып утыра.

С а ф а. Үзе генәме?

Х ө р м и. Үзе генә.

С а ф а. Алайса, иншалла озакламас. Ычкындырырга ярамый. Ныклап карадыңмы, үзе идеме?

Х ө р м и. Үзе инде, үзе, кыска чәчле.

С а ф а. Киттек. Мә, капчыкны син ал. Бик тиз томала. Әйдә, Хисами.

Х и с а м и. Әллә нигә, Сафа абзый...

С а ф а. Җебемә. Тагы өстәрмен... Тиз бул! *(Китәләр.)*

Г ы й м а й *(керә)*. Нәрсә эшләргә йөриләр болар, урлашыргамы? Шулайдыр, капчыклары да бар. *(Уйланып.)* Әллә теге баланы...

Әсма *(керә)*. Пичтә тәгәрәтеп пешергән бәрәңге бераз суынгач бик тәмле була. Кабыгы үзе әрчелеп тора, кил, карт...

Гыймай *(борчылып)*. Туктале син, карчык. Монда бер-бер шомлы эш килеп чыкмагае.

Әсма *(әкрен)*. Нәрсә булды, карт?

Гыймай. Болар нәрсәгәдер чыж-пыж йөриләр.

Әсма. Ниндидер кешеләр дә килде. Хәмер дә капкаңнар, ахрысы.

Гыймай *(борчылып)*. Ни эшләргә соң, ни эшләргә?

Әсма. Нәрсә эшлисең, синең билгеле инде, шакылдата бир.

Гыймай. Менә монда йөрәк шакылдый башлады әле, карчык.

Әсма. Әй, синен үлгән йөрәгеңә..

Гыймай. Үлгән? Юк, карчык, ниндидер ялкын кабынды аңар хәзер.

Әсма. Берүк, карткаем, юк эшләргә тыгылып йөри күрмә. Бәлагә калырсың. Кадалып китсеннәр.

Гыймай. Юк, алай түгел ул, карчык. Житәр... *(каранып.)* Кемнәрдер килә. Бар, карчык, сыпыр. Минем хәлне белеп тор!

Әсма. Ярар. Ә бәрәңген?

Гыймай. Киләләр. Бар, бар, кит!

Әсма китә. Гыймай яшеренеп күзәтә. Башына капчык кигертелгән, куллары бәйләнгән Жамалны Сафа, Хөрми, Хисами эткәләп-төрткәләп алып киләләр.

Сафа *(бауның бер очы белән сугып)*. Мә, ләгънәт! Кыска чәчле урыс марҗасы. Юк, безнең кулдан җиңел генә котыла алмассың.

Хисами *(гайрәтләнгән булып пычак белән)*. Ни эшләтим мин бу имансызны, Сафа абзый, айкыйммы?

Сафа *(аны тотып)*. Ахмак! Җиңел генә озатырга... Юк. Талап ашаган икмәкләрен костырам әле мин аның. Хисами, капчыгын салдыр, авызын чиш.

Хисами Җамалның башыннан капчыкны салдыра, авызын чишә. Җамалның кыска кара чәчләре тузган. Сафа, биленә таянып, Җамал каршысына килеп бася.

Сафа. Я, ничек, чучка токымы? Байның икмәге тәмлеме, камчысы тәмлеме? *(Тешләрен кысып.)* Һем... Камун эте... *(Җамалның чәчләрен тарта)*.

Җамал *(Сафаның битенә төкерә)*. Кабахәт!

Хөрми *(һөҗүм итеп)*. Син, сасы марҗа, минем этигә...

Сафа *(аны тотып)*. Юк, тимә! *(Битен сөртә.)* Ул җәзасын башкача алыр. *(Мәкерле көлеп.)* Янача яшәргә тели, кеше талап туклана. Минем йөрәгемә сауган кан синең җаныңны алгач кына тынычланыр.

Җамал. Кеше үтереп кенә пычрак-бозык канын чистармас. Ул канны агызырлар, агызырлар!

Сафа. Җитте, чучка танау! Хисами, бар, башкаларга әйт. Әзерли башласыннар. Зәй күпләрне йотты, бу марҗаны гына йотар. Әнә шунда инде митинкәләреңне бакаларга ясарсың. *(Көлә.)* Бар, Хисами!

Хисами китә.

Җамал. Ә сезне җир йотар! Ул көн ерак түгел инде, йотар!

Хөрми. Нәрсә такылдатып торырга бу сасыкны. Әти, ни эшләтим?

Сафа *(мәкерле елмаеп)*. Хәзергә келәткә ябып куярбыз. Аннан соң болтыйк... *(Җамалны төрткәләп.)* Әйдә, атла, ана кәнтәй! Үткән көннәреңне уйлап, бераз ләззәтлән.

Җамал *(горур)*. Юк, аның киләчәге матур булачак!

Алып чыгып китәләр. Ишек ачкан тавышлар ишетелә.

Гыймай *(качып торган җиреннән чыга)*. Я хода, нинди эш бу? Харап итәләр бит баланы. Карчык кая китеп югалды соң? *(Китә.)*

Сафа (*кερə, бармагын авызына кабып-кабып ала*). Эттән туган нәрсә, бармагымны ишеккә кыстым. Ярый, бераз җилләнеп алсын, аннан коендырырбыз. Бар, кара анда кыймылдыйлармы?

Хөрми (*китә, кире борылып*). Әти, кая бир әле ачкычларны?

Сафа. Ни пычагыма ул сиңа?

Хөрми. Анысы минем эш.

Сафа. Юк, бирмим! (*Китә башлый.*)

Хөрми (*каршы төшә*). Бирәсең!

Сафа. Юк белән пычранма.

Хөрми. Анда синең эшең юк. Бир!

Сафа. Бирмим.

Хөрми. Нигә шул марҗаны кызганасың. Асравыңны кызганмагансың бит.

Сафа (*уңайсызланып*). Тфу, җир бит! Кайчангыларны лыгырдый бит. (*Ачкычларны атып бәрә.*) Әнә, кадал!

Хөрми (*ачкычларны алып, алар белән уйнап*). Кадал түгел, «Изге эшкә салават», — диләр, картлач.

Сафа. Югал, юньсез!

Хөрми. Оҗмах ачкычлары безнең кулда, хәзер китсәк тә була. (*Китә.*)

Сафа. Тфу, җир бит! Кемгә охшап тугандыр.

Гыймай (*шакылдатып үтеп бара*). Алма агачыннан ерак төшми инде ул.

Сафа (*кәефле*). Әй, Гыймай абзый! Кил әле монда. Кил әле, кил!

Гыймай (*шакылдатып килә*). Нәрсә бар?

Сафа. Ташла әле шул тукмагыңны. Кулыңа кистән ал, кистән. Бу нәрсә...

Гыймай. Мин бит бүре куарга бармыйм, кистән белән ни эшлим?

Сафа. Кистән белән нишлиләрме? (*Гыймайның башына сугып.*) Бәрәләр. Менә шулай... Ха-ха-ха...

Гыймай. Миннән булмый.

Сафа. Өйрәнерсең. Бир әле шакмагыңны, аның урыны чүплек башы. (*Китә.*)

Гыймай. Ходаем, бу минем башымны әллә нинди бәлаләргә урап бетермәсә ярый инде. Я, хода...

Сафа (*керә, кулында кистән*) Мә, тот әле, Гыймай абзый! Курыкма, менә шулай бер генә бәр. (*Сугып күрсәтә.*) Бу заманда коралсыз ярамый.

Гыймай. Әй, миңа кем тисен. Бу чикмәнгә кызыксыннармы?

Сафа. Ашыкма. Менә кызыл этләрне куып җибәрсәк, иске кама туным синеке. (*Кесәсеннән акча алып.*) Мә, монысы бүгенге уңышлар өчен. Кара аны, күз-колак бул. Бу тирәдә берәү дә чуалмасын. (*Келәткә карап тора да мыегын сыпыргалап чыгып китә.*)

Гыймай (*озатып кала*). Ул тун миңа эләкмәс шул. Бер дә кинәргә охшамагансыз. (*Каранып, иплән кенә рәшәткәле тәрәзә янына килә, әкрен.*) Кызым, кызым! Син исәнме?

Җамал (*эчтән, калтыранган тавыш белән*). Исән... Гыймай бабай, зинһар, мине тыңла.

Гыймай. Әйт, кызым.

Җамал. Минем сиңа зур гозерем бар. Зинһар, үтә!

Гыймай (*каранып*). Сөйлә тизрәк, нәрсә?

Җамал. Кәбир дигән егетне беләсеңме?

Гыймай (*уйлап*). Бер дә хәтерләмим. Кем ул? Кем малае?

Җамал. Безнең комсомолец. Тау буе Гариф малае.

Гыймай. Ә, белдем, белдем... Гарифҗанның теге заводларда, шахталарда йөргән зимагуры. Ут егет ул. Я, әйт!

Җамал. Зинһар, шуларга барып әйт...

Гыймай. Юк, юк, кызым. Пусны ташлап беркая да китә алмыйм. Булмый.

Җамал. Зинһар, Гыймай бабай, бик кирәк.

Гыймай. Анысын аңлыйм... Сафа белсә... Алла сакласын... *(карапып.)* Тсс... Кемдер йөри.

Әсма *(керә).* Бу хәлләр дөресме, карт?

Гыймай. Тсс... Әкрен! Бик вакытлы килеп җиттең, карчык. Сиңа баевой эш, карчык.

Әсма. Нинди, нинди эш?

Гыймай. Әмер. Күп сөйләшергә вакыт юк. Кил, колагыңны шунда куй. *(Тәрәзә янына илып килә.)* Кызым, сөйлә!

Җамал. Әби җаным, хәзер үк тау буе Гарифҗаннарга барып, Кәбиргә әйт: хәзер үк ат атланып Бөгелмә юлы буендагы түгәрәк имәнлеккә чапсын. Анда Бөгелмәдән килгән Кәбир отряды булырга тиеш. *(Гыймайга.)* Бабай, кеше-фәлән юкмы?

Гыймай *(тирә-якны күзәтә).* Тынычлык, кызым.

Җамал. Әйтсен, таңны көтеп тормасыннар. Хәзер үк кузгалсыннар. Минем хәлне үзең аңлатырсың. Кем дип сорасалар, «Яулык» дисен. Онытма, «Яулык», аңладыңмы?

Әсма *(икеләнеп).* Аңлавын аңладым...

Гыймай *(җитди).* Икеләнеп торыр чак түгел, бу сиңа баянный эш. Пунәтнеме? Бар, бар, карчык тизрәк атла, һәр минуты кадерле.

Әсма. Син дә әйткәч, атасы, тагы да аңладым. Киттем генә. *(Кызу гына чыгып китә.)*

Гыймай. Менә шулай, карчык, малатчина. Булды, кызым. Димәк, килергә тиеш иделәр?

Җамал. Әйе. Мин шуларны каршы алырга дип уйлаган идем. Менә бит ничек... *(калтыранып.)* Ах, салкын. Пальтом да анда калды. Тышка чыккан җиремнән эләктереп алдылар бит, кабахәтләр.

Гыймай. Карчык та китте. Нишләргә соң? *(Уйланып.)* Ә тукта, миңа чурт та булмас. *(Чикмәнен сала. Карап.)* Монда да шул кырык тишек. Кызым, мә! *(Тәрәзәдән тыга.)* Чикмән-чикмән булыр әле ул. Төренерсең. Тарт! Менә шулай. Вәт, мөртәтләр, нәрсә кыланалар бит.

Артта Хөрминең җырлавы ишетелә.

Тсс... Киләләр!

Ары киткән, бире киткән
Бирск калалары.
Комсомолга язылалар
Ырыстан балалары.

Гыймай. Ай, бүре бугаз. Үз башыңа улагыры.

Хөрми *(керә, кызмача).* Һа, Гыймай бабай, тешләр тешкә тимиме?

Гыймай. Миңа ни... Түзәргә була. Тик менә бу бала кызганыч. Иртәгә кадәр катып үлүе бар.

Хөрми. Үлсә соң, барыбер үләсе. Бер комсомол чукынганнан чурт та булмас. *(Ачкычлар чыгара.)* Әзрәк кетекләсәң җылына ул. Мин аны... *(Келәткә килә башлый.)*

Гыймай. Тукта! Кая барасың?

Хөрми *(Гыймайга якын килә).* Син, картлач, тик кенә тор, мин үзем беләм. Әзрәк ни... кети-кети...

Гыймай. Кит, оятсыз! Кыз баланы мыскыл итәргә уйлыйсыңмы? Хәзер разбуй салам.

Хөрми *(пычак күрсәтә).* Менә моны күрәсеңме? Тележне кисәрмен. *(Керә башлый.)*

Гыймай *(аркылы төшә)*. Якын киләсе булма. Менә бу кистәнне атаң тикмәгә тоттырмады.

Хөрми *(ачулы)*. Юлыма аркылы торма. Бер-ике сәгатьтән барыбер җәһәннәмгә...

Гыймай. Я, хода. Ул бит яңа шытып килә торган чәчкә генә лабаса.

Хөрми. Менә шуңа күрә чәчкә көе су төбендә эрәм булмасын. *(Кузгала.)*

Гыймай. Кит-кит, якын килмә! Атаңа әйтәм.

Хөрми. Ул минә ачкычларны үзе бирде. Кит, буталма!

Гыймай. *(Кычкыра)*. Әй, кайсыгыз...

Хөрми *(аның авызын каплый, бер читкә өстерәп алып китеп, эченә бик каты тибә. Гыймай тәгәрәп китә, һушсыз ята. Хөрми келәткә керә. Сөйләшүләр ишетелә)*. Нихәл, тутый кош?

Җамал. Кит, кабахәт, якын киләсе булма!

Хөрми. Юләрләнмә. Әп итәм генә.

Җамал. Кит!

Хөрми. Китмәсәм нәрсә?

Җамал. Бугазыңны чәйнәрмен.

Хөрми. Тешең үтмәс.

Җамал. Кагылма! *(Кычкыра.)* Гыймай бабай!

Гыймай ыңгыраша, тора алмый, келәткә таба шуыша. Җамал йөгереп келәттән чыга, Хөрми аны эләктереп ала, кочаклый. Җамал аның кулын тешли.

Хөрми. Ох, әле син шулаймы? Кешене тере килеш ашыйсыңмы? *(Пычак белән кадый.)* Мә, алайса!

Җамал. Аһ.. *(җиргә ава.)*

Гыймай *(көч-хәл белән тора)*. Ах, имансыз икәнсең.

Хөрми каушап шашып кала. Ат тоягы тавышлары. Ашыгып Кәбир керә.

Кәбир. Кайда, кайда ул минем Җамалым?

Хөрми качарга тели.

Гыймай. Тот, тот аны! Ул аны...

Кәбир. Стой! Атам! *(Ата.)*

Гыймай. Мәчтер икәнсең. Җәһәннәм аңа...

Кәбир. Кая ул?

Гыймай *(караңгылыкта яткан Җамалны күрсәтә)*. Әнә ул, бичара...

Кәбир *(Җамал янына килә, аны күтәреп ала)*. Җамал! Җамал бәгырем, нәрсә булды сиңа? Ни эшләттеләр сине? *(Карап.)* Ах, кадаганнар. *(Җайлап яткыра.)* Җамал, Җамал, бу мин — Кәбир. Бер генә ач күзеңне...

Җамал *(авыр ыңгырашып)*. Кәбир... Кәбир җаным, синме...

Кәбир. Мин, мин, Җамал...

Җамал *(авыр, хәлсез)*. Соңгарак калдың шууу-ул... Онытма, үч ал... *(Үлә.)*

Кәбир. Җамал, Җамал! Ник йомдың күзеңне? Җамал... *(Гәүдәсенә башын куя.)* Аерылышуыбыз шушы микәнни? Бабай, үлде бит, үлде...

Гыймай *(чүгәләп дога кыла)*. Урыны оҗмахта булсын.

Артта ат тоягы тавышлары. Кызылармеец керә.

Кызылармеец. Иптәш командир, отряд килеп җитте. Сезнең әмерне көтәбез.

Кәбир *(башын күтәрә)*. Тсс... *(Аңына килеп.)* Әмер? Ә, әйе, әйе.. Үч алырга. Кодаш ягындагы отряд белән кушылганчы, камап алырга.

Кулак Сафаны тере килеш... Үтәгез, мин хәзер! *(Кызылармеец китә.)* Бабай! Хәзергә Җамалны кая булса да...

Г ы й м а й *(келәтне күрсәтә).* Шушыннан да тыныч урын булмас.

К ә б и р *(кесәсеннән чиккән яулык алып, Җамалның битенә каплый.)* Бу синең соңгы бүләгең иде. Безнең паролебез — «яулык». Хуш, дустым. Безгә яңа тормышта кавышу насыйп булмаган икән. *(Келәткә алып кереп китә. Чыга.)* Кабахәтләр! Менә бит алар беренче чәчәкләрне ничек таптыйлар. Бабай, син күз-колак бул. Мин килермен. Мин аның өчен дә үч алырмын. *(Ашыгып чыгып китә.)* Отряд, минем арттан!

Г ы й м а й. Хәерле булсын. *(Каранып.)* Чү, кемдер килә. Палас бөркәнгән димме? Әйе шул. Бай бит бу. Кача... *(Кистәнен ала.)*

Сафа кача-кача килеп чыга. Палас бөркәнгән. Почмактан Гыймай кистәне белән бик нык итеп суга, Сафа егыла.

С а ф а. Аһ, белмичәрәк суктың...

Г ы й м а й. Белеп, бик белеп, баем. Син миңа ничәмә тапкырлар суктың, мин бер генә...

С а ф а. Харап иттең... *(Үлә.)*

Г ы й м а й. Тере килеш алырга дигәннәр иде дә, үтереп харап иттем шул.

Арттан шау-шу ишетелә. Янгын башлана.

Ә с м а *(йөгереп керә).* Карт, янабыз. Байның өе яна.

Г ы й м а й. Янсын, янсын, минем янар нәрсәм юк. Очкыннан ялкын туа дип тикмәгә әйтмәгән икән мәрхүмә Җамал. Ә син малатчина икәнсең, карчык, булдырдың. *(Аркасыннан сөя.)*

Янгын көчәя. Ату тавышлары. Шау-шу.

**П ә р д ә.**

——□——

Нил Юзиев

# МУЗАЛАР ТУГАНЛЫГЫ

## I Аерылулар, кушылулар. Жанр чикләре

Хәзерге вакытта әдәбият галимнәре, теге яки бу тарихи чордагы әдәби процессның гомуми үсеше кануннарын эзләүдән тыш, аерым жанрларның табигатенә төшенергә дә омтылалар. Бераүләр шигырь төзелешен өйрәнә, икенчеләр роман, повесть һәм драма тарихын, аларның поэтикасын тикшерә. Шиксез, әлеге омтылыш әдәби әсәрнең жанры табигатен, аның катлаулы төзелешен, һәр жанрның үзенчәлекле һәм кабатланмас хасиятен тагын да ныграк аңларга, әдәби төрнең һәм жанрның үз эчендә яши торган кануннарын ачарга ярдәм итәчәк. Әйтергә кирәк, соңгы елларда әдәбият белемендә моның уңышлы, куандыргыч җимешләре да күренә башлады.

Әдәбият белемендә генә түгел, фәннең башка тармакларында да нәк шундый аерымлану, тар белгечлеккә тартылу күчәеп бара. Фәннең тармаклары, өлкәләре күбәйгәннән-күбәя. Фәнни информациянең тизлек белән арта баруы галимне билгеле бер өлкәдә ныграк төпләнергә этәрә.

Шундый ук омтылыш әдәби иҗатта да сизелә. Вакытында Каюм Насыйри телче, әдәбиятчы, фольклорист, педагог, тарихчы һәм балалар язучысы да булган. Мондый энциклопедик галим һәм язучыларны башка халыкларда да очратабыз. Леонардо да Винчи, Ломоносов — саный китсәк, алар күпләр.

Сәнгать һәм әдәбиятның үсүе хәзер язучыдан үзенең таланты хуш күргән өлкәдә узләшүне сорый, бер өлкәдә тирәнәергә мөмкинлек бирә. Чынбарлыкны тирәнрәк танып-белү ихтыяҗы язучыны әдәбият дикъгезенең билгеле бер утравында ныграк төпләнүгә китергән. М. Шолоховның тик прозада иҗат итүе аның даның һич киметми. Бу бездә дә шулай. Үткән гасырларда, мәсәлән, балалар әдәбияты белән генә шөгыльләнүче язучылар булмаган. Хәзер балалар өчен генә иҗат итә торган, шушы өлкәне нечкәләп өйрәнгән язучыларыбыз байтак. Кинодраматургларны махсус институтларда, курсларда әзерлиләр. Хәтта бер пәрдәлек пьесалар яки фельетоннар буенча специальләшкән эдиплар бар. Либретто язу өчен шигырьне генә түгел, музыканы да, сәхнәне дә яхшы белергә кирәк. Шуңа да хәзергә бу өлкәдә консерватория тәмамлаган Хәй Вахитның гына эшләп килүе гаҗәп түгел.

Без еш кына киносценарийларның һәм опера өчен либреттоларның гадәттән тыш аз язылулары турында зарланабыз. Культурабызның артта калган тармакларын чын мәгънәсендә алгы сафка бастырырга телибез икән, заманның үскән таләбен искә алып, шушы өлкәләрдә махсус белем алган кадрлар әзерләү турында җитди уйланырга һәм конкрет чаралар күрергә тиешбез. Артистларны һәм шагыйрьләрне махсус институтларда һәм курсларда укытып кайтарган шикелле, киносценаристларны да, мәсәлән, киноинститутларда оешкан төстә, төркемләп-дистәләп укытырга вакыт җиткәндер инде, ниһаять.

Иҗат кешесенең хәзер нинди дә булса бер өлкәдә, жанрда узләшүе, шул жанрның тылсымлы серләрен ныклап өйрәнүе зарури. Ә. Еники — хикәя остасы. Аңа роман язарга тәкъдим итеп караучылар да юк түгел. Ләкин Әмирхан Еники һаман шул үзе сайлаган юлдан читләшми. Роман язмаган өчен генә әдипне гаепләп булмыйдыр. Аның таланты, мөгаен, шушы формада иң тулы ачыладыр. Х. Туфан, С. Хәким, Ә. Ерикәй, Г. Афзал, Ш. Галиев, Х. Камал — «саф» шагыйрьләр. Аларның көчләре — лирикада. Алардан беркем дә проза яки драма язуны сорамый.

Әмма әдипнең тик бер генә жанрда иҗат итүе кагыйдәме! Тормышта әлеге күренешкә капма-каршы булган омтылыш та: жанрларның кушылуы, керешү, язучыларның төрле жанрларда иҗат итү тенденциясе дә яши. Төрле жанрларда уңышлы эшләп килгән язучылар безнең хәзерге әдәбиятта да, үткәндә дә аз түгел. Тукай, Гафурилар талантлы шагыйрьләр генә түгел, оста прозаиклар да булганнар. Ф. Хөсни, мәсәлән, хикәяләр, романнар гына түгел, драмалар да иҗат итә. С. Баттал шигырь, повесть, роман һәм драма да яза. һ. Такташ, М. Җәлил, Ф. Бурнаш, К. Нәҗми, М. Максуд, М. Әмир, Ә. Фәйзи, Н. Исәнбәтләрнең дә әдәбиятның төрле төрләрендә иҗат итүләрен, бер генә жанрда түгел, башка жанрларда да кыйммәтле әдәби әсәрләр тудыруларын күрер идек.

Язучы иҗатында төрле жанрларның очрашулары ни сәбәптән килеп чыга! Кай

очракта ул файдалы, отышлы! Ә кайчан уңай нәтиҗәләр бирми! Әлеге күренешнең серләрен ачу әдәбият практикасы өчен гаять әһәмиятле булыр иде. Ни өчен, әйтик, Ә. Фәйзи бер төрле тормыш материалын поэмада ача, ә икенчесе өчен драма жанрын сайлый! Ф. Хөснинең хикәяче-новеллист булуы анын роман язуына нинди тәэсир ясый! Игътибар белән рәк күзәтсәк, «Җәяүле кеше сукмагы», «Утызынчы ел» романнарында да Ф. Хөснинең новеллистлык тәҗрибәсен әсәрнең архитектоникасында да, образларны ачу алымнарында да сизми калмас идек. А. Расихның маҗаралы хикәяләр язу тәҗрибәсе анын «Ике буйдак» һәм башка романнарына билгеле бер эз салган, сюжетны мавыктыргыч итеп корырга булышкан. Ә. Фәйзинең «Тукай» романында, Н. Дәүлинең «Яшәү белән үлем арасында», «Җимерелгән бастион» әсәрләрендә дә күренешләрне рәсемләү, детальләр сайлауда шагыйрьлек тәҗрибәсен күрергә мөмкин.

Теге яки бу жанрның үсеше, үз эчендә «бикләнеп», йомык рәвештә генә бармый. Әдәби жанрлар, сәнгать төрләре үзара туганнарча якын мөнәсәбәттә яшиләр, бербереенә көчле йогынты ясыйлар. Сәнгатьнең яңа тармаклары туа тора. Аларда еш кына сәнгатьнең төрле төрләре катлаулы бердәмлек төзиләр (мәсәлән, кино).

Сәнгать төрләре һәм әдәбият һәрвакыт: элек тә, хәзер дә катлаулы диалектик бәйләнешләрдә яшиләр. Нинди дә булса бер әдәби жанрның икенче бер төрдәге казанышларны файдалануы еш кына табигый булып китә. Мәсәлән, татар драматургиясен үстерүдә поэзиянең зур роль уйнавы турында шикләнмичә әйтергә мөмкин. М. Фәйзи, Ф. Бурнаш, М. Җәлил, Н. Исәнбәт, Ә. Фәйзи, һ. Такташ, Г. Насрый, Х. Вахитларның лирик поэзиядәге тәҗрибәләре пьеса иҗат иткәндә табигый рәвештә катнашып киткән. Татар драматургиясендә лирик агымның, романтик рухның, эмоциональлекнең көчле булуы, драматик әсәрләрнең хикмәтле үткен сүзләргә нифрат бай булуы күпмедер дәрәҗәдә әнә шул шагыйрьлек стихиясе белән бәйле. Бу тәэсирнең уңай яклары турында «Галиябану», «Яшь йөрәкләр», «Таһир-Зөһрә», «Җир уллары», «Хуҗа Насретдин», «Рәйхан», «Акчарлаклар», «Беренче мәхәббәт», «Янар чәчәк» кебек әсәрләр үзләре сөйләп тора.

Ләкин файдалануның ике төрле нигезгә таянуын да онытырга ярамый: ул сәнгатьнең яки әдәбиятның көчсезләнү, үз хәле бетү билгесе булырга да мөмкин. Врачлар, авыру кешене сәламәтләндерү өчен, анын үз организмы кабул итәрдәй кан төркемен генә файдаланалар. Дөрес файдаланган кан тәнне сихәтләндереп, көчәйтеп җибәрә. Сәнгать төрләре, әдәби жанрлар да шулай. Әйтик, үткән чорларда рәсем сәнгате осталарының атаклы һәйкәлчеләрдән өйрәнүе алар өчен файдалы гына булган. Татар театрына һәм драматургиябезгә шигырь ярдәмгә килгән, аларга аякка басарга булышкан. Аерым драма әсәрләрендә яки әсәрнең кайбер урыннарында, драматургия кануннарын үзләштереп бетерә алмау нәтиҗәсендә, шагыйрьлек тәҗрибәсенең кире яклары да күренә. Ләкин болар поэзиянең уңай тәэсирен юкка чыгарырга нигез бирми әле. Ул үзара керешүләрнең шактый катлаулы булуы турында гына сөйли.

XIX гасырда аерым рус картиналарының сүзсез театраль мезансценаларны хәтерләткән сыйфатлар белән баюы — шулай ук рус сәнгатенең шушы тарихи дәвердәге казанышы, эстетик ачышы. Соңгы дәвердә фотографиянең камилләшүе дә рәссамнарга билгеле йогынты ясады, ә сынлы сәнгатьнең тәэсире нәтиҗәсендә фото эше үзе сәнгатькә бик нык якынайды, сәнгатьнең бер тармагы булып әверелде.

Станиславский, үз чиратында, режиссер һәм актерларны турыдан-туры рус рәссамнарының әсәрләреннән өйрәнергә чакырган (Н. Горчаков. Режиссерские уроки К. С. Станиславского. М., 1951, 129—131 битләр). Метерлинкның «Чудо святого Антония» пьесасын сәхнәгә куйганда, режиссер фантазиясенә (Вахтанговка) атаклы француз художнигы, сатирик Домье иҗатының ярдәмгә килүе турында Рубен Симонов кызыклы фактлар китерә. Ә Домье үз карикатураларын атаклы француз актеры Фредерик Леметр тудырган хамелеон образларыннан файдаланып иҗат иткән. «Рәсем, музыка, скульптура сәнгате безгә, режиссерларга, еш кына спектакльнең формасын, анын бөтен сәнгатьчә образын, ә актерларга рольне хәл итәргә булыша», — дип яза Р. Симонов (Р. Симонов. С Вахтанговым. М., 1959).

Рәсем сәнгате белгечләре Врубель, Гоген, Ван-Гог картиналарын сыйфатлаганда, аларда музыка тәэсирен күрәләр, Сезанн картиналарының архитектоник булуларын билгелиләр, Репинга реалистик әдәбият үсешенең көчле йогынты ясавы турында язалар. Мондый тәэсир сәнгать төрләрен баета. Шунысы әһәмиятле, мондый «керешү»ләр дәвамында сәнгать төре үзенең асыл сыйфатын, үзен сәнгатьнең шул төрендә көчле итеп таныткан хасиятен югалтмаска тиеш.

Әдәбиятның үз эчендә дә: анын төрле төрләре һәм жанрлары арасында катлаулы бәйләнешләр яши. Татар әдәбиятында гасырлар буе шигырь патшалык итеп килде. Ә менә XIX—XX гасырларда реалистик татар прозасының зур уңышларга ирешүе, шагыйрьләрнең рус һәм бөтен дөнья классиклары әсәрләре белән танышулары аларның игътибарын проза казанышларына юнәлтмичә калмады. Кеше рухы диалектикасын катлаулы процесс буларак сурәтләүдә булсынмы, тормыш-көнкүрешне конкрет тарихи-социаль сыйфатлары белән бирүдә булсынмы — XX йөз башы шагыйрьләре прозаиклардан күп нәрсә өйрәнәләр. Шартлы поэтиканы яңартучы көчләрнең берсе реалистик проза булды дисәк, мөгаен, һич тә ялгыш булмас.

Проза хәзер дә поэзиягә көчле тәэсир ясый, тормышны тирәнрәк танып-белергә ярдәм итә, аерым жанрларның чикләрен үзгәртә, темаларын, сурәтләү чараларын

баетырга, яңа стиль үзенчәлекләре тудырырга булыша.

Әгәр поэзия белән прозаның бөтен әдәбият тарихы дәвамында үзара мөнәсәбәтләрен күзәтеп чыксак, аларның чордан-чорга үзара туганлыклары нығый баруын күрер идек. Поэзиянең чикләре сыгылмалырак була бара. Кайчандыр проза «хуҗалыгы»нда саналган тормыш материалын шагыйрьләр, кыюлык белән, шигърият дөньясына алып керәләр, прозаик күренешнең дә шигъри яңгырашын табалар. Яков Емельяновның «Ярлы тормыш», Н. Думавиның «Мәхбүс», С. Рәмиевнең «Кояш чыга да бата», М. Гафуриның «Татар хатыны», «Хәерче» кебек шигырьләрендә тормыш прозаизмы шигырьгә бик табигый рәвештә керә кит, шигырь структурасында әһәмиятле роль уйный.

Х. Туфан безнең поэзияне үзенчәлекле язмышлы, үзгә характерлы лирик герой белән генә түгел, үзенчәлекле индустриаль пейзаж белән дә баетты, шигъриятькә «домналар, мартеннар җылысын да» алып килде.

Алда Урал,
Ерак күксел тауда
Аксак болыт туктап хәл җыя.

Безнең күз алда шигъриятле Урал табигате җанлана. Әмма шагыйрь моның белән генә чикләнми. Уралның тагы да конкретрак образын тудыра, завод трубаларын, төтеннәре белән бергә, шигырьгә алып керә:

Кыңгыр яткан Урал
Челем тарта.
Челем сабы — озын таш торба.
Билгә кат-кат рельсы билбау урап,
Күпер белән муенын каптырган.

Д. Фәтхи, Ш. Маннур шигырь, поэмаларында да «чуен ташкыннарны» шигърият мәйданына алып керү буенча уңышлы гына эзләнүләр барды.

һ. Такташ авыл һәм шәһәр көнкүрешенең моңарчы шигъриятә урын тапмаган күп якларын зур кыюлык һәм осталык белән тасвирлады, прозаик көнкүрешнең шигъри яңгырашын тапты, прозаизмның шигырьдә бөтенләй яңа стилистик вазифаларын ачты.

«...Мин соңгы вакытларда төп мотивларымны матур декорацияләр, күп вакытта көлке элементлар белән урап яза башладым. Мәчеләр, казларны көлке позаларга куеп, урталарына авылның бәхетле киләчәген җырлаучы тракторны китереп куям», — дип язды ул бер мәкаләсендә, үзенең иҗат принцибын аңлатып.

М. Җәлилнең «Кандала» шигырен хәтергә төшерегез. Прозаик төрмә күренеше, прозаик детальләр (тычканнар, кандала туйлары) шигырьнең башка кисәкләре белән тыгыз бәйләнешкә кереп, ахырда нинди поэтик, җан тетрәткеч күренеш хасил итәләр!

Поэзия һәм суд... Бу төшенчәләрнең янәшә килүе бераз сәеррәк тоела. Ул, бәлки, поэзиянең тормыштагы күтәренке, шигъри вакыйгаларны, матурлыкны чагылдыру омтылышына бәйледер! Суд, бәлки, шуңа да моңарчы поэзия ишеген какмыйча, күбрәк прозага, драматургиягә тартылгандыр! С. Хәким кыю рәвештә суд залын, суд дөньясын поэзиягә алып керде, аны шигъри күзлегеннән карап яктыртты.

Поэзиябезнең шигърият мәйданын киңәйтүгә С. Баттал, Ш. Мөдәррис, Х. Камал, Г. Афзал һәм башка шагыйрьләрдән дә байтак мисаллар китерергә мөмкин булыр иде. һәр шагыйрь поэзиядәге бу күренеш белән очрашмыйча калмый торгандыр. һәр шагыйрь прозаизмны поэтик әсәр тукымасында файдалануның үз юлын сайлый, үзенчә хәл итә. Кыскасы, прозаизм хәзерге шигырь өчен ят нәрсә түгел.

Ләкин һич тә һәр очрашу шагыйрьнең җиңүе белән тәмамлана дип әйтә алмыйбыз. Гадәти тормыш күренешенә шигъри рух өрү, аңа шигъри ачкыч таба алу, прозаизмны, мәгънәле сәнгатьчә алым буларак, шигырь тукымасында файдалану шагыйрьдән зур осталык сорый. Бу өлкәдә Х. Туфан, Ш. Маннур, С. Хәким кебек шагыйрьләрнең дә аерым әсәрләрендә авырлык кичерүләре, хәтта һ. Такташның мәче, каз образлары кергән шигырьләренә тәнкыйтьнең үз вакытында «һөҗүм» итүе мәсьәләнең алай ук җиңел булмавына тагын бер кат ишарә ясый. Демьян Фәтхинең иҗат юлын бик тә гыйбрәтле мисал итеп китерәсе килә. Талантлы шагыйрь 20—30 елларда шушы юнәлештә кыю экспериментлар ясады. Әлеге тәҗрибәләр йомгагы буларак, аның атаклы «Алтын тайга трагедиясеннән» поэмасы туды. Әмма бу әсәр язылганчы шагыйрь байтак югалтулар да кичерде.

Поэзия белән прозаның табигый чиген табу цирк артистының кыл өстендә йөрү күренешен искә төшерә. Шагыйрьдән дә шундый ук осталык, виртуозлык, сизгерлек, шигырь кануннарына илтифатлылык сорала. Д. Фәтхинең шигъри сөйләм законнарын, ритмикадагы симметрия һәм тигезлекне санга алып бетермичә, шигырьне прозаик сөйләмгә якынайтуы уңышсызлыкка да китергәләде.

Бүгенге поэзиядә дә Д. Фәтхинең уңышсыз чыккан тәҗрибәләрен кабатлаган, яңа шигырь формасы сылтавы белән поэзиянең бөтен кануннарын кире каккан әсәрләр күренгәли. Шагыйрьнең эзләнү хокукын кире какмастан, яшь шагыйрьләрнең игътибарын өлкәннәрнең тәҗрибәләрен җентеклебрәк өйрәнергә юнәлтәсе килә. Бу өлкәдәге җиңүләрне һәм югалтуларны хуҗаларча исәпкә алу, яуланган казанышларга ныграк таяну поэзиябезнең үсешен тизләтергә ярдәм итәчәк.

Прозаизмның әсәр тукымасында диссонанс тудырып, стиль бөтенлеген юкка чыгару очракларына да, прозаик тормыш материалының шигъри ноктасы табылмыйча файдалануына да безнең бүгенге поэзиядән байтак мисаллар китерергә була. Шагыйрьләрдә дә фәнни караш тәрбияләү өчен бу мәсьәләләрне гыйльми өйрәнүне, гомумиләштерүне тизләтергә кирәктер.

Әдәбиятның 50 еллык тәҗрибәсе бүгенгегә ныграк булышсын иде. Әйтик, поэмалар бездә гаҗәп күп язылган. Ләкин аларның азы гына әдәбият тарихында билгеле бер эз калдырган. Байтагы язылганнар да онытылганнар. 20—30 елларда никадәр тезмә әсәрләр язылган! Ә хәзер алардан дистәгә якыны гына яши. 50 еллардагы поэмаларның исәбенә чыгу шулай ук кыен. Ә күпмесе яши! Бик азы! Н. Баян, Г. Хуҗи, Ш. Мөдәррис кебек тәҗрибәле һәм сәләтле шагыйрьләрнең дә поэмалар иҗат иткәндә шактый гына кыенлыкларга очравы тикмәгә түгел бит.

Күп кенә поэмаларның уңышсызлыкка очравындагы бер сәбәп, минемчә, жанрның эчке хасиятләренә җитәрлек игътибар итмәстән, шагыйрьләрнең прозаикларга артык ияреп китуләрендә. Кайчандыр, прозаның эстетик функциясе көчсезрәк дәверләрдә, шигырь башка жанрлар өстенә төшкән йөкне дә күтәреп барган, проза чикләренә дә үтеп кергән. Проза, драматургиянең үсеше поэзиянең эстетик чикләрен хәзер нык үзгәртте, шигырь җилкәсендәге тормыш материалының авыр йөген нык җиңеләйтте. Ул поэзиянең, шигырьнең үз асыл хасиятен активрак эзләргә этәрде.

Поэманың үз кануннарын исәпкә алмау, хикәя яки повесть поэтикасын механик төстә поэмага күчерү яки хикәядә тирәнрәк ачылырга тиешле тормыш материалын эзмә-эз шигырь теле белән бирү поэзиянең үсешенә комачаулый торган җитди сәбәпләрнең берсенә әверелде. Монысын, бәлки, азмы-күпме дәрәҗәдә прозаның поэзиягә агрессиясе дип тә атарга мөмкин булыр иде. Ләкин шунысы гаҗәп, прозаиклар һөҗүм итми бит, шагыйрьләр үзләре прозага тартылалар. Ике арадагы чикләрне атлап чыгу сәбәпле, үзләре үк прозаикларга әсир төшәләр.

Һәр жанр, һәр сәнгать төренең тууында, яшәвендә эчке бер ихтыяҗ һәм зарурилык бар, һәр жанрның үз эчке мөмкинлекләре бар. Музыка, мәсәлән, шагыйрь яки рәссам әйтеп бирә алмаган кеше хисләрен бирә ала. Шуның өчен яши, шуның өчен кирәк. Шагыйрьнең дә композитор әйтеп бетерә алмаган хисләрне әйтүе, прозаик үтеп керә алмаган рухи дөньяны ачуы зарур. Сәнгать төрләренең, әдәби жанрларның туганлыклары аларны бар иткән, яшәткән асыл сыйфатларына зарар итмәскә, шагыйрь һәрвакыт шагыйрь булып калырга тиеш. Такташ сүзләре белән әйтсәк, шагыйрь тормыштагы яңа хисләргә исем куша. Ул кеше җанының музыкасын эзли, таба, шуны сүзләр белән олы дөньяга чыгара. Бүгенге поэзиянең төп үсеш тенденциясе шушы юлда.

* * *

Сәнгать төрләренең һәм әдәби жанрларның үзара йогынтылары, тарихи-социаль шартларга һәм яшәп килә торган эстетик йола-нормативларга бәйле рәвештә, төрле тарихи чорда, төрле милләттә төрлечә булган. Бу мәсьәләне тарихи прогресска бәйләп, чынбарлыкны танып-белүнең тирәнәюе рәвешендә тикшерү — киләчәк эше. Шулай да, татарда профессиональ сәнгать төрләренең байтагының XX гасырда гына туыннан чыгып, үзара йогынтыларны тикшерүне дә совет чорына гына кайтарып калдыру хакыйкатькә туры килмәс иде.

XX гасыр башында әдәбият һәм сәнгать төрләре синтезының яңа юллары туа. Совет чорында бәйләнешләр тагы да көчәя. Әмма бу элекке дәверләрдә дә синтез һәм үзара йогынтыларның яшәп килүен һич тә инкарь итми. Җыр һәм шигырь, көй һәм сүз татарда борын-борыннан синтез төзеп килгәннәр. Монысы — аксиома. Ә менә башка сәнгать төрләренә карата мәсьәлә катлаулана төшә. Рәсем сәнгате һәм скульптура татарларда соңгы гасырда гына туган, дип сөйләргә яратабыз икән, әдәбиятның әлеге төрләр белән бәйләнешен тикшерү үзеннән-үзе юкны бушка әйләндерү, миф булып чыга түгелме соң? Хәлбуки, бу миф түгел. Тарих башкача сөйли. Археологлар, тарихчылар (С. М. Шпилевский, И. Н. Березин, А. Ф. Лихачев, Ф. Баллод, А. П. Смирнов, Н. Ф. Калинин, А. Халиков, Ф. Вәлиев һ. б.) борынгы болгар-татарларда да сәнгатьнең, һөнәрчелеккә бәйле рәвештә, чигү, каю, чуен, көмеш кою кебек төрләренең киң тамыр җибәрүе, борынгы архитектураның үз чоры өчен шактый югары дәрәҗәдә булуы турында язалар. Дистәләгән фәнни экспедицияләр сынлы сәнгатьнең болгар-татарларда күп гасырлар буе яшәп килүенә күп дәлил туплады. А. П. Смирнов, мәсәлән, хәзерге татарлардагы ювелирлык сәнгатен борынгы болгарлардан килә дип саный («Волжские болгары», М., 1951, 79 бит) һәм болгар һөнәрчеләренең металл сайлауда булсынмы, орнаментта булсынмы — үз стильләре булуы турында яза (шунда ук, 116 бит). Атаклы сәнгать белгече В. В. Стасовның 1902 елда ук, борынгы Болгардагы көнкүреш ядкарьләре турында: «Живописьта һәм сәнгатьчә промышленностьта төрки стиле тиешенчә өйрәнелмәгән. Әмма ул бар, аның булуында шик юк. Ул стиль аерата ачык сизелә, ул аерата хас», — дип язуы юкка түгел.

Халык тормышының кайсы гына өлкәсен алып карамыйк, без көнкүреш әйберләренең шул чорның матурлык законнары таләбеннән чыгып ясалуын күрәбез. Ул заманнарда сәнгать көнкүреш белән аерылгысыз, бердәм ансамбль төзеп, шул көнкүрешнең эчендә яшәгән. Менә гади савыт-сабалар. Иң борынгы дәверләрдә Болгарда аларны хайван сурәтләренә охшатып ясаганнар. Алар күп төрле орнаментлар белән бизәлгән. Берләрендә — уртасында нокта булган концентрик түгәрәкләр, йолдызлар; икенчеләрендә—агач яфракларына охшаш сурәтләр. Ул гына да түгел, аларда һәртөрле фантастик җанварлар (аждаһа, гриф) һәм реаль хайваннар (эт, сарык, куян, арыслан, аю) сурәте дә шактый еш очрый. «Шунысы гаҗәп, — дип яза А. Ф. Лихачев, — сәнгатькяр һәр реаль хайванның үзенчәлекләрен шундый уңышлы тота алган, рәсемгә карау белән,

останың нинди хайванны ясарга теләвен шунда ук белеп була» [А. Ф. Лихачев. Бытовые памятники Великой Булгарии. 1876, 11 бит]. Болгарлар ясаган көзгеләр, балталар, сугыш кораллары да үсемлек, кош, хайван рәсемнәре белән бизәлгән. Борынгы Болгар дәүләте һәм Казан ханлыгы чоры акчаларында да [бакыр таңкаләрдә] без һәртөрле бизәкләр: кош, хайван һәм кеше сурәтләре белән очрашабыз. [Ф. М. Френның 1832 елгы, И. Н. Березинның 1855 елгы хезмәтләрен кара.]

«Менә бу укка игътибар итегез, — ди нумизмат Мөхәммәдиев, борынгы акчаларга күрсәтеп. — Ул сугыш угы түгел, ә ау угы. Җәнлекләрнең тиресен бозмас өчен, шундый уктан файдалана торган булганнар. Мондый уклар казу вакытында еш табыла. Бу таңкаләр — сәнгать тарихы өчен гаҗәеп зур байлык. Вакытына күрә алар сәнгать үсешен чагылдырганнар, даими чыгулары һәм меңәрләп сугылулары белән, газета ролен дә үтәгәннәр. Шулар аркылы халык дөнья яңалыклары белән танышып торган».

Гадәттә мөселман халыкларында, шул исәптән татарларда да, сынлы сәнгатьнең үсүе турында сөйләгәндә, исламның тере сын ясауны тыюына бәйләп, сүзне артык кыюсыз алып баралар: бездә сәнгатьнең ул төре булмаган, бусы да тумаган, чөнки дин рөхсәт итмәгән, диләр. Кыска җавап. Ансат җавап. Әмма фәнни, нигезле җавап түгел. Дөрес, шәригать, тере җаннарны һәм кешеләрне ясауны тыеп, сынлы сәнгать үсешенә искиткеч зур тоткарлык ясаган. Дөнья күләмендә танылган рәссамнарыбызның, һәйкәлчеләребезнең юклыгы, бәлки, нигездә шушы рухи изүгә бәйледер. Ләкин бу әле татарларда сынлы сәнгать төрләре һәм аларның тарихы юк икән дигән сүз түгел.

Аннары, шәригатьнең тере җаннарны тыюы барлык чорлар өчен дә һәм барлык халыклар өчен дә бертигез дәрәҗәдәге канун рәвешен алмаган. Мәсәлән, борынгы гарәп тарихчысы Макризиның мөселман сурәтчеләре биографияләрен теркәгән хезмәте булган. Кызганычка каршы, ул хезмәт сакланмаган. Макризи язуынча, Мисырда Басрадан чыккан Ибн-әль-Азиз һәм Ирактан килгән Казир дигән рәссамнар аеруча атаклы саналган. Язури исемле вәзир аларга сарай диварларын рәсемнәр белән бизәргә боерган. Ибн-әль-Азиз рельеф эффектлары белән сары тонда кызыл япма ябынган биюче хатын-кыз сурәте ясап куйган. Макризи рәссамның кеше сыннарын рельефлы итеп сурәтләү осталыгын да билгеләп үткән. Моны ул Йосыфның кое эчендәге күренеше белән дәлилли: аның ап-ак тәне кара фонда контраст булып аерылып торган һәм караган кешеләргә Йосыф җир асты төрмәсеннән чыгып килә торган шикелле тоелган. [Б. Денике. Искусство Востока. 1923.] Ләкин Макризи язган бу мәгълүматлардан тыш, тарих башка сурәтчеләрнең исемнәрен дә, Ибн-әль-Азиз һәм Казирның рәсемле тукымаларын да сакламаган.

Борынгы татар культурасы ядкарьләренә игътибар иткәндә дә ислам дине таралуының баштагы дәверләрендә җанлы сурәт төшерүгә иркенрәк караш яшәвен, сынлы сәнгатьнең һәм архитектураның тормышта әһәмиятле роль уйнавын чамаларга мөмкин. XIII гасыр әсәре «Йосыф-Зөләйха» кыйссасында шушы фикерне ачыклый торган дәлилләр бар. Зөләйха үзенең Йосыфка гашыйк булуы турында сөйләгәч, даясе [тәрбиячесе] аңа түбәндәгечә киңәш бирә:

Дая әйдер: «Баниләр»[1], хазыйр кәлсен,
Сәңа лаек бер сарай бина кылсын;
Уйлә кылсын: кем күргән хәйран калсын,—
Эче гаҗәп дәрле нәкыш[2] улсын имди.

Төзүчеләр һәм сәнгатькярлар сарайның эчен хәйран сокланырлык итеп матурлыйлар: аның эчен ун мең төрле нәкышлар бизи, ахак һәм кристалл колонналар янында кызыл алтыннан эшләнгән агачлар, көмештән ясалган үгезләр, саф алтыннан коелган атлар тора... Алар гына да түгел.

Сурәт (берлә) бизәсеннәр сәкыф[3] арасын,
Уйлә кылсын (һәм) дүрт дивар арасын.
Бизәсеннәр җөмлә Йосыф сурәтен, —
Һәм сәңа биңзәтү[4] кылсыннар имди.

Сарай түшәмен һәм стенасын кеше сурәтләре белән нәкышлау күренеше белән без поэмада тагын бер тапкыр очрашабыз [13 бүлектә]. Йосыф үзенең төзүчеләренә сарай салырга һәм стеналарын рәсемнәр белән бизәргә боера. XIII йөз поэмасында сурәтләнгән бу күренеш үзе үк Кол Гали кебек шагыйрьләрнең ислам догмалары белән артык исәпләшеп тормаулары турында сөйләсә, икенчедән, сәнгатьнең ул чорларда да халык тормышында зур роль уйнавын, матурлык тойгысы белән әхлак тәрбияләү мәктәбе булуын күзалларга ярдәм итә. Тагын шул. Поэмадагы вакыйгалар Болгар җирендә бармасалар да, анда тасвирланган мәхәббәт, көнчелек кебек гомум кешелек тойгылары болгарлар өчен табигый булган кебек, төзү һәм нәкыш сәнгатенә караган өлешләрнең дә реаль җирлеге булуы бик ихтимал. Болгар төзүчеләренең осталыгы турындагы мактау сүзләрен Татищев кебек рус тарихчыларының язуы да моңа бер дәлил. Борынгы Болгар хәрабәләрендә күп еллардан бирле алып барылган казу-тикшеренү эшләре дә Болгар дәүләтендә төзү сәнгатенең үз чоры өчен югары профессиональ дәрәҗәдә торуын раслыйлар.

Идел, Кама буйларыннан, Казан, Пермь тирәләреннән табылган ядкарьләр арасында кеше сыны төшерелгән сөяк, тимер, бакыр әйберләр, көмештән, бронзадан коелган кеше сыннары, таш һәйкәлләр бар. Аларның берләрендә — хатын-кызлар, икенчеләрендә — аучы яки сугышчы ирләр, өченчеләрендә аксакал картлар сынландырылган. Борынгы бабаларыбыз

[1] Баниләр — төзүчеләр.
[2] Нәкыш — бизәк.
[3] Сәкыф — түшәм.
[4] Биңзәтү — охшату.

яшәгән төбәкләрдә кыпчакларга хас «Таш баба»ларның — таш сыннарның очраулары да кызыклы һәм әһәмиятле күренеш.

Сәнгать тарихыбызның кыйммәтле истәлекләре илебезнең төрле музейларына сибелгәннәр. Аларга ни өчендер сәнгать белгечләренең игътибары җитеп бетми. Шуңа да безнең сәнгатьнең аерым тармаклары әле язылмаган һәм укылмаган мавыктыргыч сәхифәләр булып калуында дәвам итә.

Әдәбият тарихын өйрәнгәндә дә аны шул чор сәнгате белән бәйләнештә карау юк. Җир асты хәзинәләре: таш һәм бронзалар безгә борынгы сынлы сәнгать үрнәкләрен генә түгел, аларның әдәбият белән туганлыкларын да — шул чорлардагы үзенчәлекле синтез күренешен дә саклаган. Нәкыш, миниатюра, орнамент һәрвакыт диярлек шигырь һәм хикмәтле сүз белән бергә йөргән. Шигъри сүз һәм орнамент угланнарның көбә һәм кылыч-калканын,ияр-ыңгырчакларын да, йортларны һәм бүлмәләрне дә, шәрап яки чәй эчә торган кувшиннарны да, кара савытларын да, хәтта акчаларны да бизәгән. А. Терещенко, 1840—50 елларда Сарай-Берке шәһәрен казыганда, борынгы татар язулары һәм һәртөрле чәчәкләр белән сырланган зур мәрмәр кисәкләре, хәтта бөтен кәрнизләрнең күп табылуы турында искәртеп үтә [Ж. М. В. Д. 1847, XIX]. Мәсәлән, ул шундый бер мәрмәр уртасына лилия чәчәге ясалуын, чәчәк тирәсенә Сәгъдинең фарсыча шигыре урнашуын яза һәм аның русча тәрҗемәсен китерә. Бу факт әдәби бәйләнешләр тарихын өйрәнү ягыннан да әһәмиятле. Таш «китап»ларга ышанмаска нигез юк бит.

Археологик җәмгыять язмаларында [ВО РАО, т. XXI, вып. 1, 1912, стр. 38] шигырь белән бизәлгән кувшиннар турында да очратырга мөмкин. Менә шул язуларның берсе:

Кеше күрке йөз ул, бу йөз күрке — күз,
Бу авыз күрке тел ул, бу тел күрке — сүз.
Тагын күрек кешегә белик һәм һәнү
Пулуг къылгу жанны беликлеккә әр.

Шул ук кувшинда түбәндәге ике юл да бар:

Бу кубнинең эчендә
Яшь көяр булур.

Кешеләрнең кабер ташларын да шигырь һәм орнамент бизәгән. [Г. Юсупов. Введение в булгаро-татарскую эпиграфику. М.—Л., 1960.] Шигъри юллар архитектура ядкарьләрендә дә очрый.

Шагыйрь фантазиясе рәссам-архитектор хыялын уяткан, ә сәнгатькяр эшләре шагыйрьнең образларын, әдәби телен үтемлерәк итәргә булышкан дип уйларга да нигез бар. Татар халкының сурәтле фикерләвендә [шул исәптән поэзиядә] төсле бизәкләрнең борынгыдан ук әһәмиятле урын алып килүләре әнә шул борынгы талантлы рәссамнардан килмиме икән! Гомумән, татар халкы борынгыдан ук төрле ачык төсләрне ярата, төсләргә аерым бер мәхәббәт белән карый.

Ислам шәригатенең кысуына бәйле, татар рәссамнары үзләренең осталыкларын һәртөрле җансыз әйберләргә күчерергә мәҗбүр булалар. Бу өлкәдәге традицияләр баетылганнар. Ләкин орнамент та һәм декоратив рәсемнәр дә, мөгаен, талантлы рәссамнарда буш, мәгънәсез бизәкләр җыелмасы гына булмаганнардыр, дип уйларга кирәк. Алар конбатыш сәнгатькярләренең фикерләвеннән бөтенләй үзгә фикерләү системасын тудырганнар. Орнамент аларга рәсем, һәйкәлчелек шикелле үк гади, аңлаешлы, шул ук вакытта мәгънәле сурәт булган. Ул тел хәзер безнең өчен күп очракта ят. Без хәзер аларның бизәкләре, парчалары, төс чуалышлары белән генә сокланабыз, ә шул орнаменталь яки декоратив образлар аңлаткан мәгънәгә әһәмият бирмибез. Дөресрәге, аңламыйбыз, чөнки хәзер безнең сурәтле фикерләү законнары ул дәверләрнекеннән нык аерыла. Ул дәвер сәнгатькярләре конкрет предметлардан абстрактлашуга юл тотканнар. Чәчәк, кояш, агач сурәтләре тора-бара үзләренең реаль сыйфатларын югалта барганнар, шул вакыттагы дөньяны кабул итүләренә, магик йолаларга бәйле символик мәгънә алганнар. Тора-бара символик мәгънә дә үзенең эчтәлеген, мәгънәлелеген югалта, билгеләрнең функциясе үзгәрә.

Чагыштырып карaганда, бу хәл бер татар сәнгатенә генә хас күренеш дип әйтә алмыйбыз. Шуңа охшаш хәлне, башка тарихи һәм социаль шартларда, рус сәнгатендә дә күрергә мөмкин. Безне бу юлы мәсьәләнең икенче ягы — сынлы сәнгать белән поэзиянең үзара мөнәсәбәте кызыксындыра.

Борынгы әдәбиятны тикшерүче галимнәр [Д. Лихачев, Я. Лурье һ. б.] шул чор сынлы сәнгатенә хас конкретлыктан качып, гомумилеккә омтылу сыйфатының рус әдәбияты өчен дә уртак булуы турында язалар. Шундый уртаклык татар әдәбияты өчен дә ят түгел. Сүзләрдән орнамент төзү поэзиядә язылмаган бер кагыйдә рәвешен ала. Тукай, Такташ, Җәлилдән дә, бүгенге көн шагыйрьләреннән дә сүз бизәкләре төзүгә, аларны лирик яки эпик әсәр хасиятенә нисбәтән оста куллануга күп мисаллар китерергә була. Бу — поэзия һәм рәсем сәнгатендәге уртак хасиятләр турында сөйли торган әһәмиятле факт. Меңләгән хис бизәкләрен, төсмерләрен эченә алган дүртәр юллы халык җырларын хәтергә төшерик. Алар да төрле хис-тойгыларны ачарга ярдәм иткән әнә шундый орнаменталь сурәтләр — хис бизәкләре булып тезелмиләрмени!

Тәрәзәм төбе асылташ,
Алтын белән, җаный, аралаш;
Бармагың камыш, йөзең кояш,
Акылларың камил, үзең яшь.

Хискә, ситуациягә бәйле рәвештә, башкаручы-җыручы меңләгән куплетлар арасыннан үзенә хуш килгәнен сайлап ала бара, тезә бара. Рәссам төс һәм сызык бизәкләрен кушуның чиксез мөмкинлекләрен тапкан кебек, чичән дә җырны синтезлауның котелмәгәнчә күп меңләгән

вариант һәм вариацияләрен таба. Хуҗа Насретдинга багышлап чыгарылган мәзәкләрнең яшәешендә дә орнаментикада очраган шушы принципка тәңгәллекне күреп була түгелме соң! Мөхәммәдьяр поэмаларына, С. Сараиның төрки «Гөлстан»ына, Г. Кандалыйның Сәхипҗамалга шигырьләр язуына игътибар иткәндә дә композициядә шушы дәвамлы теркәп бару — орнаментика кагыйдәсенә охшаш күренеш белән очрашабыз.

Әмма шунысын да әйтергә кирәк, поэзиядә — төс һәм хис бизәкләрен куллану ягыннанмы, әсәрнең композицион хасияте ягыннан булсынмы — рәсем сәнгате белән охшашлыклар булса да, орнамент һәм орнаментальлекнең эстетик функцияләре ике сәнгать төрендә бер-берсеннән бик нык аерыла.

Шигъриятнең рәсем сәнгате белән борынгыдан ук туганлыкта яшәп килүен икенче бер күренеш белән дә дәлилләргә мөмкин. Югарыда без ислам диненең җанлы сурәт төшерүчеләрне эзәрлекләвен әйтеп үткән идек. Бу — сәнгать өчен фаҗигале рухи көрәш төсен алган. Археологларның XIV—XV гасыр хәрабәләрендә кеше сыннары табуы ислам диненең әлеге чикләве татар халкында да нык каршылыкка очравы турында уйларга нигез бирә. Үзенең якын туганына поэзия дә ярдәмгә килгән. Шәригать никадәр ортодоксаль һөҗүм итмәсен, ул әдәбият һәм сәнгатьтән кешене тасвирлауны чыгарып ташлый алмаган. Кеше сурәтен таштан, бронзадан, сөяктән, агачтан ясау тыелса, сәнгатькяр аны сүздән «койган». Сүзнең тылсымлы көче белән Йосыф, Зөләйха, Таһир, Зөһрә, Сәхипҗамал кебек чибәрләрнең портретларын иҗат иткән, рәссам шикелле үк тулылык һәм төгәллек белән, укучы сокланырлык итеп, кеше сынын сурәтләгән. Татар поэзиясенең шушы омтылышы аның сурәтләү мөмкинлекләрен һәм чикләрен дә киңәйткән. Ләкин поэзиянең сынлы сәнгать өлкәсенә керүе — бу басып алу, агрессия, интервенция түгел, ә киресенчә, туганына ярдәмгә килү, табигый һәм тарихи зарури күренеш. Кешенең физик һәм рухи матурлыгын җырлау үзенә күрә ислам идеологиясенең реакциясенә каршы рухи бунт булган. Кол Гали, Мөхәммәдьяр, Сәйфи Сараиларда булсынмы, халык җырларында булсынмы — кеше портретын рәссам шикелле колоритлы, ачык буяулар белән тулы итеп сурәтләү омтылышы, минемчә, әнә шул борынгы традицияләрдән, борынгы туганлыктан ук килә. Хәтта төрки поэзиясе урта гасырларда кешенең физик мәһабәтлеген, матурлыгын осталарча күрсәтә белүе белән башка әдәбиятларга да тәэсир ясаган. Бу турыда, мәсәлән, гарәп галиме Әмин әл-Холи «Нил һәм Идел арасындагы бәйләнешләр» (М., 1962) исемле китабында ачык әйтеп уза:

...Идел урта гасырларда Нил белән тыгыз бәйләнештә яшәгән. Мисырда яшәүче кыпчаклар гарәпләрне кымыз эчәргә һәм түбәтәй киярга генә түгел, әдәбият һәм сәнгать өлкәсендә дә күп кенә гыйбрәтле нәрсәләргә өйрәткәннәр. Әмин әл-Холиның язуынча, Мисырга мәмлүкләр килгәннән соң, гарәп шагыйрьләре кеше тәненең матурлыгын сурәтләүгә һәм данлауга аеруча игътибар итә башлаганнар, әдәбиятта яңа сурәтләр, эпитетлар туган, һәм нәфислекнең өлгесе итеп һәрвакыт мәмлүкләрнең матурлыгы алынган.

XX гасырда сынлы сәнгатьнең татар дөньясында кабат терелеп, профессиональ төс алуы, элек тыелган жанрларның тулы мөмкинлекләр белән үсеп китүе хәзер аның поэзия белән мөнәсәбәтендә дә кайбер үзгәрешләр тудырмый калмады. Ул поэзиянең үз чикләрен кристаллаштырып, үз мөмкинлекләрен ныграк эзләргә этәрде һәм этәрә. Тукайга игътибар итсәк, без нәкъ шушы омтылышны ачык күрербез. Ул поэзиянең үз чикләрен тагы да ачыграк рәвешкә китерә, шигырьнең үз хасиятен, аның бай мөмкинлекләрен эзли. Дәрдмәнд иҗаты өчен дә шушы тенденция хас. Әмма моннан чыгып, XX йөз башы татар поэзиясе кешенең тышкы матурлыгын сурәтләүдән читләшә икән, дигән фикерне әйтү хата булыр иде. Кеше матурлыгын сурәтләү бу чорда да шигъриятнең тылсымлы бер көче саналган. Шигъриятнең табигый, зарури бер хасияте булган. Ахыр чиктә ул гуманизмга барып тоташкан, гуманизмның татар поэзиясендәге үзенчәлекле гәүдәләнешен чагылдырган күренеш булган. Тукай, Гафури, Думави, Дәрдмәндләр иҗатын тикшергәндә поэтикадагы шушы гомум закончалыкны искә алмыйча ярамый торгандыр.

Дәрдмәндтә, мәсәлән, «Рәсем» исемле (1908) түбәндәге портрет-шигырьнең очравы һич тә очраклы түгел:

Тәнкәен ак, түшкәйләрен киң яраткан,
Биткәенең иң очында миң яраткан,
Саклар өчен зифа буен яман күздән
Чәчкәйләрен аяк белән тиң яраткан.

М. Гафурида да мондый характердагы шигырьләр аз түгел (мәсәлән, «Ул» шигыре, 1919).

Татар профессиональ сәнгатенең үсүе, бөтен дөнья рәсем сәнгате казанышларына киң юл ачылу, шәригать салган киртәләрнең алынып ташлануы (Бу процесс үзе Тукайлар заманында ук башлана. Дөньяның мәшһүр рәссамнарын пропагандалау буенча «Аң» журналы зур эш башкара) хәзерге поэзиядә кешенең портретын тасвирлауда шагыйрьне яңарак алымнар эзләргә этәрә. Рәссамнардан килгән күренеш, вакыйга, портретларны сәнгатьчә төгәллек һәм тулылык белән күз алдына китерерлек итеп сурәтләү, детальләр белән эш итү осталыгын — шигъриятнең зарурияте булып киткән хасиятләрне шагыйрь, әлбәттә, ташларга җыенмый. Такташ балалык дусты Мөхәммәтҗанга багышлап язган «Мокамай» әсәрендә нинди төгәл, саран штрихлар белән Мокамайның портретын җанлы итеп күз алга бастыра:

Әкияттәге ике бала кебек,
Каен башларына үрмәләп,
Ике штансыз малай дөнья белән
Танышып йөргән идек бергәләп...

Беребез сары чәчле, беребез — кара,
Сары чәчлесе ул — мин идем,
Кара чәчле, коңгырт кара күзле,
Кәкре аяклы дустым, җан кисәгем,
Ул, Мокамай бәгырем, син идең.

Әмма шагыйрь образның тышкы төгәл портреты белән генә чикләнми. Шигырь безне рәссам да бирә алмаган юллар белән алып китә. Шагыйрь Мокамайның җанлы бала чагын, алар кичергән авырлыкларны күз алдына бастыра, портрет социаль фон һәм рухи тирәнлек белән баый бара. «Алсу» шигырендәге Алсу образы да катлаулы психологик антитезаларда ачыла. Ул да җанлы һәм үзенчәлекле бер образ булып күз алга баса. Әмма Алсуның матурлыгы аның тышкы портретында гына түгел. Хәтта Алсуның портреты гадәттән тыш саран детальләрдә күренә. Такташ Алсуны матур, сөйкемле дип кенә язып үтә:

«Бу — Алсуың синең,
Күрәсеңме,
Нинди матур булып утырган».

Хәтта рәсемнең дә артык гомуми сыйфатын гына — Алсуның утырып төшүен генә белдерә. Әмма аңа карап Алсуның матурлыгы, сөйкемлелеге югалмый. Шагыйрь аны портретының тышкы билгеләрен җентекләү аша түгел, ә күп төрле башка юллар, шигъри алымнар белән ача. Такташ Алсуның рухи матурлыгын тулылык, төгәллек белән сурәтли.

Поэзия белән сәнгать төрләре арасында туган үзара бәйләнешләрнең заманга хас үзгәрүен һәм аларның поэтикада да үзгәрешләр тудыруын Такташ гаҗәеп интуиция һәм сәнгатьчә такт белән сизеп алган шагыйрь булды.

Поэзия хәзер дә үзенең спецификасын тирәнрәк ачу юлыннан үсә. Шигырь теле белән генә әйтеп бирә торган мөмкинлекләрне эзли һәм таба. Җәлил, Туфан, Хәким, Давыдов кебек шагыйрьләрдә без шигърияттнең күп яңа ачышлар белән баюын күрер идек. Яшьләрдә дә кешенең матурлыгын шигъри тел белән ачу буенча матур табышлар бар.

Шулай да хәзерге поэзиядә һәр сәнгать төренең үз специфик йөзен тирәнрәк эзләүгә бәйләнештә туган яңалыкларга җитәрлек игътибар бирмәү дә юк түгел әле. Нинди дә булса күренешне яки вакыйганы эчке тирән шигъри мәгънәсе белән ачмаган шигырьләр, поэмалар да бездә басыла тора. Андый шигырьләрдә бүгенге тормышның тышкы билгеләре, бүгенге кешеләрнең тышкы сыйфатлары да юк түгел. Әмма шигырь өчен зарури булган шигърият, шагыйрьнең олы һәм кешелекле җаны юк аларда. Күренеш, вакыйгаларның тышкы яклары белән мавыгу, кеше рухының тирәнлекләренә үтә алмау поэзиябезнең үсеш юлында зур киртә. Моны, әлбәттә, сынлы сәнгатькә иярүдән генә килә торган кимчелек дип аңлату шулай ук беркатлылык булыр иде. Ул, бәренче чиратта, язучының талантына бәйле. Әмма бу юлы сүзне сәнгать төрләре, жанрларның үзара мөнәсәбәтләре, төрле тарихи чорларда үзләренең специфик чикләрен үзгәртүләре турында алып барабыз икән, сәнгать үсешенә, заманга һәм халыкның сурәтле фикерләвенә бәйле туган яңа хасиятләрне һәм ихтыяҗларны һич тә күздән ычкындыра алмыйбыз.

Тормышны эстетик танып-белүнең формалары һәм алымнары гаять хәрәкәтчәннәр һәм сыгылмалылар. Әдәби жанр һәм сәнгать төрләренең чикләрен дә катып калган, үзгәрми торган бер күренеш итеп күзаллау һич тә дөрес түгел. Татар халкының сурәтле фикерләве дә һәрвакыт хәрәкәттә. Ул чордан-чорга баый бара, чынбарлыкны тирәнрәк ачуның юлларын эзли һәм таба.

———□———

# Халык авыз иҗаты

## КУРГАН ТАТАРЛАРЫНЫҢ АВЫЗ ИҖАТЫ

Казан дәүләт университетының татар әдәбияты кафедрасы соңгы елларда Курган өлкәсендә яшәүче татарларның фольклорын җыйнады. Шулай итеп, моңарчы фәнни экспедицияләр тарафыннан өйрәнелмәгән бик күп иҗади байлык тупланды.

Курган өлкәсендә татарлар шактый тыгыз утырган ике район бар. Болар — Сафакүл һәм Әлмән районнары. 1965 елның җәендә безнең экспедицияләр бу районнарда булганнар иде.

1966 елда бер группа студентлар белән без Шадрин һәм Шатров районнарында булдык. (Җирле татар халкы аларны элек Шадрау һәм Шатрау дип йөрткән.) Күлләр, урманнар артында, тимер юлдан еракта Тагыл, Өчкен дип йөртелгән бу авылларда безнең студентлар шактый күп халык иҗатын таптылар. Бу як татарлары өчен характерлы күренеш — халыкта көйле озын җырларның бик күп булуы. Бәет, озын җыр, тарихи җыр боларда буыннан-буынга күчеп зур ихтирам белән сакланып килә икән. Көйле җырларны без магнитофон лентасына язып алдык. Тарихи озын җырлар арасында качкыннар турында, патша властеның җәберенә эләгүчеләр һәм 1812 елгы сугышта катнашкан егетләр турындагылары очрый. Патша түрәләре эзәрлекләвеннән качып Урал аръягына килеп чыккан Казан егетләре турындагы җырлар да бар. Шундыйлардан безгә бик ошаганы һәм бөтен Шадрин һәм Шатров районнарында популяр булганы «Габидулла бәете». Габидулла бәетенең язмышы бик кызыклы. Бу бәетнең кайбер строфаларын соңгы вакытта Пугачев восстаниесенә кагылышлы архив документлары арасыннан да таптылар. Безнең уебызча, Габидулла Казан ягы егете булып, Пугачев восстаниесендә катнашкан һәм ахырдан патша хөкүмәте тарафыннан сөргенгә җибәрелгән булырга тиеш. Бәетнең эчтәлеге, һәрхәлдә, шуңа ишарә ясый. Аннан соң, барлык җырлар арасында да Курган ягы татарлары бу җырны аеруча яраталар һәм картлар арасында моны белмәгән кеше юк диярлек.

Курган татарлары иҗатындагы бер үзенчәлек — бәетләрнең шигъри яктан бик нык эшләнгән һәм аерым көйгә салынган булуы. Аларның күбесен җырлардан аерып та булмый. Түбәндә китерелгән «Юркәй Юныс», «Һаммасадыйк мулла» һәм башкалар гасырдан-гасырга эшкәртелеп килгән тарихи сюжетлы җырларны хәтерләтәләр һәм алар бәет урынына түгел, ә мәҗлесләрдә җыр урынына җырланалар икән.

1965—1966 елларда Курган татарлары арасында җыелган озын җырлар һәм бәетләрнең бер өлешен укучыларга тәкъдим итәбез.

### Габидулла бәете

Бисмилланың әүвәл башы — вәл-гасери,
Егетләрнең кызга гыйшкын кыз яшерер [1].
Без көләек, без уйнык тереклектә,
Адәм угылы бердәнбер сер яшерер.

Агыйделнең аръягында җәйләгәнем,
Билләремә ефәк билбау бәйләгәнем.
Ай онытмам, ел онытмам, һич онытмам
Күкрәгеңә башым куеп йоклаганым.

Агыйделнең аръягында болыт тора,
Яңа ярлар иске ярны оныттыра.
Яңа ярлар табак белән аш китерә,
Иске ярлар ике күздән яшь китерә.

[1] Мондый строфа белән башланган озын җырлар, бәетләр татар, башкорт фольклорында еш очрый.

Агыйделдә үрдәк йөзә бата-калка.
Өсләрендә аның булыр алтын камка.
Егетләрнең ярдин-ярга йөргәненең
Колагына кидерерләр чуен алка.

Агыйделне иңләп-буйлап саллар килә,
Сал өстендә асыл кошлар сайрап килә.
Ул кошларны ефәк белән бәйләү кирәк,
Кызлар белән сөйләшергә хәйлә кирәк.

Карагайда кара җиләк унар микән,
Җыеп баксак савытларга тулар микән?
Кузыем, колынкаем Габидулла,
Илгә кайтып торыр көнең булар микән?

Кузыемның киткәненә өч ай тула,
Ниләр җәеп ята икән асларына?
Иркәм-колыным киткән чакта шуны әйтте:
«Үтенеп-үтенеп сәлам әйт, — дип, — дусларыма».

Мәскәүләрдән килгән, диләр, җирән кашка,
Башкаенда көмеш җөгән, бавы башка.
Иртән сәлам, кичен сәлам кара кашка.
Ни килсә дә килә, диләр, безнең башка.

Ат аранда, сыер ята бозау белән,
Әнекәсе чәчен тарый майлау белән.
Габидулла чыгып китте олау белән,
Әнекәсе күз бетерде еглау белән.

Үрдәк әйтә, казлар әйтә очам, диеп,
Казанның киң җиренә төшәм, диеп.
Шул Казанның киң җирләре тардыр безгә,
Бер ходаның боерыгы бардыр безгә.

## Биби ләй

Минем егетем шундый, Биби ләй,
Сагына аны бар кызлар, Биби ләй.
Эшләгәндә янып торган, Биби ләй,
Биш почмаклы йолдыз бар, Биби ләй.

Йөгереп керә, йөгереп чыга, Биби ләй,
Юка күлмәк комача, Биби ләй.
Кечкенә булсын, удалый булсын, Биби ләй,
Яшь күңелне шул ача, Биби ләй.

Кулымдагы йөзегемнең, Биби ләй,
Исемнәре гел Уел, Биби ләй,
Әйдә, җаныем, кавышаек, Биби ләй,
Кавышаек без быел, Биби ләй.

## Киленнәр җыры

Әнекәем, аш пешер,
Аз пешермә, күп пешер,
Аш ашаган чагында
Мине дә исеңә төшер.

Әнекәем, ястыккаем
Мамык булмаган икән,
Әнекәем, теләкләрем
Кабул булмаган икән.

Машинаның шунысы матур —
Утыргычы биектә,
Аерылганда әйтә алмадым
«Хуш, әнием», — диеп тә.

## Тагыл көе[1]

Ай, татлы йокымнан уянамын
Тагылларга үрдәкләр очканда.
Ай, мин үкенмим мал беткәнгә,
Мин үкенәм гомерем үткәнгә.
Ай, татлы йокыдан уянамын
Тагылларда үрдәк тавышына,
Иртә торсам хәсрәт ява башлый
Минем газиз мескен башыма.

## Байкал көе

Сибәләп кенә сибәләп яңгыр ява
Үтә микән үләннең төбенә.
Бу хәсрәтләрем дә бетәр микән
Әллә китәр микән гомеремә?

Ай, чылдыр ла чылдыр чылдырыйдыр
Аякларым тимер кандалда.
Күзен киткән кошлар кире кайта,
Кайтармыйлар безне анда да.

Таң мәлендә бер уянып китәм
Гүләп кенә кошлар очканда.
Ай, мин үкенмим баш киткәнгә,
Үкенәмен гомерем үткәнгә.

Ай, машиналарда без барабыз,
Төшеп кенә сулар алабыз.
Булмас инде безгә рәхәт дөнья
Әҗәл генә эзләп барабыз.

[1] Тагыл — Шатров районындагы зур күл исеме. Күл янына урнашкан авыл да Тагыл дип атала.

## Сары яфрак көе

Стенада алтын көзге
Матур күрсәтә йөзне.
Сары яфрак,
агып китте ялтырап.
Сәгать саен, минут саен
Сагынып сөйләем сезне.
Сары яфрак,
агып китте ялтырап.
Иртә торып су ташыем
Бакча эченнән генә.
Сары яфрак,
агып китте ялтырап.
Беркемгә дә сиздермием
Көям эчемнән генә.
Сары яфрак,
агып китте ялтырап.

## Аван Карманы көе[1]

Ак тастымалкаеңны мин бәйләдем,
Ак тастымалкаеңның кере бар.
Ник карыйсың, егет, ай, күземә,
Күкрәккәем тулы серем бар.

Ситса бидәр күлмәк мин апбирәм,
Камзулкайларыңны кисәнә.
Атинәндин[2] сорадым — бирмәделәр,
Үз генәем сөям, дисәнә.

Биеккәй лә тауның, ай, башында
Мәчет, мәдрәсәне кем салдикән?
Күкрәккәем тулы гамь-хәсрәт,
Бу гамь-хәсрәтне миңа кем салдикән?

## Тинес көе

Тинескәй лә буйлап йөргәндә лә,
Кәкүккәйләр кошын күрдеңме?
Сагынган ла чакта юк сәламең —
Саргаеп ла үлсен дидеңме?

Тинескәй лә елга, суы тирән,
Буй салганда буең буйламый.
Баш китәрлек эшне мин эшләдем
Акылларга салып уйламый.

Тинескәй лә елга, суы салкын,
Таш астындин агып ятканга.
Ат кынамнан төшеп суын эчтем
Яшь йөрәккә ялкын капканга.

---

[1] Аван Карманы — авыл исеме.
[2] Атинәндин — әти-әниеңнән дигән сүз.

Сикереп кенә төшеп ат бәйләдем
Мияс кенә буе муелга.
Минем генә кайгым бетәр микән,
Китәр микән гомерем буена?

Тинес кенә буйлап йөргән чакта,
Күк бурзайны алдым юлдашка.
Уңлап кына суллап кашым тарта,
Ниләр генә булды бу башка?!.

Тинес кенә буе Какчырлы күл,
Аермасы аның ни җирдә?
Күрдем исә күздән яшем ага,
Күп уйнаган идем шул җирдә.

Тинес кенә акмый, ай, тугайсыз,
Егет кеше йөрмәй уңайсыз.
Уңайларын табып йөргән ирләр
Коткара икән башын бер малсыз.

Тинескәйнең буе бигрәк ямьле,
Карман авыл мишәр өйләре,
Ишеткән лә күргән көйли алсын
Ах, молодцы, Тинес көйләре.

## Ем елга

Иртә белән торып уй уйладым,
Ем елгакайларын буйладым,
Ем елгакайлары аша чыккач
Башым кайтмас диеп уйладым.
Иртә белән торып бер карасам
Билгенәмә шашкы[1] бәйләнгән.
Ак кошлардин корбан чалыр идем
Ил генәмә кайтып әйләнсәм.

Ай яктылары бигрәк якты,
Ай каршында якты бер йолдыз.
Ак торнакай кебек мин зарланам.
Чит илләрдә үзем мин ялгыз.

## Рамай көенә

Уфа сөлгеләре бигрәк матур, Рамай,
Бәйрәм көннәрендә эләргә.
Безнең теләк шундый теләк, Рамай,
Бергә яшәп, бергә үләргә.
Ишеккәем алды таш керлисә[2], Рамай,
Җиз самовар кайный җил белән.
Маңгаеңа язган хак язмышны, Рамай,
Сыпырып ташлап булмый тир белән.

[1] Шашкы — кылыч.
[2] Керлисә — крыльцо, баскыч.

## Кәкүк

Ай-һай гына юлның кагыны[1],
Чаналарда атның баруы,
Шул вакытларда юк микән
Янган ла йөрәк даруы.
    Иртә беләп торып җимнәр бирдем
    Үз генәем сөйгән бөркеткә.
    Даулашмагыз гына безнең белән
    Җибәрербез сезне Эркеткә[2],

Анау да гына күлдә бөрәү чума,
Ак чабаккай кебек ялтырап;
Безне лә дошман сөйли микән
Теше-тешкә тими калтырап.

## Юркәй Юныс көе[3]

Җирәнчеккәй атның утлар җире
Тугай чардагының төяге[4].
Арысландай кебек, ай, ирләрнең
Төялепләй килде сөяге.
    Җирәнчеккәй менгән, камзул кигән
    Ике егет килә базардин.
    Мин курыкмыймын дошман, ай, сүзеннән,
    Мин куркамын башым азардин.

Бара гына торгач мин утырдым,
Ала елан басып үтердем.
Килә генә китә йөри торгач,
Газиз башкаемны бетердем.
    И-һа-һай лай дигән, ай, тавышка
    Кыр камасы кача камышка.
    Йокыларымдин уянып килдем
    Юркәй качты дигән тавышка.

Җирәнчеккәй атым мин бәйләдем,
Арка җиргә үскән савылга.
Тавышларым минем таулар яра,
Ишетелми микән авылга.
    Какчырлыдай күлнең ашасындин
    Күренә микән ак йон даласы?
    Шаркаена[5] басып язу язган
    Юркәй Юныс Кирәй баласы.

---

[1] Кагын — такыр юл.
[2] Эркет — Иркутск, бу урында сөргенгә мәгънәсендә.
[3] Юркәй Юныс — патша түраләренә протест йөзеннән бер төркем татарлар белән урманга качып, гомерен качкынлыкта үткәргән кеше дип сөйлиләр. Бу җырның бер строфасы башкорт фольклорчылары язган вариант белән туры килә.
[4] Төяк — Төбәк, яшәү урыны.
[5] Шаркаена — агач төбенә.

## Чәһри[1] асыл кыз бала

Ак куянкайларны мин качырдым,
Акбүз атка менеп бастырдым.
Чәһри асыл кыз бала...
Булыр гына булмас йомыш белән
Алдашып лай ишеген ачтырдым.
Сафьян итек, сары читек
Басма егет җиргә сай итеп,
Чәһри асыл кыз бала...
Иөремәләй ялгыз, кер куеныма,
Яшь гомереңне, егет, зай итеп.
Ак куянкай урак эз сала, ай,
Яңа туган ап-ак кар белән.
Чәһри асыл кыз бала...
Бу дөньяның бөтен рәхәте
Мәхәббәтле сөйгән яр белән...

## Һаммасадыйк мулла бәете

Һаммасадыйк[2] мулла намаз укый,
Намазлыгы аның әлмәле.
Һаммасадыйк мулла качып киткәч
Һичбер кеше аны белмәде.
Урта күлнең уртасында
Ике күгел[3] уйный парланып.
Һаммасадыйк мулла качып киткәч
Оркыясы йөри зарланып.
Какчырлы күлнең өсләрендә
Ак дулкыннар йөри чабышып,
Һаммасадыйк мулла оттыргачтын
Чәчләренә йөри ябышып.
Какчырлы күлнең суы тирән,
Буй салдисаң буең буйламый.
Баш китәрдәй эшләр эшләде
Гакылларга салып уйламый.
Һаммасадыйк мулла чапан кигән,
Чалмалары асыл ефәктән.
Каргамас та идем, атам, сине,
Мыскыл иттең мине бик яшьтән.
Какчырлы күлнең лә уртасында
Кычкыра бер үрдәк баласы,
Кычкырма син, үрдәк баласы,
Болай да әрни йөрәк ярасы.
Какчырлы күлне бик киң диләр,
Тик юк аны ярып үлчәүче.
Чегәнгә лә хатын, ай, булганчы
Батып кына әнкәй үлсәмче.
Какчырлыкай күлне бик киң диләр,
Агыйделгә аны тиңлиләр.

[1] Чәһри — йөзе.
[2] Һаммасадыйк — шул яктагы бер мәхәлләнең мулласы булган. Буыннан-буынга килгән легендаларга караганда, ул үзенең кызын чегәннәргә карта уйнап оттырган. Курган өлкәсендә бу бәет бик популяр. Аның үзенең көе бар.
[3] Күгел — үрдәк.

Аерылып ла калган үрдәккәйгә
Язмышымны минем тиң диләр.
Какчырлы ла күлнең ашасындин
Дулкын белән килә ак күбек.
Күңләмә лә, йөрәгем, ник күнлисең [1]
Артта калган хәлсез ат кебек.
Какчырлыкай буе куе камыш,
Бер ялгызы кычкыра тартар.
Очып кына илгә кайтыр идем,
Минем өчен дөнья бик тар, тар.
Ил генәем миннән ерак калды,
Басып карар идем — баскыч юк.
Эч кенәем минем ут күк яна,
Очып китәр идем, очкыч юк.
Какчырлыкай күлдә кара болыт,
Яңгыр булып килә күкрәп.
Күп хәсрәтләрне күрде инде
Әнкәй бүләк иткән күкрәк.
Какчырлыкай күлем, ямансыма,
Бер ялгызың түгел син җирдә.
Кайгырсам да куанамын уйлап,
Бер ялгызым түгел мин илдә.

## Ашказар

Ашказаркай буе куе камыш,
Күлнең өсте тора ялтырап.
Җанкай җанаш кайтмый, ай, сунардан,
Кайгылардан торам аптырап.
Арбалардан төшеп күлгә баксам,
Ак бурзае килә, үзе юк,
Кычкырыр идем — тавышым юк,
Кул болгар ла идем — яулык юк.
Ишеккәем алды, ай, керлисә,
Җиз самавыр кайный җил белән.
Сыйфатларын эшләп куяр идем
Җан кертеп лә булмый кул белән.
Һаваларда оча, ай, тилегән,
Канат ягын кара көйдергән.
Анадан да тумас, туса тормас,
Җанкай җанаш кебек сөйдергән.
Ишегемнең алды, ай, керлисә,
Керсәм генә чыксам уйланам.
Йокыларга китсәм, ай, куанам,
Төшләремдә күреп уянам.
Ишеккәем алды, ай, керлисә,
Җиз самавыр кайный җил белән,
Самавырлар кайнап, чәйләр пешкәч,
Инде эчим аны кем белән?
Тубылгы ла агач, ай, зур булмас,
Тубылгы да үтә юл булмас.
Йөз дә лә булмас, мең дә булмас,
Җанкай матур кебек ир булмас [2].

[1] Артта калган чабышкының үзеннән узып китүче атлардан күңләшеп борчылуы белән йөрәкне чагыштыру дип аңларга кирәк.
[2] Җырның кайбер строфалары «Башкорт халык җырлары» дигән китапта бар.

## Кәкуккәй көе

Бирсәнә лә, җанкай, кураемны,
Мин кәкуккәй көен тартаем.
Җибәрсәнә, җанкай, беләгемне,
Мин саксаул буйлап кайтаем.
Бәйләсәнә, җанкай, билбавымны,
Син бәйләсәң билем бушамый.
Сөйгән генә ярлар табылачак,
Холкы-фигыле сиңа охшамый.
Җирәнчеккәй атым бик юырсак,
Җилләр уйный аның артында.
Чаршау гына үтә каш сикертә,
Ни бар икән аның дәртендә.
Җирәнчеккәй атым, ай, тик тормый,
Сөлге салсаң тотмый билендә.
Кайберәүләр тора үз илендә,
Кайберәүләр сөйгән җирендә.

## Гаффә көе[1]

Безгә генә килгән сатучының
Алып бирче, әти, тиге бар.
Гаффә җаныемны матур диләр,
Уң битендә аның миңе бар.
Гаффә җаныкаем кайтып килсә,
Җитен торба җәям елгага.
Хак язганнары шулдыр инде,
Гаффә сылуым, зинһар, елама.
Гаффә матур такыя чигә,
Түр тәрәзәкәйнең түрендә.
Үз сөйгәнкәемне ятка бирдем,
Сызланмачы, әткәй, гүрендә.
Җиккән генә атым туры ала
Тубылдыккайларга урала.
Сөйгән генә ярын ятлар алса,
Йөрәк кенә маең суырыла.

## Сафа көе

Егет кенә булсаң, ай, егет бул,
Көмеш кыстыр каеш йөгәнгә.
Күп дошманнар безне күрәалмый,
Үзләрендин артык йөргәнгә.
Борылып та борылып юллар килә,
Мин кайсысы белән китәем?

Бер ай түгел, бер ел көттем,
Җаным сөйгәч ни хәл итәем.
Абзарыгыз сезнең якын икән
Күл буендин барып карарга.
Тәтәкәем быел, ай, чыкмаса
Без икәүгә килә зарарга[2].

---

[1] Җырның легендасы: Гаффә исемле кызны әтисе көчләп бай кияүгә биргән. Җыр Гаффәнең сөйгән егете тарафыннан чыгарылган, имеш.

[2] Көйнең легендасы: бер бай үзенең кече кызын, апасы чыкмас борын ярамый, дип кияүгә бирми. Кече кызның сөйгән егете була. Шул егетнең иптәшләре шушы җырны чыгарып, байның капкасы турыннан җырлап узалар, имеш.

## Сугыш бәетләре

Хәсрәтләрем бигрәк авыр
Ничек итеп әйтәем.
Дошман пулялары тиеп
Үлде газиз бәбкәем.
Дошман пулялары тигәч,
Харап булдым дигәндер.
Як-якларымда караңгы,
Ах, әнием, дигәндер.
Яшь йөрәгенә
пуля тигәндер,
Якты дөньялар
кала дигәндер.
Нурлы йөзләре
ап-ак булгандыр,
Шомырт күзенә
яшьләр тулгандыр.
Гөрләвек кебек
каннар аккандыр,
Бетәм, дусларым,
дип ул әйткәндер.
Зифа буйларын
сузып яткандыр,
Дошман каһәрең
төбәп аткандыр.
Шундук каберенә
күмелмәгәндер,
Канлы тәннәре
юылмагандыр.
Туфрак баскандыр
зифа буйларын,
Мәңгегә бетмәс
минем уйларым...
Сугышлар тагын
булмасын иде,
Аналар кан-яшь
түкмәсен иде.
Һәрвакыт кояш
елмайсын иде.

## 41 ел бәете

Мең тугыз йөз кырык беренче елларда
Дошман ут ачты безнең илләргә.
Шунда бәндәләр корбан булдылар,
Туган илләргә кайталмадылар.
Балалар калды ятим — эткәсез,
Аналар калды газиз бәбкәсез.
Минем дә бәбкәм шунда юк булды,
Дошман уклары илгә ут булды.
Газиз бәбкәем унҗиде яшьтә,
Йоклап йокысы туймастай чакта,
Йөрәгем парәсе китте еракка,
Яшьлек таңнары чәчәктәй чакта.
Инде кайтмас ул күпме көтсәм дә,
Хәсрәтем бетмәс ничек итсәм дә.
Бу кайгыларны күп күрде ана,
Ана йөрәге ут булып яна.

---

Җырларны һәм бәетләрне II курс студентлары В. Әхмәтҗанов, Н. Әхмәдиев, С. Хәйдәрова, С. Таһирова, Ф. Галиев, Р. Сәлаховлар Шатров һәм Шадрин районнарында язып алдылар.

III курс студентлары Р. Вәлиев, С. Хафизов, Ә. Габдулкаева, Н. Бакыева, З. Хөснетдинов, Ә. Сабитова, Р. Әхмәтҗановлар Сафакүл районында язлылар.

Сүз башы һәм текстлар М. Мәһдиев тарафыннан әзерләнде.

1965—1966

# БЕРЕНЧЕ КИТАП ҺӘМ БАЛАЛАР ӘДӘБИЯТЫ

Соңгы елларда татар әдәбияты шактый үнышка ирешге. Ләкин бу уңыш, нигездә, проза белән поэзиягә туры килә. Әдәбиятның башка жанрлары исә һаман койрыкта өстерәлеп баралар. Шул койрыктагыларның берсе — балалар әдәбияты.

Балалар әдәбияты дигәндә мин балаларга атап язылган барлык әдәбиятны күз алдында тотмыйм. Мин бары тик балалар әдәбиятындагы проза белән генә чикләнмәкче булам. Кайбер уңышлары булуга да карамастан, балалар прозасы, минемчә, бер урындарак таптана. Анда күбесенчә сөйләү, схематизм һәм фантазия ярлылыгы өстенлек итә. Бездә балалар горурланып укырлык революцион китаплар да, йотлыгып, хыялланып укырлык фантастик һәм мажаралы әсәрләр дә юк дәрәҗәсендә.

Ә бит болай өстән генә караганда, без һич тә ярлы түгел сыман шикелле. Балаларга атап махсус газета, журнал чыгарыла, Татарстан китап нәшрияты ел саен китаплар бастыра. Шулай ук әледән-әле яңа исемнәр дә күренгәли.

Язучы Роберт Батуллинны, мәсәлән, мена шул яңа исемнәр рәтенә кертергә мөмкин. Р. Батуллин балалар өчен кечкенә хикәяләр, сәхнә әсәрләре һәм зур күләмле әсәрләр иҗат итә. Былтыр аның беренче китабы — «Исемем минем Дүрткүз» дип аталган повесте басылып чыкты.

Дүрткүз дип аталган көчек, нефтьчеләргә ияреп, шәһәргә китә. Анда ул төрле хәлләргә юлыга, «артист» була, пароходка эләгеп чит илгә барып чыга. Иң соңыннан Дүрткүз, дәүләт чиге аша үтеп, кире үзе безнең якка чыга һәм туган авылына кайтып житә.

Автор үзенең әсәрен шактый мажаралы итеп корган. Монда сина качып китүләр дә, адашып калулар да бар. Монда шулай ук кечкенә укучыга беркайчан да тынгы бирми торган шпионнар да, сугышлар да, диңгез һәлакәтләре дә бар. Боларның барысы да ике төрле тормыш — бездәге һәм чит илдәге тормыш фонында күрсәтелә.

Кагыйдә буларак, балалар өчен язылган әсәрләр җиңел укылырга, кызыклы һәм мавыктыргыч булырга тиеш. Безнең күп кенә хикәяләргә менә шул мавыктыру көче житми. Традициягә әйләнгән күңелсезлектән качарга тырышып, автор, әлбәттә, дөрес эшләгән. Ләкин шулай да яшь язучы каш ясыйм дип күз чыгара. Ул бер чиктән икенче чиккә ташлана. Китаптагы бер-берсенә өелгән мажаралар, көтелмәгән хәлләр билгеле бер максатка юнәлдерелмәгән һәм нинди дә булса логикага, эчке үсеш таләпләренә буйсындырылмаган.

Һәрбер әсәрнең, шул исәптән мажаралы, фантастик әсәрнең дә, үзәгендә төп герой була. Көтелмәгән хәлләр, вакыйгалар төп геройның эшенә, хәрәкәтенә бәйле рәвештә тасвирлана. Әдәби герой төрле каршылыкларга очрый, шул каршылыкларны җиңеп чыга, алга, үз максатына омтыла. Менә шушы көрәш, омтылышта геройның эчке дөньясы ачыла. Көтелмәгән хәлләр аша автор укучыны шулай ук табигатьтәге, фән һәм техникадагы яңа, ят нәрсәләр белән дә таныштырырга мөмкин.

Р. Батуллинның әсәрендә төп герой итеп, әйтелгәнчә, Дүрткүз исемле эт алынган. Хикәяләү беренче заттан алып барыла — эт үзенең күргәннәрен үзе «сөйли». Эт «күзлеге» аша язучы кешеләр тормышын тасвирлый. Дүрт аяклы герой искиткеч җиңеллек белән бер җирдән икенче җиргә, бер хуҗадан икенче хуҗага күчә. Үзенчә ул кайбер батырлыклар да эшли. Ләкин күбесенчә аны язмыш, дөресрәге, автор ихтыяры йөртә.

Шулай итеп, әсәрнең башыннан алып азагына кадәр Дүрткүз көрәш, омтылыш сыйфатыннан мәхрүм ителә.

Дөнья әдәбиятында этләр, атлар һ. б. хайваннар турында язылган гүзәл әсәрләр бар. Мондый әсәрләрдә язучы, гадәттә, хайваннар дөньясына «үтеп керергә» тырыша, аларның психологиясен, теге-бу карашларын, омтылышларын тасвирлый, һәм дүрт аяклы геройлар беркайчан да кеше «ягына» чыга алмыйлар, ягъни беркайчан да кешегә әйләнә алмыйлар.

Р. Батуллинның Дүрткүзе кеше «ягына» чыгу гына түгел, арттырып та җибәрә: ул хәтта кайбер кешеләр белмәстәй нәрсәләрне дә белә. Димәк, Дүрткүзнең эт табигате юкка чыга, эт кешегә әйләнә. Ләкин аны чын мәгънәсендә кеше дип тә булмый. Хикәя героеның менә шундый икеле-микеле хәле укучыда шик тудыра. Шикләнү тора-бара ышанмауга күчә. Әсәрнең төп герое итеп кеше алынса, ихтимал, китап отышлырак булыр иде.

Шуның белән бергә, яшь язучының бу беренче китабында һәртөрле ялгышлар, уйлап җиткерелмәгән нәрсәләр күзгә ташлана. Мәсәлән, Дүрткүз — бернәрсәгә өйрәтелмәгән гап-гади бер авыл эте. Шулай да ул шәһәрдә һәркемне шаккатырырлык һөнәрләр күрсәтә башлый — «укымышлы» эткә, овчаркага әйләнә. Автор Дүрткүзнең нинди чит илдә булуын әйтми. Ләкин аның Төркияне күз алдында тотканлыгы укучыга бик яхшы аңлашыла. Шуңа күрә, Дүрткүз йөргән чит илне Төркия дип аңларга безнең тулы хакыбыз бар. Шәһәр башлыгын яшь язучы «паша» дип атый. Бер-ике биттән соң шул ук «паша» «вәли»гә әйләнә. Бездә «губернатор» яисә «фельдмаршал» титуллары күптән юкка чыккан кебек, «паша» да Төркиядә күптән кулланылмый. Чик аша чыкканда Дүрткүз кобра дип аталган елан белән сугыша. Безнең илдә кобра еланы Кавказда юк, бары тик Урта Азиянең көньягында гына очрый.

Яисә тагын бер мисал. Сула исемле төрек диңгезчесе: «Мин бүген үз милләтемә каршы үлем җибәрәчәкмен. Шах Кипрга һөҗүм итә», ди. Күрәсең, автор моннан берничә ел элек Кипрда булган киеренкелеккә ишарә ясый. Тик монда бөтен нәрсә буталып бирелгән. Беренчедән, Төркия белән Кипр арасындагы каршылык «үлем җибәрү»гә, ягъни сугыш дәрәҗәсенә үк барып җитмәде. Икенчедән, Төркия төрегенең Кипрдагы «үз милләтенә» каршы «үлем җибәрүе» шулай ук сәер һәм хата. Өченчедән, «шах» — Иран дәүләтенең башы. Иран белән Кипр арасында бернинди дошманлык юк. Дүртенчедән, «шах» түгел, «шаһ» яисә «шаһиншаһ». «Шах» — шахмат уены термины.

Күрәсез, кыска гына бер-ике җөмләдә никадәр хата! Кайберәүләргә мондый хаталар вак нәрсә булып тоелырга мөмкин. Ләкин китап язу — бала-чага уены түгел, һәм монда вак, кечкенә нәрсә була алмый. Монда сүз генә түгел, хәреф тә, нокта да, өтер дә үз урынында һәм кирәгенчә генә булырга тиеш.

Әйтергә кирәк, ташка басылган язуның дөреслегенә, ачыклыгына игътибар бирмәү бездә шактый тамыр җәйгән. Китапларда, газета, журнал битләрендә иң гади, элементар нәрсәләрнең дә ялгыш басылуын күреп минем җен ачуларым кила. Бу безнең гомуми культура дәрәҗәбезнең түбән булуын һәм иҗат эшенә җавапсыз каравыбызны күрсәтә түгелме соң?

Һәртөрле хаталар, ялгышлар үзең тасвирлаган материалны яхшы белмәү аркасында гына түгел, бәлки туган телне белмәү, аның тәмен, төсен, музыкаль яңгырашын һәм эчке законнарын кирәгенчә аңлый алмау аркасында да китәргә мөмкин. Телгә карата игътибарсызлык, каләм тибрәтә башлаган кайбер яшьләргә нәреп, әдәбиятка, вакытлы матбугатка да үтеп керә. Язу-сызу белән шөгыльләнүче яшьләрнең тел байлыгы, телгә карата сизгерлеге бик чамалы. Алар кайчагында гап-гади фикерне дә татарча ачык һәм төгәл итеп яза белмиләр.

Мәсьәләдән беркадәр читкә китеп булса да, мин монда күптән түгел булып узган бер дискуссиягә әйләнеп кайтмакчы булам. Бер елдан артык дәвам иткән әлеге дискуссиядә, күп кенә мәсьәләләр белән бергә, татар поэзиясендәге форма тенденцияләре турында да сүз булды. Яшьләрнең кайберләре поэзиядә «иркен» дип аталган форманы артыграк куәләр. «Казан утлары»ның беренче санында (1967 ел) яшь шагыйрь Ренат Харисов янадан «иркен»челәрнең карашларын яклап чыкты. «...Шигырьне шигырь иткән чаралар рифма һәм калып ясый торган ритм белән генә чикләнмиләр ич. Әгәр дә шигырьдә бары шушы ике генә «җитешсезлек» бар икән — «куркыныч түгел», дип яза Р. Харисов.

Китерелгән өзеккә игътибар итегез — менә сезгә яшьләр теленнән бер мисал: рифма һәм калып ясый торган ритм... Автор, билгеле, рифма һәм калып турында

түгел, рифма һәм ритм турында әйтергә тели. Ләкин аның рифма һәм ритм турында әйтергә теләгән фикере дә «рифма һәм калып ясый торган» «ритм» шикеллерәк яңгырый.

Әйтик, рифма ул кадәр үк мәҗбүри дә түгел ди. Ә ритм? Мин, мәсәлән, шигырьдә генә түгел, *проза* әсәрендә дә ритм *мәҗбүри* дип исәплим. Ритм ул кемдер юри уйлап тапкан нәрсә түгел. Ритм шулай ук иҗекләр саны гына да түгел. Киң мәгънәсендәге ритм — табигый күренеш.

Үз теленең серенә төшенмәгән һәм читтән килгән һәр модага иярүне алдынгылык, оригинальлек дип исәпләүче кайберәүләр менә шушы табигый ритмны танымаска тырышалар. Ритмсыз язу хокукын яклау ул иҗат ирегең, форма ирегең яклау түгел, бәлки туган телгә карата игътибарсызлыкны, тел шапшаклыгын һәм сәнгатьсезлекне яклау булып тора.

Инде янадан Р. Батуллин китабына күз төшерик. «Исемем ~~минем~~ Дурткуз»... исемем минем... мм... Кычкырып әйтеп карагыз — берәр нәрсә сизеләме? Сизелә. Әле генә телгә алган ритмның юклыгы сизелә. Тар әйтелешле «м» авазлары бер тирәгә җыелган, шуңа күрә китапның исемен укыганда нәрсәгәдер абынып, төртелеп каласың шикелле. Сүз сайлауда автор үз-үзенә карата таләпчәнрәк булса, китабына, әлбәттә, мондый «абындыра» торган исем куймаган булыр иде.

Яшерен-батырын түгел, Роберт Батуллинның теле коры, төссез. Аның әле үз ритмы, үз стиле сизелми. Әлегә аның теле тәрҗемә телен хәтерләтә. Менә кайбер мисаллар: *«Мин үзем дә аның авызына әләгүдән ерак йөрим»; «Күзләрем шәп күрәләр»; «Чатырдан берничә ир һәм хатынкыз чыктылар»; «Хуҗам шул көй астында ашарга әзерләргә керешә»; «Бер-икесе юлдан ерак түгел яткан такта кисәкләренә таба йөгерде»; «...Шунда аның күзләре миңа төштеләр»; «Ул мөмкинчелекне әниең тудырыр»; «...Искитмәле хикмәтле күнегүләр күрерсез»; «Аннан күзем кая караса, аякларым шунда атлады»; «...Ачлык һәм сусау үзләренекен иттеләр»* һ. б. һ. б.

Күренеп тора, яшь язучының беренче китабы бик үк уңышлы булып чыкмаган. Шулай да бу бары Батуллинның гына уңышсызлыгы түгел. Бу уңышсызлык гомумән бүгенге балалар прозасының торышын чагылдыра кебек.

Автор тәнкыйтькә колак салыр һәм киләчәктә, һичшиксез, уйлабрак, тырышыбрак язар дип өметләнергә кирәк. Ләкин киләчәктә, әйтик, Р. Батуллинның яхшырак әсәр язуы белән генә бөтен балалар прозасы яхшырырмы? Бу турыда әлегә берни әйтеп булмый.

Балалар әдәбиятын үстерү турында ныгытыбрак, бергәләбрәк кайгырту дөрес булмасмы? Балалар өчен язучылар ничектер үз казаннарында гына кайныйлар. Тәҗрибәле язучыларга, күрәсең, менә шул «казан»ны ватарга, «казан»дагылар арасына үтеп керергә һәм аларның кимчелекләрен ешрак күрсәтергә, булышырга, өйрәтергә кирәктер? Каләм осталары, «олы башларын кече итеп», нәниләр өчен, балалар өчен үзләре дә иҗат итсәләр, тагын да яхшырак булыр иде. Дөрес, кайберәүләр бу эштә үрнәк күрсәткәли, тик шулай да берәм-сәрәм «кайберәүләр» генә мәсьәләне тамырыннан үзгәртә алмыйлар.

Нурихан ФӘТТАХ.

—●—

# ӘСӘР ХАКЫНДА БЕРНИЧӘ СҮЗ

Бер танышым аша «Казан утлары» журналының 1, 2, 3 саннары кулыма төште... Шул саннардан Әхсән Баяновның «Яшьлегемне эзлим» исемле повестен укып чыктым. Дөресен әйтергә кирәк, әсәр миңа ошады. Билгеле, миңа журналның әлеге саннарын тәкъдим иткән кешегә дә ошагандыр, ошамаса — тәкъдим итмәс иде. Әниснең туган җир турында уйланулары, Әнис белән Фәһимәнең дуслыгы, Әниснең Ленага карата булган тойгылары — барысы да бик дөрес язылган, әйтерсең, тормышның үзеннән алынган. Повестьта безнең барыбызга да якын Агыйдел сурәтләнә, аннан соң миңа таныш Яркәй, Ишкар, Исмаил һәм Башкортстанның Илеш районына кергән башка авыллары очрый. Ә Илеш — безнең күрше район.

Аннан соң әсәрдә безнең буын кешеләренең бала чагына туры килгән авыр сугыш еллары һәм сугыштан соңгы чор бик дөрес чагылдырыла. Һәркемнең исендә калырлык бик авыр еллар иде шул. Болар барысы да әсәрне миңа бик якын иттеләр.

Ләкин мин әсәрнең азагында сурәтләнгән Әнис, аның уй-тойгылары, карашлары белән килешә алмыйм. Лена белән соңгы мәртәбә очрашканнан соң, Әнис үз алдына болай дип кала: «Кара көннәремнең матур һәм бәйләнчек юлдашы! Я, хуш, вакытлыга түгел, мәңгелеккә».

Әнис кайчандыр Ленаны ярата иде бит. Ул әле дә аңа карата тыныч түгел. Ә нигә соң шул «кара көннәрнең матур һәм бәйләнчек юлдашын» ул «кара көннәр» белән ташлап калдыра!..

Билгеле, безнең заманның кайбер кешеләрендә искедән калган карашлар әле дә юк түгел. Ләкин безнең заманның уңай герое шундый күренешләргә, шундый начар гадәтләргә каршы көрәшергә тиеш иде.

Дөрес, квартирадан Шәһиәхмәтовларны куып чыгаруда да Лена гаепле, Әнис консерваториягә киткән чакта, аны Уфада калырга «үгетләүче» дә шул. Әнис бит боларның барысын да аңлап торды. Ләкин Ленага ярдәм итәргә, аңа хаталарын аңлатырга тырышып карамады. Лена каршында аның үз намусы да чиста түгел бит. Лененың бәхетсез булып калуында Әнис тә гаепле түгелменн!.

Аннан соң: «Лена — бәхетсез, аныңча яшәп калган булсам, мин дә аның төсле булыр идем», — ди бер урында Әнис. Бу сүзләрне туры мәгънәсендә аңлаганда, болай килеп чыга түгелме: «Әле дә аның белән калмагонмын, мин дә бәхетсез булыр идем». Бу үз бәхетең өчен генә омтылу түгелме!.. Болар бит 17 яшьтәге егет акылы белән әйтелгән сүзләр түгел. Әгәр Әнис вакытында Ленага ярдәм итсә, аны да укырга өндәсә (хәзер дә соң түгел иде әле), Лена аның кебек кеше булмас идемени! Лена бит Әниска булган мәхәббәте хакына әллә ниләр эшләргә әзер иде. Ә тормышта әзмыни шундый очраклар!

Әлбәттә, намус һәм бәхет турында Әнис бик матур фикер йөртә (мин язып тормыйм). Ләкин шул матур сүзләр урынына, Ленага һәртөрле зарарлы карашлардан арынырга булышса — бу Лена өчен дә, Әнис өчен дә файдалырак булыр иде.

Кадерле редакция! Мин повесть турында кайбер уй-фикерләремне генә яздым. Әсәрнең идеясенә тукталмадым. Бәлки, аның идеясе дә шул Әнис образын дөрес чагылдыруга бәйләнгәндер.

Л. ӘХМӘДИЕВА,
Башкортстан.

—□—

# МИН ҮКЕНМИМ

Безнең Илеш районында «Казан утлары» зур популярлык белән файдалана. Аны укучылар саны елдан-ел арта бара. Әгәр узган 1966 елда 400 дән артык журнал алдырылган булса, 1967 елда бу журналга 900 дән артыграк кеше язылды. Моны басылып чыккан әсәрләрнең эчтәлеге һәм тематик яктан төрле-төрле булулары белән аңлатырга кирәктер.

Мин «Казан утлары»н «Ак чәчәкләр» (Г. Әпсәләмов), «Муса» (Ш. Маннур) романнары басылганнан башлап, системалы рәвештә укып барам. Һәм журнал кулдан кулга йөреп, тузып бетә торган була башлады.

Якташыбыз Әхсән Баяновның журнал битләрендә чыгып килгән шигырьләре бездә шулай ук уңай тәэсир калдыра. Укучы сыйфатында, аның соңгы әсәре — «Яшьлегемне эзлим» лирик повесте хакында бер-ике сүз әйтәсем килә.

Әсәр турында объектив караштa торуымда шик тә булырга мөмкин түгел. Чөнки мин аның замандашы диярлек (1—2 яшькә генә зуррак). Ул 7 класста укыганда, мин Ишкар мәктәбендә укытучы булып эшләдем (1942/43 уку елы). 1943—1951 елларда Совет Армиясендә хезмәт иттем. Яшьлегебез бер чорда узган кешеләр булгач, әсәрдә язылган вакыйгалар турында да үз фикеремне язу дөрес булыр дип исәплим.

Әхсән Баянов Ватаныбыз өчен авыр булган чор — сугыш елларын һәм тылдагы хезмәтне чагылдырган. Сайлаган темасы, минемчә, урынлы. Авырлыкларны, берсен дә яшермичә, ачып салган. Шулай ук, дәһшәтле сугыш елларыннан соң, тылдагы матур тормышның башлангычын да күрсәткән.

Ләкин сайланган теманы ачып бирүдә артык натурализм күрсәткән кебек күренә. Образлар (әгәр шулай атасак) бик примитив бирелгәннәр. Гомумиләштерүче чаралар юк, дисәк тә була. Бу әсәрдә Ленадан башка образлар үз исемнәре белән бирелгән.

Әсәрнең төп линиясен Әниснең иләсмиләс мәхәббәте билән тора, дисәк тә ялгыш булмас. Аның үзенә профессия сайлап йөрүе артык күп яктыртылган.

Чор белән геройлар арасындагы бәйләныш рус әдәбиятында (аның кече туганы татар әдәбиятында да,) иң яхшы традиция бит. Гражданнар сугышы Д. Фурмановның «Чапаев»ын, А. Фадеевның «Тармар»ын һ. б. тудырды, коллективлаштыру — М. Шолоховның «Күтәрелгән чирәм»ен барлыкка китерде һ. б.

Ватан сугышы чорында яшүсмерләр фронтта гына түгел, тылда да, тыныч вакыттагыга караганда, иртәрәк формалаштылар. Ә безнең Әнисебез, 7 классны бетергәч, кош оясы туздырып, укырга кергән техникумын ташлап кайтып, аның яшьтәшләре (1927 елгылар) җиңү көнен фронтта тантана иткәндә базарда йөри. Шулай да «герой» үзе турында югары фикердә: «Минем гомеремнең яртысы үземнең кешелек дәрәҗәмне югалта язганда саклап калу, теләсә нинди кыенлыкларда да төшермәү, үземнең «мин»емне һәртөрле япганнан, түбәнчелектән азат хәлдә тоту, горур шәхесемне раслау өчен көрәшеп узды» («Казан утлары». 1967 ел. 3 сан. 50 бит).

Мещанлыкка каршы нәфрәт, гаделсезлеккә каршы тору — ул һәрбер совет кешесенә хас сыйфат. Моның белән генә шаккатырып булмый.

Уңай образ проблемасы совет әдәбиятында хәл ителгән нәрсә. Ләкин әсәрдә ул сыек. Әсәр сентиментализмга да бик якын тора. Әйтик, Фәһимә образы Н. М. Карамзинның «Бедная Лиза»сындагы шул Лиза түгелмени! Шундый ук тыйнак, җырчы, үзенең мәхәббәте өчен көрәшми, мылтыктан атылып үлә. Нигә аны үтерү кирәк булгандыр!

Әнис, Лена, Фәһимә образларын М. Ю. Лермонтовның «Безнең заман герое»ндагы Печорин, Вера, княжня Мэри белән чагыштырсак та начар булмас. Кияүгә чыккач та Әнисне яратучы шул ук Вера — Лена, шул ук Мэри — Фәһимә.

«Мин тагын бер ачыш ясадым: күңелең белән аерылышырга һәр минут әзер торсаң да, яратмасаң да, һичнәрсә дәгъва итмәсәң дә, үзең белән бәйләнештәге кешеңнән аерылу — барыбер фаҗига, син аны барыбер көнлисең...» (3 сан. 44 бит). Бу юллар Печоринның Верадан аерылганнан соң булган кичерешләренә охшаш.

Повесть ахырындагы символика да бу ике әсәрне чагыштырырга нигез бирә. Менә ул: «Кая да булса китәргә... Әйе,

Лермонтов геройлары янына. Кырыс чынбарлыктан хыял иленә. Бүтән барыр җир, бүтән максат күрмим... Бәлки чынбарлыктан шул юл белән котылырга, бөтенләй башка җиргә, материал кысанлыктан идеаль киңлеккә чыгарга... Тирә-ягымда матур-матур киенгән кызлар. Аларның кайсы Мэри икән дә, кайсысы Вера икән». (3 сан. 39 бит.)

Лермонтов яшәгән чор, аның геройлары белән хәзерге чор (1946 еллар) һәм совет әдәбияты геройлары арасында нинди уртаклык бар соң! Лермонтов үзе яшәгән чордагы җәмгыятьне фашлаган. Ә хәзерге чор әдәбияты, киресенчә, тормышны раслый. Әдәбиятның бурычы — вакытлыча кыенлыкны үтү юлларын ачыклау. Романтизм һәм социалистик реализмның нинди уртаклыгы бар соң!

Әсәрдә хезмәт темасы үзенә тиешле урынны таба алмаган. Автор, әгәр Әниснең мәхәббәтен күрсәтәсе килсә, аны печән өмәсенә, Агыйдел якларына илтә, Өфе шәһәренә алып бара; әгәр Әниснең принципиаль булуын күрсәтәсе килсә, бодай башы кыркучылар янына илтә, ашлык урлаучы иптәше артыннан йөртә.

Кайда соң колхозчыларның фронт өчен чын фидакарь хезмәте! Хезмәттә чыныккан кешеләре!..

Печорин үзенең сәләтенә урын таба алмаган. Әнис тә сугыш бетеп, үзенә 20 яшь тулгач кына юнәлеш таба. Шуны әйтәсе килә: Баяновтан, яшь, сәләтле язучы буларак, алынган проблеманы социалистик реализм күзлегеннән чыгып хәл иткән, укучыларда әхлак тәрбияләрлек әсәрләр көтәбез. Һәр язучының үз стиле бардыр, әлбәттә. Ләкин бер шәхес артыннан укучыны ияртеп йөртү, шулай ук геройны индивидуалист итеп сурәтләү урынсыз, минемчә.

Бу, билгеле укучы сүзе генә. Безнең зур әдипләребез, танылган тәнкыйтьчеләребез бар. Соңгы сүзне алар әйтер.

Минем исә, гади укучы сыйфатында, шуны гына әйтәсем килә: әсәрнең исеме — «Яшьлегемне эзлим»... Аңлашылып бетми. Ул яшьлеген кемнән дә булса таләп итәме, нәрсәгәдер үкенәме! Мин, аның замандашы буларак, үкенмим.

Г. НӘҖМЕТДИНОВ,
Башкортстан, Илеш районы.

——□——

# *Түгәрәк өстәл тирәсендә*

*Сәгыйт Таҗетдинов*

## УКУЧЫЛАРГА ҖАВАП

«Казан утлары» журналының узган елгы 10—12 саннарында «Үлемнән яшәүгә» исемле документаль повестем басылып чыккач, минем үземә дә, журнал редакциясенә дә шактый күп хатлар килде. Ул хатларны төрле яшьтәге һәм төрле профессия кешеләре язган. Хат авторларының барысы да әсәрне яратып укуларын әйткәннәр. Ул хатларның икесе «Казан утлары»ның бу елгы 7 нче санында басылып та чыкты инде. Әмма алар күп, шунлыктан барысын да бастырып бетерү мөмкин түгел. Шулай да тагын ике хатны журнал укучыларына тәкъдим итәсем килә. Менә алар:

«Кадерле Сәгыйт Абдуллович!

Без Сезнең «Үлемнән яшәүгә» исемле повестегызда сурәтләнгән әсирләрнең — социалистик илебез кешеләренең батырлыгына, ныклыгына сокланабыз. Фашистлар тарафыннан коточкыч каты җәберләнүләренә, кимсетелүләренә карамастан, коммунистлар партиясенә, туган илебезгә турылыклы булып калган һәм шундый кыен шартларда да ирекка чыгу өчен, дошманны җиңү өчен көрәшүләрен дәвам иткән ул кешеләргә сокланабыз. Без фашизмны күрәалмаска, тынычлык өчен көрәшергә һәм бөтен тормышыбызны туган илгә хезмәт итүгә багышларга вәгъдә бирәбез.

Оренбург, 64 нче мәктәпнең 8 нче класс укучылары».

«Повестегызны укып чыктык. Сезгә сәламәтлек һәм рух күтәренкелеге телибез. Сезнең әсәрдәге геройлар кебек булырга тырышырбыз. Тынычлык өчен, коммунизм өчен көрәшербез.

Оренбург педагогия институтының тарих-филология факультеты студент-комсомолецлары».

Бу хатка 150 комсомолец кул куйган.

Дөресен әйтергә кирәк, повестем басыла башлагач, укучылар аны ничек каршылар, ошатырлармы, юкмы икән, дип шактый нык борчылган идем мин. Чөнки мин профессиональ язучы түгел бит, әдәбиятны яратсам да, язучыларыбызның әсәрләрен күп укысам да, кулыма каләм алып үзем әсәр язып караганым юк иде. Әмма башымнан кичкән хәлләр, әсирлектә үлеп калган күп кенә иптәшләремнең якты истәлекләре соңгы елларда миңа тынгылык бирмәде. Күңелем алар турында сөйләүне, аларның исемнәрен халыкка җиткерүне таләп итте.

1960 елда миңа сугыш елларында фашистлар кулында тоткынлыкта булган кешеләр җыелышында катнашырга туры килде. Мәскәүдә үткәрелгән ул җыелышта мин күп кенә танышларымны да очраттым. Алар да миннән, Дахау тоткыннарының фашизмга каршы көрәше турында язып, хакыйкатьне халыкка җиткерүемне үтенделәр. Җыелышта да тоткыннар тормышы турында язарга киңәш иттеләр безгә. Менә шуннан соң мин Дахау концлагере турында мәгълүматлар җыярга тотындым: үзем белән әсирлектә булган һәм хәлләреннән килгәнчә фашистларга каршы көрәш алып барган иптәшләр белән бәйләнешкә кереп, алар белән киңәштем, сөйләштем, фактларны ачыкладым. Бәхеткә каршы, Дахаудан исән котылган иптәшләрем шактый булып чыкты һәм алар миңа байтак кына материаллар җибәрделәр. КПСС Үзәк Комитеты

арнылы үзем белән тоткында булган чит ил кешеләре белән дә элемтәгә кердем һәм алардан да хатлар ала башладым. Кайбер иптәшләр белән газеталарда басылган хәбәрләр аша таныштым. Иосиф Лаушер һәм Зубка Франтишеклар белән, мәсәлән, шулай табыштым. Алар (Иосиф Лаушер Австрия Коммунистлар партиясе делегациясе составында, Зубка Франтишек профсоюзлар съездына) Мәскәүгә килгәннәр иде. Бу иптәшләр дә минем ниятемне хуплап хат яздылар һәм байтак кына мәгълүматлар бирделәр. Аннары мин тәвәккәлләп кулыма каләм алдым һәм шушы повестьны яздым да укучылар хөкеменә тапшырдым.

Журнал укучыларыннан килгән ике меңләп хат һәм телеграммаларны мин әсәремә карата хөкем карары дип кабул итәм һәм, яшермим, ул хөкемнең минем өчен куанычлы булуына шатмын.

Ул хатлардан тагын шул хәл ачык күренә: хәзерге укучыларыбызның аң-белеме, культурасы бик нык алга киткән икән. Алар әдәби әсәрне бары тик кызыклыгы өчен генә укымыйлар, бәлки аның эчтәлеген, максатын да дөрес аңлыйлар икән. Хат авторларының күбесе «Үлемнән яшәүгә»нең әһәмиятен, аның яшьләребезне патриотик рухта тәрбияләргә ярдәм итәчәген әйткәннәр. Мин үзем дә шуны күздә тотып язган идем бу повестемны. Димәк, максатыма ирешкәнмен. Очрактан файдаланып, әсәремә карата фикерләрен язып җибәргән иптәшләрнең барысына да рәхмәт әйтәсем килә.

Хат авторларының күбесе повестьта сурәтләнгән кешеләрнең язмышлары белән кызыксына, аларның хәзер исәнме, юкмы, исән булса, кайда яшәүләрен, кем булып эшләүләрен сорап язалар. Бу сорау хат авторларын гына түгел, башка укучыларны да кызыксындыра торгандыр дип, түбәндә повесть персонажлары хакында кыскача мәгълүмат биреп китмәкче булам. Аларның байтагы исән әле.

Илларион Андриевич Пановка хәзер алтмыш биш яшь. Ул Мәскәүдә яши һәм төзелеш трестларының берсендә кадрлар бүлеге начальнигы булып эшли.

Латиф-Зада алтмыш ике яшьтә. Башта Сәмаркандта яшәде, ә хәзер Кавказда яши һәм ял йорты начальнигының ярдәмчесе булып эшли.

Генерал-майор Сергей Владимирович Вишневский һәм генерал Николай Филиппович Михайлов Мәскәүдә яшиләр. Икесе дә отставкада, пенсионерлар.

Антифашистик группаның актив члennарыннан Семен Маляров һәм Артем Марценюк икесе дә Полтавада яшиләр. Маляров заводта цех начальнигы булып эшли. Артем да шул завод эшчесе.

Яшерен радиоалгыч ярдәмендә безнең антифашистик группага Совинформбюро хәбәрләрен вакытында җиткереп торган батыр йөрәкле Геннадий Нуретдинов хәзер Татарстанда яши. Нефтьче.

Михаил Менделеевич Шейман хәзер Мәскәү дәүләт университетында укыта. Доцент.

Андрей Семенович Прудников Тихорецк шәһәрендә, Алексей Андреевич Северюхин Ижевск шәһәрендә яшиләр.

А. С. Календарев Ленинградта яши. Инженер.

Ә лейтенант Хонич туган илгә кайтып җитә алмаган, юлда үлгән.

Күп кенә укучылар повесть китап булып басылып чыгачакмы, чыкса, кайчан чыгачак дип сорыйлар. Бу мәсьәләдә эш менә болай тора. Язып бетергәч, мин аны Мәскәүгә Ватан сугышы ветераннары киңәшмәсенә алып барган идем. Анда аны хәрби әсирләр секциясендә укып тикшерделәр дә, яхшы язылган дип табып, тагын да яхшырту өчен кайбер киңәшләр биреп, «Южный Урал» нәшриятында китап итеп русча бастырып чыгарырга тәкъдим иттеләр. Иптәшләрнең фикерләрен искә алып, мин повестьны яңадан карап-төзәтеп чыктым. Аннары аны әлеге нәшриятка тапшырдым. Нәшриятта повестьны укып-тикшереп 1967 ел планына керткәннәр. Ел ахырларында, шәт, бастырып чыгарырлар дип торам.

Ә татарча вариантын Татарстан китап нәшриятына тәкъдим итмәкче булам. Шулай итеп повестьның язмышы Татарстан китап нәшрияты кулына тапшырылачак. Анда ничек хәл итәрләр — анысын әйтә алмыйм.

□



# сатира һәм юмор

*Э. Гайнанов*

## Майсыз тәгәрмәч

Арба тәгәрмәче
Юл буена шыгырдады:
Атны, арбаны...
Барысын тетте сүгеп...
Ә үзенә җитми иде нибары
Бер майлам деготь.

## Палас язмышы

Йөриләр элек
Тузанлы
Аяклар белән
Таптап,
Аннары,
Кыйныйлар элеп,
Таяклар белән
шап-шап...

## Термометр

— 40 ка менеп җитәм бит,
карале!!
Мәсәлнең морале:
Артыңнан гел
кыздырып
Торсыннар әле!..

*Ш. Шәрәпов*

## Чебен

Алай итәбез, ди, без!
Болай итәбез, ди, без!
Тәрәзәдәге чебендәй
Безелди ул без-з-з дә без-з-з...

# әдәбият һәм сәнгать яңалыклары

## СОВЕТ ВЛАСТЕНЫҢ 50 ЕЛЛЫГЫНА

Татарстан китап нәшрияты Октябрьның 50 еллыгы уңае белән «Халык бәхете өчен көрәшчеләр» дигән китап бастырып чыгарды. Бу китапка Татарстан территориясендә революцион хәрәкәткә, гражданнар сугышына, Совет властеның беренче елларында социалистик төзелешкә актив катнашкан сиксәннән артык көрәшчеләр турында очерклар тупланган.

Алар төрле милләт кешеләре: татарлар, руслар, чувашлар, латышлар, литвалылар, украиннар, удмуртлар, поляклар һәм венгрлар. Барысы да коммунистлар, уртак максат өчен — хезмәт ияләрен һәртөрле изүдән коткару, илебездә социализм һәм коммунизм төзү өчен бөтен гомерләрен багышлаган кешеләр. Совет дәүләтенең күренекле эшлеклесе Үзәк мөселман комиссариаты комиссары М. Вахитов, 1905—1907 елларда Казанда революцион хәрәкәткә актив катнашкан, Октябрь революциясеннән соң СССР чит ил эшләре халык комиссары (министры) урынбасары булып эшләгән А. Лозовский, Татарстан дәүләтенең беренче житәкчесе Сәхипгәрәй Сәетгалиев, хезмәт батыры, татар әдәбияты классигы Г. Ибраһимов, Азин дивизиясендә полк командиры булган ике тапкыр Советлар Союзы Герое, Советлар Союзы маршалы В. Чуйков, халык бәхете өчен көрәшүче һ. б. ларның образлары шактый тулы сурәтләнә.

Китапны тарих фәннәре докторлары Р. Нәфигов, М. Мөхәрәмов, тарих фәннәре кандидатлары Н. Андриянов, И. Ионенко, Ю. Смыков, философия фәннәре кандидаты М. Мусин, КПССның Татарстан өлкә комитеты партархивы мөдире А. Лебедева составындагы редакцион коллегия әзерләгән. Китапка алтмыштан артык авторның очерклары кертелгән.

Бөек юбилей уңае белән нәшрият бастырып чыгарган икенче китап «Казанда Октябрь» дип исемләнгән. Китапта Казандагы Февраль революциясе белән Совет власте урнашкан вакытка кадәр булып үткән вакыйгалар сурәтләнә. Китапның авторлары И. Ионенко һәм И. Таһиров республикабызда азатлык өчен көрәшнең үзенчәлекләрен, Казан большевикларының зирәк тактикасын шактый тулы яктыртуга ирешкәннәр, революцион вакыйгаларны күрсәтә торган, моңа кадәр укучыларга билгеле булмаган күп кенә яңа фактлар ачканнар. Киң катлау укучылар массасы бу китапны да яратып кабул итәчәк.

Татарстан китап нәшриятында басылып чыккан һәм чыгачак «Ленин турында хикәяләр», Г. Халитнең «Революция тудырган геройлар», Х. Садриның «Безнең таңнар», С. Батталның «Чиремшән буйларында», А. Первенцевның «Кочубей», Ш. Рәкыйповның «Чәчәкләр сөйли белә» һ. б. китаплар да Бөек Октябрьның 50 еллыгына багышланган.

## ОЧРАШУЛАР, КОМАНДИРОВКАЛАР, КОНФЕРЕНЦИЯЛӘР

Мәскәүдә «Сокольники» паркында «Россия — минем Ватаным» дигән темага әдәби кичә үткәрелде. Кичәгә Мәскәү, Ленинград, Воронеж, Калмык АССР язучыларыннан А. Коптяева, Е. Долматовский, М. Соболев, В. Туркин, В. Кузнецов, В. Гордейчев, Б. Сангаджиевалар белән бергә Татарстаннан Зәки Нури да катнашты.

* * *

Республикабыз районнарыннан һәм күрше өлкәләрдән Казан югары уку йортларында читтән торып укучылар, укытучыларның белемен күтәрү институтындагы методик курсларга килгән укытучылар белән Казан дәүләт педагогия институтында, Укытучылар йортында язучылар берничә очрашу үткәрделәр. Бу очрашуларда Х. Туфан, Г. Бәширов, Г. Галиев, С. Хәким, Г. Гобәй, З. Нури, Н. Дәүли, Н. Фәттах, С. Радзиевская, Г. Латыйп, Л. Ихсанова, Р. Гәрәй, Ә. Бикчәнтәева, Р. Гатауллин, Г. Зәйнашева, М. Саттаров һ. б. язучылар катнашып, үзләренең яңа әсәрләрен укыдылар, иҗат планнары белән уртаклаштылар.

* * *

Р. Мостафин Сарман районы колхозларында булып кайтты. Ул анда колхозчыларга, укытучыларга һәм культура хезмәткәрләренә КПСС Үзәк Комитетының Октябрьның 50 еллыгы уңае белән чыга-

рылган тезислары турында сөйләде. Шул ук максат белән Зәки Нури Лаеш районы авылларында булды.

* * *

Шагыйрь Мостафа Ногман Пермь өлкәсенең татар районнарына һәм авылларына барып, укучылар белән очрашты, анда үзенең яңа әсәрләрен укыды, татар әдәбиятының бүгенге торышы, үзенең иҗат планнары турында сөйләде.

* * *

ВЛКСМ Үзәк Комитеты чакыруы буенча Советлар Союзына килгән Югославия пионерлары Казанда булдылар. Алар Татарстан журналистлар союзында редакция хезмәткәрләре, язучылар белән очраштылар. Кунаклар үзләре дә яшь хәбәрчеләр. Бу пионерлар «Мале новине» («Нәниләр газетасы») газетасы үткәргән конкурста җиңеп чыкканнар һәм шуңа редакцияләре аларны Советлар Союзына сәяхәткә җибәргән.

Югославия пионерлары язучы һәм журналист абыйларына Казанда алган тәэсирләре турында сөйләделәр, аннары З. Нури, Л. Ихсанова, А. Сәләхетдинов, Р. Харисов һ. б. язучыларның, журналистларның Татарстан, Советлар Союзы Герое Муса Җәлил, татар әдәбияты һәм культурасы турында сөйләүләрен кызыксынып тыңладылар.

* * *

Улан-Үдэ шәһәрендә РСФСР язучыларының әдәби тәрҗемә мәсьәләләренә багышланган пленумы үткәрелде. Анда Татарстаннан Р. Мостафин катнашты.

* * *

Горький исемендәге культура һәм ял паркында «Яшьләр — яшьләргә» дигән тематик кичә үткәрелде. Анда яшь шагыйрьләрдән Шамил Маннапов, Гәрәй Рәхим һәм Рөстәм Мингалимов катнашты.

* * *

Шагыйрь Зәки Нури Мәскәүдә «Россия китабы» дигән темага үткәрелгән халыкара китап күргәзмәсендә катнашты. Ул анда Татарстан язучылары һәм аларның китаплары турында сөйләде.

* * *

Азнакай район Советының утырышлар залында М. Хәсәновның «Саф җилләр» романы буенча укучылар конференциясе үткәрелде. Фикер алышуга район Советы башкарма комитетының культура бүлеге мөдире М. Әхсәнова, КПСС райкомының беренче секретаре Ә. Баһаветдинов, «Ленин юлы» колхозы председателе И. Исхаков, Октябрьның 40 еллыгы исемендәге колхоз зоотехнигы Усманов, район китапханәсе мөдире Дөлкәрнәева, Ленин исемендәге колхозның партия оешмасы секретаре Рахманов, ветеринария врачы Акулов һәм башка иптәшләр катнашып, әсәрдәге образларга тукталдылар, романның уңышлы һәм кимчелекле якларын күрсәттеләр. Конференциягә автор үзе дә катнашты.

* * *

Күптән түгел редакциягә Пермь өлкәсенең Барда районыннан бер хат килеп төште. Аны филология фәннәре кандидаты Дания Сарманаева язган:

«Хөрмәтле редакция!

Барда халкыннан, колхозчылардан, укучылардан, яшь язучылардан, бигрәк тә сезнең журналны яратып укучылардан ялкынлы сәлам!

Бездә язучы драматург Риза ага Ишморат булып китте.

Мин «Казан утлары» журналын бик күп еллар инде алдырам. Соңгы елларда чыга торган саннарда сез язучыларның халык белән очрашуына зур игътибар белән карап, һәрберсен чагылдырасыз. Р. Ишморат белән очрашу аерата истәлекле булды. Язучы үзенең балачагында укыган Сараш авылын хәзер, 55 елдан соң, күреп, искиткеч үзгәрешләргә гаҗәпләнде.

Тол елгасы буенча урнашкан Барда районы халкы соңгы елларда үз авылларында язучыларны, җырчыларны ешрак күрә башлады.

Алар элек-электән, җыр-музыка, әдәбият яраткан Тол буе халкына татар культурасын, аның казанышларын өйрәнергә ярдәм итәләр.

Риза ага Ишморат ике атна эчендә күп кенә авылларда булып, колхозчыларны, укытучыларны, культура хезмәткәрләрен татар әдәбиятындагы яңалыклар, аның тарихы һәм үсеше белән таныштырды, райондагы яшь һәм башлап язучыларга, халык театры коллективына төрле киңәшләрен бирде.

Язучыларның безгә килүе Уралның үзәгендә яшәгән татар хезмәт ияләренең культурасын үстерүгә зур ярдәм күрсәтә».

## ЯЗУЧЫГА ДОЛОРЕС ИБАРРУРИ ХАТЫ

Татарстан китап нәшриятында язучы Самат Шакирның «Легенда егетләре» дигән документаль повесте басылып чыккан иде. Бу повесть Сталинград сугышында һәлак булган рус, испан һәм татар халыкларының батыр уллары — очучы майор Владимир Каменщиков, пулемет ротасы командиры капитан Рубен Ибаррури һәм артиллерия батареясы командиры капитан Хафиз Фәттахетдиновка багышланган.

Күптән түгел «Легенда егетләре» повестеның авторына Испания Коммунистлар партиясе председателе Долорес Ибарруридан хат килде. Бөек Ватан сугышында батырларча һәлак булган испан егетенең әнисе язучыга рәхмәт белдергән һәм иҗатында уңышлар теләгән.

## ВОЛГОГРАДТА КИТАП САТУ БӘЙРӘМЕ

Шушы көннәрдә герой шәһәр Волгоградта Идел буе республикаларының берләштерелгән китап сату бәйрәме булып үтте. Берничә көнгә сузылган бу бәйрәмдә бик күп китаплар сатылды. Татарстан ки-

тап нәшрияты бастырып чыгарган Г. Тукай, Г. Ибраһимов, М. Җәлил, М. Әмир, Р. Ишморат һәм башка язучыларның китапларын бик күп әдәбият сөючеләр алды.

Китап сату бәйрәменә Татарстаннан язучы Сафа Сабиров һәм шагыйрь Самат Шакир барган иде. Алар геройлар аллеясында булган очрашуда үзләренең әсәрләрен укыдылар.

Республикаларның берләштерелгән китап сату бәйрәмнәре киләчәктә башка шәһәрләрдә, шулай ук Казанда да булачак.

### ВЕНГРИЯ ФӘННӘР АКАДЕМИЯСЕНДӘ

Венгрия Фәннәр академиясе каршында чыгарыла торган халыкара «Studia Musilogica» журналының IX томында музыка белгече Мәхмүт Нигъмәтҗановның Идел буе татарлары музыкасы турында инглиз телендә (21—32 битләр) мәкаләсе басылып чыкты.

Мәкаләдә татар халык музыкасының этнографик үзенчәлекләре һәм башка халыклар музыкасына булган йогынтысы турында сөйләнелә.

### РЕСПУБЛИКАБЫЗ АРТИСТЛАРЫ ГАСТРОЛЬДӘ

Свердловск шәһәрендә Миңнзәлә татар дәүләт театры гастрольдә булды. Театр тамашачыларны С. Шәкүровның «Уракчы кызы», Х. Вахитның «Соңгы хат», Р. Ишморатованың «Әйтер идем йөрәк серемне», Г. Галиевнең «Айдар» спектакльләрен күрсәтте. Татар культурасын пропагандалаудагы һәм хезмәт ияләрен эстетик тәрбияләүдәге хезмәтләре өчен КПССның Свердловск өлкә комитеты, өлкә Советы башкарма комитеты, КПССның шәһәр комитеты, шәһәр Советы башкарма комитеты театрны Грамоталар белән бүләкләде. Грамоталар аерым артистларга да бирелде.

* * *

Габдулла Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясенең Фәйзи Юсупов җитәкчелегендәге группасы совет властеның 50 еллыгына багышланган «Иҗатыбыз сиңа, Октябрь» дигән темага эстрада концерты белән Башкортстанның Октябрьск һәм Туймазы шәһәрләрендә булды. Күрше республика тамашачылары татар артистларының чыгышларын яратып карадылар.

* * *

Г. Камал исемендәге Ленин орденлы Татар дәүләт академия театры артистлары, быел өч бригадага бүленеп, республикабыз нефтьчеләре янында, авыл районнарында, Башкортстан, Удмуртия республикалары колхозларында һәм совхозларында 150 дән артык спектакль куйдылар. Тамашачылар артистларның уенын җылы кабул иттеләр. КПССның Апас районы комитеты һәм район Советы башкарма комитеты халыкка культура хезмәте күрсәтүдәге уңышлары өчен театр коллективын Почет грамотасы белән бүләкләде.

Тугандаш Башкортстан республикасы хезмәт ияләре Г. Ибраһимовның «Татар хатыны ниләр күрми» әсәре буенча эшләнгән спектакльне яратып карадылар. Бу әсәр Янавыл, Дүртөйле районнарында, шулай ук Октябрьск шәһәрендә һәм Удмуртия республикасы авылларында күрсәтелде. КПССның Уфа, Ижевск шәһәр комитетлары һәм шәһәр Советы башкарма комитетлары да артистларны Почет грамоталары белән бүләкләделәр.

### «ЗУР ИДЕЛ» КҮРГӘЗМӘСЕНДӘ

Волгоград шәһәрендә РСФСР күләмендә Совет властеның 50 еллыгы уңае белән «Зур Идел» юбилей күргәзмәсе ачылды. Анда РСФСРның тугыз өлкәсеннән, биш автономияле республикасыннан 448 художник катнашты. Республикабыз художниклары күргәзмәгә илле авторның 130 әсәрен тәкъдим иттеләр. Иң яхшы әсәрләр «Совет Россиясе» күргәзмәсенә сайланып алындылар.

### ТАТАРСТАН СОЮЗ ЭКРАНЫНДА

Хезмәт Кызыл Байрак орденлы үзәк документаль фильмнар студиясе «Туган илгә — юбилейгә» дигән киноочерк чыгарды. Ул безнең республикада төзелә торган Түбән Кама химия комбинатына багышланган. Фильмда төзүчеләрнең Совет властеның 50 еллык юбилеен нинди уңышлар белән каршылавы күрсәтелә.

### КАЗАНДА — ГАСТРОЛЬДӘ

Франциянең «Олимпия» Мюзик-хол артистлары Казанда гастрольдә булды. Җырчылардан Мирэй Матье, Мишель Дельпеш, Фреда Роби, акробат Л. Марселис чыгышларын, «Олимпия» балетын Казан тамашачылары яратып карадылар.

Шулай ук республикабыз башкаласында Н. В. Гоголь исемендәге Мәскәү театры, Хәмзә исемендәге Ленин орденлы үзбәк дәүләт академия драма театры, Ленин комсомолының XXX еллыгы исемендәге Дзержинск драма театры, СССРның халык артисты В. Дуров аттракционы катнашында Мәскәү циркы артистлары да гастрольдә булды.

### Оренбургтагы Хөсәен Ямашев исемендәге китапханәгә 60 ел

Оренбург шәһәрендә Хөсәен Ямашев исемендәге татар китапханәсенә 60 ел тулды. Шул уңай белән илебезнең төрле республикаларыннан һәм шәһәрләреннән юбилярны котлау өчен кунаклар килде. Татарстан язучылары исеменнән С. Шакир атаклы татар революционеры, большевик Хөсәен Ямашев исемен йөртүче бу китапханә эшчеләренә зур уңышлар теләде һәм Габдулла Тукай бюстен, китаплар бүләк итте.

Җаваплы редактор **Рафаэль Мостафин**

Редколлегия: **Хәй Вахит, Ибраһим Гази, Әмирхан Еники, Гази Кашшаф, Шәйхи Маннур, Габдрахман Минский, Сибгат Хәким, Нил Юзиев**

Производствога бирелде 14/VII-1967 ел. Басарга кул куелды 23/VIII-1967 ел. ПФ 05134. Кәгазь форматы 70×108$^1$/$_{16}$. Учетн.-изд. табак 12,2. Басма табак 10(14). Тираж 56 406 экз. Заказ М-1202. Бәясе 40 тиен.

ТАССР Министрлар Советы каршындагы Матбугат идарәсенең Камил Якуб исемендәге матбугат комбинатында басылды. Казан, Бауман урамы, йорт 19, 1967 ел.

Бәясе 40 тиен
Цена 40 коп.

*Ежемесячный литературно-художественный
и общественно-политический журнал*

# КАЗАН УТЛАРЫ

(ОГНИ КАЗАНИ)

ОРГАН СОЮЗА ПИСАТЕЛЕЙ ТАТАРИИ

Индекс 73210